МИРАС

ЧЫН

ФӘННИ-ПОПУЛЯР,
ӘДӘБИ-НӘФИС ЖУРНАЛ

№2 / февраль 2014

Казан – төрки дөньяның 2014 елгы мәдәни башкаласы

ТАРИХИ, ӘДӘБИ, МӘДӘНИ МИРАС, ТӘНКЫЙДИ ФИКЕР, ЗАМАН ӘДӘБИЯТЫ, ЯҢАЧА КАРАШ

МИРАС
№2 / 2014

УКАЗ
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
УКАЗЫ

Казан шәһәрен төрки дөньяның 2014 елгы мәдәни башкаласы дип игълан итү белән бәйле рәвештә оештыру чаралары турында

Халыкара төрки мәдәният оешмасы (ТЮРКСОЙ) әгъзалары булган илләр мәдәният министрлары Даими Советының чираттагы XXX утырышы Казан шәһәрен төрки дөньяның 2014 елгы мәдәни башкаласы дип игълан итү турындагы карары нигезендә, «Казан – төрки дөньяның 2014 елгы мәдәни башкаласы» программасы кысаларында тантаналы чаралар әзерләү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына ике ай вакыт эчендә:

«Казан – төрки дөньяның 2014 елгы мәдәни башкаласы» программасы чараларын әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты төзергә һәм аның составын расларга;

үткәрү вакытын, җаваплы башкаручыларны, финанслау күләмнәрен һәм чыганакларын күрсәтеп, төп чаралар планын эшләргә һәм расларга, шулай ук аны гамәлгә ашыруны контрольдә тотуны тәэмин итәргә.

2. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарына, җәмәгать берләшмәләренә һәм оешмаларга «Казан – төрки дөньяның 2014 елгы мәдәни башкаласы» программасы чараларын әзерләүдә һәм уздыруда актив катнашырга тәкъдим итәргә.

3. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына, «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе» ачык акционер җәмгыятенә, республика һәм жирле массакүләм мәгълүмат чараларына «Казан – төрки дөньяның 2014 елгы мәдәни башкаласы» программасы кысаларында уздырылучы чараларны киң яктыртуны тәэмин итәргә.

4. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2013 ел, 13 май
№ ПУ-394

МИРАС
ЧЫН
ФӘННИ-ПОПУЛЯР,
ӘДӘБИ-НӘФИС ЖУРНАЛ
№2(26) / февраль 2014

Эчтәлек

ТАРИХ

4 **XV-XVIII гасыр төрки-татар дәүләтләре тарихы буенча гарәби язулы нарратив чыганаклар.** *Ильяс Мөстәкыймов*

18 **Габденнасыйр Курсави, Шиһабетдин Мәрҗани һәм Галимҗан Барудиның яңа табылган кульъязмалары.** *Әлфрит Бостанов*

23 **Җәмалетдин әл-Әфгани һәм Ризаэддин Фәхреддин.** *Дамир-Сәед Шаһаби*

29 **Шәех Җәмалетдин.** *Ризаэддин Фәхреддин*

36 **Яңа төрек дәүләте уңчылары.** *Йосыф Акчура*

ӘДӘБИЯТ

46 **Кутадгу билик (Котайткыч белем).** *Йосыф Баласагуни*

63 **Табарлар безнең эзләрне.** *Марсель Галиев*

64 **Р.Фәхреддин: «Милләт аналары йитешдерегез!»** *Альта Мәхмүтова*

70 **Мәрьям.** *Зариф Мөэминов*

88 **Чын шагыйрь иде.** *Марсель Галиев*

93 **Шигырьләр.** *Нияз Акмал*

96 **Кеше кичерешләренең рәссамы.** (Шәриф Камалның тууына 130 ел) *Дания Заһидуллина*

106 **Кан алдыру үзенчәлекләре.** *Айдар Гайнетдинов*

110 **«Кояш» газетасында Казан хәбәрләре: 1914 елның февраль ае.** *Ленар Гобәйдуллин*

120 **Яңа китаплар.** *Алия Мөбарәкшина*

12 +

Журнал «ТАТМЕДИА» ААҖ тарафыннан гамәлгә куелды.
2012 елның май аеннан чыга.

Баш мөхәррир —
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары — җаваплы сәркатип —
Рамил ХАННАНОВ
(843) 222-09-83 (17-93)

Редакция советы:
Марсель Әхмәтҗанов
Разил Вәлиев
Резеда Ганиева
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Дания Заһидуллина
Илдус Заһидуллин
Данил Ибраһимов
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Данил Мостафин
Рөстәм Мөхәммәдиев
Рафыйк Мөхәммәтшин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Индус Таһиров
Рамил Ханнанов
Рафаил Хәкимов
Әнвәр Хуҗиәхмәтов

Бүлек мөхәррирләре:
Илдус ЗАҺИДУЛЛИН
Ленар ГОБӘЙДУЛЛИН
Алия МӨБАРӘКШИНА
(843) 222-09-83 (17-90)

Дизайнер һәм биткә салучы —
Диләрә НӘҮРҮЗОВА
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректор —
Дания ФӘЙЗУЛЛИНА
(843) 222-09-83 (17-90)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

Заказ №А-191
Тираж — 1500 данә.
Формат 70 х 108 1/16
Басарга кул куелды: 6.02.2014
Журнал айга бер тапкыр чыга.
Бәясе ирекле

Безнең журналга
54132 ИНДЕКСЫ
буенча Татарстанның һәм
70275 ИНДЕКСЫ
буенча Россия төбәкләренең
һәр элемтә бүлегендә язылырга
мөмкин.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-49398 нче таныклык белән теркәлде.

Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин.
Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә.
Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.

Тышлыкның 1 нче битендә —
«Улу Мухаммад хан». 2013 ел.
Киндер, май.
Р.Вахитов эше.

Бу санда авторларның, ТР Милли музее фондыннан, А.Дубин архивларыннан да фоторәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

«Истинное наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)



Тарих

Гасыр китабын актарсаң,
Кан тәме дә көл тәме.
Дөньяны без көтәбезме,
Дөнья безне көтәме?!

Марсель Галиев

XV-XVIII ГАСЫР ТӨРКИ-ТАТАР ДӘҮЛӘТЛӘРЕ ТАРИХЫ БУЕНЧА ГАРӘБИ ЯЗУЛЫ НАРРАТИВ ЧЫГАНАКЛАР[1]

ИЛЬЯС МӨСТӘКЫЙМОВ,
тарих фәннәре кандидаты,
Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы
Баш архив идарәсе хезмәткәре

АЛТЫН УРДА ТАРКАЛГАННАН СОҢ БАРЛЫККА КИЛГӘН ТӨРКИ-ТАТАР ДӘҮЛӘТЛӘРЕНЕҢ ТАРИХЫНА КАРАГАН ШӘРЫК ЧЫГАНАКЛАРЫНЫҢ КҮБЕСЕ ГАРӘБИ ЯЗУЛЫ, АЛАРНЫҢ ЗУР ӨЛЕШЕ ТӨРКИ ШИВӘЛӘРДӘ ЯЗЫЛГАН.

XV гасыр урталарына Ючы Олысы[2] аерым «йорт»ларга[3] таркалу, акрынлап аларда җирле историографик традицияләр яки бу традицияләрнең башлангычлары барлыкка килүгә этәргеч тудырган. Ючы Олысы җирләрендә оешкан йортлардагы историографик традицияләрнең уртак үзенчәлеге булып, В.В.Трепалов билгеләп үткәнчә, «таркалган Ючы Олысының әүвәлге бердәмлеге «инерция»сенең» һәрбер «йорт»ка ясаган зур йогынтысы тора [Трепавлов, 2011, с.10]. Алтын Урда дәүләте калдыклары булган төрки-татар мәмләкәтләре арасында тыгыз сәяси, икътисади һәм мәдәни багланышлар булган. Барыннан да бигрәк, алар арасында, халык авыз иҗаты әсәрләре һәм язма тарихи нарратив чыганаклар белән алмашу барган, шунлыктан Алтын Урда таркалганнан соң төзелгән теге яки бу мәмләкәттә язылган тарихнамәләр (хроникалар) арасында барлык Ючы Олысы тарихына яки башка «йорт»ларның башлангыч дәверләренә караган мәгълүматлар еш очрый.

Алтын Урда дәүләте таркалганнан соң барлыкка килгән төрки-татар

---

[1] Нарратив чыганаклар — хикәяләүче чыганаклар (урта гасыр тарихи хезмәтләре, елъязмалар, тарихи дастаннар һ.б.).

[2] Ючы Олысы (русчасы: Улус Джучи) — Алтын Урда дәүләтенең фәндә кабул ителгән атамасы. Урта гасыр фарсы чыганакларында кулланган. Ючы (Ючы хан) — Чыңгыз ханның олы улы. Олыс (улус) — борынгы төрки телдә «авыл; торак пункты» мәгънәсенә ия сүз булып, урта гасыр мугал (монгол) телендә «халык» төшенчәсен белдерә башлый, һәм XIII йөздә Мугал империясе оешканнан соң төрки телләрдә дә «халык, ил» мәгънәләрен ала.

[3] «Йорт» терминының урта гасыр төрки-татар чыганакларындагы мәгънәләреннән берсе: мөстәкыйль яки ярыммөстәкыйль мәмләкәт, вилаять, ил. Мәсәлән: «Туктамыш хан йорты» (Кырым ханлыгы), «Тимер Котлуг хан йорты» (Хаҗитархан ханлыгы), «Маңгыт йорты» (Нугай Урдасы), һ.б.

дәүләтләренең җирле историографик традицияләренең башка үзенчәлеге булып, аларның формалашуында зур, ә кайчакта төп рольне телдән сөйләнгән мәгълүмат (тарихи риваятьләр[4], сирәгрәк, авторга берникадәр якынрак булган теге яки бу вакыйгаларның елъязмасын тасвирлаганда — вакыйгаларны үз күзләре белән күргән кешеләрнең мәгълүматлары) уйнаудан гыйбарәт. Беренче чиратта бу Идел-Урал буенда барлыкка килгән чыганакларга карый. Вакыйгаларның үзенчәлекләренә бәйле рәвештә, Алтын Урданың соңгы дәвере традицияләре нигезендә барлыкка килгән елъязмаларда бу дәүләтнең соңгы дәвере һәм ул дәүләт таркалганнан соң булган вакыйгаларга мөнәсәбәтле төгәл даталарны сирәк кенә булса да файдалану бар. Әмма бу дәвергә мөнәсәбәтле нинди дә булса вакыйгаларның даталары искә алынса да, алар еш кына төгәл булмыйлар. Вакыйгаларны эзлекле тасвирлау җәһәтеннән, кагыйдә буларак, госманлы яки госманлыларның тарих язу традицияләре йогынтысында булган кырымлы авторлар тарафыннан язган әсәрләр мәгълүматка баерак (Габдулла бине Ризванның «Тәварихе Дәште Кыпчак»ы, сәед Мөхәммәд-Ризаның «Әс-сәбгыс-сәйяр»е һ.б.)

XII-XV йөзләрдә Ючы Олысы тарихы һәм географиясе буенча язылган гарәби язулы чыганаклар арасында Алтын Урдадан читтә фарсы һәм гарәп (беренче чиратта Мисыр) авторларының, кагыйдә буларак, фарсы, гарәп телләрендә язган әсәрләре өстенлек алган Алтын Урда дәвереннән аермалы буларак, Ючы Олысы таркалганнан соңгы дәвердән төрки-татар дәүләтләрендә иҗат ителгән шактый күп сандагы төрки телле әсәрләр, чагыштырмача аз санда төрки-татар йортыннан читтә (нигездә, госманлыларда) язылган чыганаклар калган.

Мөхәммәд-Шәйбани хан.
Мәшһүр рәссам Камалетдин Биһзад миниатюрасы. Якынча 1507 ел.
Каптерева Т.П., Виноградова Н.А. Искусство средневекового Востока. — М., 1989. — с.90.

Укучыларга уңайлы булсын өчен без, заманыбызга кадәр килеп җиткән гарәби язулы чыганакларның язылу урыннарына бәйле рәвештә өчкә (Урта Азия һәм Хөрәсән; Идел буе; Кырым һәм Госманлы) бүлеп тасвирлыйбыз. Әлбәттә, бу бүленеш беркадәр шартлы.

УРТА АЗИЯ ҺӘМ ХӨРӘСӘН ЧЫГАНАКЛАРЫ

XVI гасыр башында Әбелхәер ханның оныгы Мөхәммәд-Шәйбани Тимериләрне[5] Мавәраэннәһер[6] һәм Хөрәсәннән[7] кысрыклап чыгара һәм

[4] Соңгы үзенчәлек, күрәсең, монгол һәм монголларга кадәрге төрки (шул исәптән болгар) тарихи традицияләренә хас. В.В.Бартольд билгеләп үткәнчә, «төрки халыклар арасында тарихны һәм риваятьләрне бер-берсеннән аерып аңлау дәрәҗәсенә бары тик госманлылар гына җиткән» [Бартольд, 1963, с.100-101].
[5] Тимериләр (Тимуриды) — әмир Тимер (татар риваятьләрендә — Аксак Тимер) нәселеннән булган хөкемдарлар.
[6] Мавәраэннәһер (гар. «елга аръягы») — Амудәрья (Җәйхун) һәм Сырдәрья (Сәйхун) елгалары арасындагы җирләр.
[7] Хөрәсән — III-XVIII гасырларда Урта Шәрыктагы тарихи өлкә. Хөрәсәнне хәзерге Иранның төньяк-көнчыгыш, Төрекмәнстанның көньяк, Әфганстанның төньяк һәм төньяк-көнбатыш өлешләре тәшкил иткән.

Шыбанилар[8] дәүләтенә нигез сала. Мөхәммәд-Шәйбани хан үзенең эшгамәлләрен данлаган әсәрләр яздыра [Юдин, 2001, с.48]. Берничә шундый әсәр төзүдә ул үзе дә турыдан-туры катнаша.

Безнең көннәргә килеп җиткән, төрки телле Чыңгызый традициясе нигезендә (аның «Ючы-Шыбани тармагында») иҗат ителгән иң беренче һәм зур чыганак — исеме мәгълүм булмаган авторның 1502-1504 еллар арасында язган «Тәварихе гөзидә — Носрәтнамә» тарихнамәсе. Бу әсәр Мавәраэннәһердә һәм Хөрәсәннең бер өлешендә Шәйбанилар дәүләтен төзүче Мөхәммәд хан күрсәтмәсе белән язылган. Әсәрдә Себер йорты, Олы Урда һәм Нугай Урдасы, Болгар/Казан вилаяте (Казан ханлыгы) оешканчыга кадәрге һәм аларның башлангыч дәверләренең сәяси тарихлары турында, кыскача булса да, кыйммәтле мәгълүматлар китерелә. «Тәварихе гөзидә»дә Ючылыларның, шул исәптән Алтын Урда таркалганнан соң барлыкка килгән мәмләкәтләр хакимнәренең дә, XVI гасыр башына кадәрге генеалогиясе турында җентекле мәгълүмат булуы аеруча әһәмиятле. «Тәварихе гөзидә» Көнчыгыш Дәште Кыпчакта[9] хөкемдарлык иткән Әбелхәер хан һәм аның оныгы Мөхәммәд-Шәйбани хан хакимияте дәвере турында Шыбаниларның соңрак иҗат ителгән ядкәрләренә һәм, өлешчә, Әштерханилар[10] историографиясенә мәгълүмат бирүче төп чыганак булып хезмәт итә [Юдин, 2001, с.36-37]. Аерым әйткәндә, «Тәварихе гөзидә»дәге Әбелхәер хан хакимиятенең Урта Идел буена кадәр җәелүе турындагы мәгълүмат берникадәр үзгәртелгән рәвештә Бохара ханы Габдулла IIнең сарай тарихчысы Хафизе Тәнишнәң «Шәрәфнамәи шаһи» (икенче исеме — «Габдулланамә») (1580 нче еллар) һәм Әштерхани династиясе тарихчысы Мөхәммәд-Йосыф мөншинең[11] «Тарихе Мөкыйм хани» (XVIII гасыр башы) әсәрләрендә бар [Мустакимов, 2010, с.25-27]. XV гасыр-XVI гасыр башын тасвирлаганда «Тәварихе гөзидә» авторы, вакыйгаларны үз күзләре белән күргән кешеләрнең, шул исәптән әсәрне язарга заказ биргән Мөхәммәд-Шәйбани ханның да, хатирәләреннән файдалана. А.М.Әкрәмов тарафыннан «Тәварихе гөзидә»нең тәнкыйди тексты хәзерләнде [Таварих, 1967]. С.К.Ибраһимов [Ибрагимов, 1956, с.108-111], В.П.Юдин [Таварих, 1969], И.А.Мөстәкыймов [Мустакимов, 2009а, с.214-232; Мустакимов, 2011, с.228-248] — «Тәварихе гөзидә»дән аерым өземтәләрне рус теленә тәрҗемә иттеләр.

Кайбер тикшеренүчеләр «Тәварихе гөзидә»нең кыскартылган варианты дип, беренче мәртәбә И.Н.Березин тарафыннан нәшер ителгән, авторы мәгълүм булмаган «Шәйбанинамә»не саныйлар [Библиотека, 1849]. «Шәйбанинамә»не язучы тарафыннан коңырат кабиләсе вәкилләре турында җентеклерәк мәгълүмат өстәлгән.

1504 һәм 1510 еллар арасында фарсы телле язучы һәм музыкант Камаледдин Бинаи «Шәйбанинамә» һәм «Фөтүхате хани» тарихнамәсен яза, шунысын

---

[8] Шыбан — Ючы хан улларыннан берсе. XVI йөздә аның нәселе вәкилләре Урта Азиядә (Мавәраэннәһердә һәм Харәземдә) мөстәкыйль ханлыклар төзиләр. Әбелхәер хан — Шыбан нәселеннән булып, Көнбатыш Себердә һәм бүгенге Казакъстан территориясенең бер өлешендә хөкемдарлык иткән падишаһ.

[9] Дәште Кыпчак (шулай ук Кыпчак, Дәшт) фарсыча «Кыпчак даласы» — XI-XIX гасыр Шәрык чыганакларында көнчыгышта Иртеш елгасыннан алып, көнбатышта Туна (Дунай) елгасы тамагына кадәр, төньякта Тобол елгасы һәм Идел-Уралдан алып, көньякта Сырдәрья елгасының урта агымына кадәр сузылган җирләр. Алтын Урда дәүләте атамаларыннан берсе. Фәнни әдәбиятта Көнчыгыш Дәште Кыпчакка (Көнчыгыш Дәштә) һәм Көнбатыш Дәште Кыпчакка (Көнбатыш Дәштә) бүлү кабул ителгән. Аларның шартлы чиге булып, Җаек (Урал) елгасы тора.

[10] Әштерханилар — Әстерхан ханнарыннан чыккан, 1601-1753 еллардагы Бохара ханнары династиясе. Алар Бохара ханлыгына Шәйбанилар династиясе урынына киләләр.

[11] Мөнши — хөкемдарның хосусый сәркатибе.

әйтергә кирәк, икенче әсәр үзе үк язган «Шәйбанинамә»нең киңәйтелгән варианты булып тора. «Шәйбанинамә»дәге Көнчыгыш Дәште Кыпчак турында мәгълүматлар, нигездә, «Тәварихе гөзидә»дәге хәбәрләр белән тәңгәл килә. Әмма «Шәйбанинамә» , мөгаен, ниндидер чит чыганаклардан алынган кайбер кыйммәтле мәгълүматны да үз эченә ала [Юдин, 1969б, с.91-96].

«Тәварихе гөзидә»нең сюжеты һәм андагы мәгълүматлар, шулай ук XVI гасыр башында (вакыйгаларны тасвирлау 1501 елга кадәр җиткерелә) фарсы телендә язылган шигъри тарихнамәдә — Мөхәммәд-Шәйбани ханның сарай әдәбиятчысы мулла Шадиның «Фәтехнамә»сендә күп ягы белән кабатлана. Әмма «Фәтехнамә»дә «Тәварихе гөзидә»дә булмаган мәгълүматлар бар. Бу аеруча гаҗәпләнерлек, чөнки ике тарихнамә дә Шәйбани ханның махсус күрсәтмәсе белән һәм, аңлашыла ки, аның үзенең турыдан-туры күзәтүе астында язылган. Шунысын да әйтергә кирәк, В.П.Юдин «Фәтехнамә»нең авторы Бабәр язмалары буенча, Мөхәммәд-Шәйбани хан тарафыннан Казан ханы Мөхәммәд-Әмин хан сараена җибәрелгән музыкант Голам Шади белән бер үк шәхес булырга мөмкин, дигән фикерне әйтә [Юдин, 1969а, с.44-45][12].

XVI гасыр уртасында Мәсгуд бине Госман Күһестаниның «Тарихе Әбелхәер хани» исемле фарсы телендә язылган хезмәтенең дә йомгаклау өлешендә «Тәварихе гөзидә»дә булган мәгълүматлар шактый гына кабатлана. Әмма Күһестани әсәрендә нәсел һәм ыру-кабилә аксөякләре (угланнар һәм бәкләр) — Әбелхәернең якыннары турында күпкә тулырак күзаллау бирелә, шулай ук «Тәварих»та булмаган XV гасырның Көнчыгыш Дәште Кыпчакта-

Әбелхәер хан якын булган кешеләре белән мәҗлестә.
«Тәварихы гөзидә — Носрәтнамә» әсәренең Лондон күчермәсендәге миниатюра.
Һиҗри 970 / милади 1562-1563 ел.
British Library, Or. 3222, f. 118b

гы сәяси тарихы турында да җентекле языла [Юдин, 1969в, с.136-138]. Моңа мисал итеп, Күһестаниның XV гасырда Көнчыгыш Дәште Кыпчак хакиме Әбелхәер ханның Тура (Чимге Тура, Себердәге Төмән) шәһәрен үз кулына алуы турындагы тәфсилле хәбәрен китерергә була [Кухистани, 1969, с.144-145].

Харәзем тәхетендә Шыбаниларның башка тармагы урнаша, аларның үз историографияләре җайга салына. XVI гасыр уртасына Үтәмеш хаҗи бине мәүлана Мөхәммәд-Дусти тарафыннан историографиядә «Чыңгызнамә» һәм «Тарихе Дуст солтан» исемнәре белән мәгълүм булган тарихнамә языла[13]. Хәзерге вакытта бу әсәрнең ни-

[12] Мөхәммәд-Шәйбаниның Голам Шадины Мөхәммәд-Әмин сараена җибәрүе турында кара: [Бабер-наме, 1857, с.230].
[13] Елъязманың чыганаклары мәсьәләсе, аның исеме һәм Алтын Урда таркалганнан соң барлыкка килгән башка историографик әсәрләр арасындагы урыны турында кара: [Кавагучи, Нагаминэ, 2010, с.44-52; Миргалеев, 2011, с.14-19]

бары ике генә кулъязмасы билгеле. Аның тулы булмаган бер нөсхәсе — Ташкәнттә; аның В.П.Юдин тарафыннан хәзерләнгән транскрипциясе, рус теленә тәрҗемәсе һәм факсимиле, галим үзе вафат булганнан соң басылып чыкты [Утемиш-хаджи, 1992]. Ташкәнт кулъязмасы нигезендә бу чыганак Казакъстанда [Қазақстан, 2005], Япониядә [Ötämiš, 2008], Үзбәкстанда [Ўтамиш, 2009] һәм Төркиядә [Ötemiš, 2009] дә дөнья күрде. Икенче нөсхә исә Әхмәд-Зәки Вәлиди Туганның кулында булган. Хәзерге вакытта кулъязма Төркиядәге бер шәхси китапханәдә саклана.

Үтәмеш хаҗиның үзе язуынча, ул телдән-телгә сөйләнгән мәгълүматларны җыйнарга һәм язып алырга тырышкан. Әмма ул нигезләрендә халык авыз иҗаты — дастаннар, легенда һәм риваятьләр яткан язма чыгакларны да файдаланган булса кирәк.

Үтәмеш хаҗи әсәренең Ташкәнттә саклана торган күчермәсе Туктамыш ханның Алтын Урда тәхетенә күтәрелү турындагы хәбәре белән өзелә, әмма чыганак Олы Урда һәм Әстерхан ханлыклары тарихы турында, кыска гына булса да, кыйммәтле мәгълүматлар саклый. «Чыңгызнамә»нең Әхмәд-Зәки Вәлиди Тугандагы күчермәсен файдалану мөмкинлегенә ирешкән тикшерүчеләрнең хезмәтләренә караганда, бу нөсхә күпкә тулырак һәм анда Ючы Олысы таркалу һәм шуның нәтиҗәсендә мөстәкыйль мәмләкәтләр барлыкка килү дәверенә караган кыйммәтле мәгълүматлар тупланган [Туған, 1994, с.25–26, 149, искәрмә 98; Togan, 1981a, с.136, 161; Togan, 1981b, с.353, 492, искәрмә 176; Togan, 1999, с.39-64]. Кызганыч ки, бу нөсхә әлегә кадәр киң фәнни әйләнешкә кертелмәгән. «Чыңгызнамә»нең «Вәлиди-Туган» нөсхәсен XVIII гасыр Кырым татарлары историографиясенең иң эре әсәрләре — Мөхәммәд-Ризаның «Әс-сәбгыс-сәйяр»е һәм Габделгаффар Кырыминың «Гомдәтел-әхбар»ы белән чагыштырып караганда, Алтын Урда чоры һәм аерым төрки-татар дәүләтләре барлыкка килү вакыйгаларын тасвирлаганда кырымлы тарихчыларның Үтәмеш хаҗи елъязмасыннан киңрәк файдалана алганлыклары күренә.

Үтәмеш хаҗидан бер гасыр соң иҗат иткән ватандашы, Хива хөкемдары Әбелгази хан (1603-1663) да — ике тарихи әсәр авторы. Аның берсе — «Шәҗәрәи төрек вә мугул»да Хива ханлыгы буенча кыйммәтле материаллар тупланган; аның Алтын Урда таркалганнан соң барлыкка килгән мәмләкәтләр турындагы мәгълүматлары өзек-өзек кенә бирелгән [Aboul-Ghazi, 1871; Абуль-Гази, 1906; Әбелгазый, 2007].

Бөек Мугуллар династиясенә нигез салган Заһиреддин Мөхәммәд-Бабәрнең (1483-1530) тарихнамәсе башка чыганаклардан беркадәр үзгә булып тора. Бабәрнең «Бабәрнамә» дигән исеме белән билгеле әсәре чыгтай шивәсендә язылган. Ул, нигездә, автобиографик характерда һәм XV гасыр азагы — XVI гасыр башы Урта Азия, Әфганстан, Һиндстан халыкларының тарихын чагылдыра. Бу елъязмада шул чордагы төрки-татар дәүләтләре тарихы буенча да кайбер мәгълүматлар бар. Аерым алганда, анда Олы Урда хакимнәренең Тимериләр белән никах мөнәсәбәтләре турында әйтелә [Бабур-наме, 1958, с.189-190], «үзбәк»[14] хакиме Мөхәммәд-Шәйбани хан белән Казан ханы Мөхәммәд-Әмин арасында яшәп килгән тыгыз элемтәләр турында күләмле булмаган, әмма кыйммәтле мәгълүмат бар [Бабер-наме, 1857, с.230][15].

---

[14] Тарих дәвамында «үзбәк» этнонимының (халык атамасы) мәгънәсе үзгәреп торган. XVI гасыр авторы Фазлулла бине Рузбиһан Исфаһани әйтүенчә, аның заманында «үзбәк» атамасы өч кабиләгә: «шыбаниларга» (Шыбани хөкемдарлар кулы астындагы кавемнәргә), казакъларга һәм маңгытларга (нугай) нисбәт ителгән.

[15] Әлеге ике хаким арасындагы тыгыз мөнәсәбәтләрнең тагын бер дәлиле булып, Мөхәммәд-Шәйбани ханның Мөхәммәд-Әмин хан гаскәренең 1505 елда Мәскәү бөек кенәзе гаскәрен җиңүенә багышланган шигыре тора [Togan, 1981a, с.133].

1438 елда — Олуг Мөхәммәдне Алтын Урда тәхетеннән куып җибәрү һәм ул дәүләт тулысынча таркалып, Олы Урда формалаша башлаган елны — Сарай шәһәренә сәүдә эшләре белән Ирандагы Шираз шәһәреннән Шәмсетдин Мөхәммәд исемле сәүдәгәр килә. Аның Сарай базарларында бай товар ассортименты һәм бәяләр турындагы сәфәр хисабын Һәрат авторы Мөхәммәд әл-Комый үзенең фарсы телле «Шәмсессийак» хезмәтенә кертә (бу хисапның эчтәлеге турында карагыз: [Заходер, 1967, с.166-167]).

Нугайлар («үзбәкләр»), Әстерхан һәм Кырым ханлыклары турында кайбер мәгълүматлар фарсы авторы Шәрифеддин Хөсәен Шәрифинең үзенең әтисе Хөсәен Харәзми (1551 елда вафат) — Көбравия суфый тарикате шәехенең тормыш юлын яктыртуга багышланып, 1573 елда язылган «Җаддәтел-гашыйкыйн» исемле агиографик әсәрендә бар [Муминов, 2012]. Шәех хаҗга барганда, 1550 елда үзенең яраннары белән Сарайчык шәһәре, Әстерхан һәм Кырым аша уза. Әсәрнең авторы бу җирләр турында кыскача гына мәгълүмат биреп китә [Шарифи, 1390, с.39-43].

ИДЕЛ БУЕ ЧЫГАНАКЛАРЫ

...1550 елның кышында рус гаскәре янәдән Казан каласын камап ала. Әмма казанлыларның шәһәрне батырларча саклаулары (рус елъязмалары буенча — начар һава торышы) дошман гаскәрен чигенергә мәҗбүр итә. Әлеге вакыйгалар «Зафәрнамәи вилаяте Казан» («Казан мәмләкәтенең[16] җиңүе турындагы язма») исемле әдәби-публицистик әсәрдә чагылыш таба. Бу әсәрнең авторы Шәриф Хаҗитархани дигән шәхес булып, аны күп кенә тикшерүчеләр соңгы Казан сәеде Кол-Шәриф белән тәңгәлләштерәләр. «Хаҗитархани» нисбәсе күрсәтүенчә, «Зафәрнамә»нең авторы Әстерхан белән ниндидер бәйләнештә булган (мөгаен, чыгышы белән шул төбәктәндер). Чыганакның безнең көннәргә килеп җиткән бердәнбер нөсхәсе XVI гасырга карый. Ул Төркиядә, Көтаһия илендә (өлкәсе), Таушанлы илчәсендәге (өязе) Зәйтин угыллары китапханәсендә саклаучы бер кульъязма җыентыкта табылган[17] һәм Әхмәд-Зәки Вәлиди Туган тарафыннан тарихи шәрехләүләр белән гарәп графикасында басылган [Togan, 1965, с.179-204]. Ә.З.Вәлиди-Туганның хезмәте Ә.Н.Куратка әлеге чыганакны кыскартып бастырып чыгарырга һәм аның төрек теленә кыскартылган тәрҗемәсен нәшер итәргә [Kurat, 1972, с.361-372] һәм хәзерге заман төрек галимәсе А.М.Үзйәтгингә хәзерге төрек транскрипциясен, төрекчәгә тәрҗемәсен әзерләргә һәм чыганакны филологик тикшерергә нигез булды [Őzyetgin, 1993, с. 321-413]. Үз чиратында, А.М.Үзйәтгиннең төрекчәгә тәрҗемәсе Ф.С.Хәкимҗановка бу чыганакны рус теленә [Шерифи, 1995, с.83-92], ә Ә.Н.Куратның кыскартылган публикациясе — М.И.Әхмәтҗанов тарафыннан татар теленә тәрҗемә итәргә нигез булды [Шәриф, 1995, с. 12-16; Кол Шәриф, 1997, с.76-93; Кол Шәриф, 2005, с.16-22; Мәңгелеккә, 2006, с.16-23]. Чыганакның А.М.Үзйәтгин хәзерләгән төрекчә тексты узган ел «Чын мирас» журналында А.Рәхимованың хәзерге татар теленә тәрҗемәсендә тулаем дөнья күрде [Үзйәтгин, 2013, с.7-13]. «Зафәрнамәи вилаяти Казан» — Идел буенда язылып безнең көннәргә кадәр килеп җиткән иң әүвәлге тарихи нарратив чыганак булып тора.

Гомумән алганда, Идел-Урал

[16] «Вилаять» термины гадәттә өлкә, ил мәгънәсен белдергән территориаль берәмлекләргә карата кулланыла. Әмма бу контекстта «вилаяте Казан», һичшиксез, Казан ханлыгының рәсми исеме булып тора, һәм аны «Казан мәмләкәте (дәүләте)» (урта гасыр рус чыганакларында «Царство Казанское») дип шәрехләргә кирәк.

[17] Хәзерге вакытта бу кульъязма Таушанлы шәһәрендәге Зәйтин углы илчә халык китапханәсендә саклана.

төбәгендә мөселман историографик традициясе бары тик XVII гасырда гына, ягъни төбәк Россия составына кергәннән соң гына барлыкка килә [Франк, 2008, с.27]. Идел буе мөселман историографиясенең безнең көннәргә килеп җиткән иң әүвәлге җәүһәрләре шул гасырга карый. Шул ук вакытта, тикшерүчеләр билгеләп үткәнчә, җирле тарихчылар элегрәк язылган чыганакларга да мөрәҗәгать иткәннәр. Мөгаен, А.Ф.Франкның, Идел-Урал төбәгендә ислам историографиясе «тарихи әсәрләргә әверелгән халык тарихи риваятьләренә нигезләнә», дигән фикере хакыйкатьткә якындыр [Франк, 2008, с.27]. Җирле елъязмаларның авторлары язма чыганакларны да файдаланган. Шул ук вакытта, бу чыганаклар өчен, А.Франкның: «Кадыйр-Гали бик[18] үзенең хезмәтендә язма чыганакларны файдаланса да, аның, үз чиратында, билгеле бер дәрәҗәдә халык тарихи риваятьләренә нигезләнгәнлеге аңлашыла», — дип, Идел буе мөселман историографиясенең хәзерге көннәргә килеп җиткән иң әүвәлге әсәрен бәяләгән искәртмәсе дөреслеккә туры килә [Франк, 2008, с.29].

1602 елда Касыйм ханы Ураз-Мөхәммәднең яраны, җалаер кабиләсеннән чыккан Кадыйр-Гали бик тарафыннан үз исеме сакланып калмаган тарихи әсәр языла. Фәндә аның, чыганакны беренче тикшергән галим И.Н Березин тарафыннан тәкъдим ителгән, «Җамигыт-тәварих» дигән шартлы исеме урнашкан. Елъязма патша Борис Годуновка багышланган кереш, Рәшидеддиннең «Җамигыт-тәварих» әсәреннән өзек һәм авторның үз хикәяләвендәге Орыс, Туктамыш, Тимер-Котлыг, Хаҗи-Гәрәй, Хаҗи-Мөхәммәд, Әбелхәер, Ядегәр, Ураз-Мөхәммәд ханнар һәм Идегәй би шәхесләренә һәм нәсел-нәсәпләренә багышланган 9 дастаннан гыйбарәт. «Җамигыт-тәварих»ның әлеге дастаннарында Алтын Урда таркалганнан соң барлыкка килгән мәмләкәтләр турында кыскача, әмма кыйммәтле мәгълүматлар бирелә (хикәяләве XV гасырның беренче чиреге вакыйгаларын тасвирлау белән туктап калган «Туктамыш хан турындагы дастан»нан кала). Бу дастаннарның шактый дәрәҗәдә телдән сөйләнгән мәгълүматларга нигезләнгәнлеге күренә (югарыдагы А.Франк искәрмәсен карагыз). М.Г.Госманов «Җамигыт-тәварих»тагы дастаннар нигезендә төрки телле тарихи әсәрләр ята, шул ук вакытта фольклор ядкәрләре дә «авторга зур таяныч булып тора», дигән фикер әйтә [Усманов, 1972, с.53]. Соңгы дастанны Кадыйр-Гали бик анда тасвирланган күп кенә вакыйгаларның шаһиты буларак язган. Ураз-Мөхәммәд ханга багышланган бу дастан Кадыйр-Гали бик тарихнамәсенең төп өлеше булып тора, әсәрнең калган өлешләре исә аңа фон буларак кына хезмәт итә (чыганак турында җентеклерәк карагыз: [Усманов, 1972, с.33-96]). Әсәрнең беренче публикациясен оригинал телендә (төрки-татарча) И.Н.Березин хәзерли [Библиотека, 1854]. Соңгы чирек гасырда бу ядкәрнең хәзерге казакъ һәм татар графикасына күчерелмәләре һәм казакъ, татар телләренә тәрҗемәләре дөнья күрде [Қадырғали, 1997; Сыздыкова, 1989; Сыздықова, Қойгелдиев, 1991; Мирастан, 2011, с.8 – 36[19]].

Идел буе историографиясенең тагын бер эре ядкәре — авторы мәгълүм булмаган «Дәфтәре Чыңгызнамә» (XVII гасыр азагы). Чыганак «Чыңгыз хан нәселе турындагы дастан», «Аксак Тимер нәселе турындагы дастан», «Гайса угылы Амәт турындагы дастан», «Идегә би турындагы дастан», «Урыннар һәм шәһәрләр турындагы дастан», «Тарих турындагы дастан» дип исемләнгән алты бабтан тора (чыганак турын-

[18] Бик (шулай ук би) — бүгенге татар әдәбиятында кабул ителгән бәк феодаль титулының урта гасыр төрки-татар әйтелеше.
[19] Соңгы басмада Рәшидеддиннең «Җамигыт-тәварих» әсәре кергән бүлекләр төшереп калдырылган.

да кара: [Усманов, 1972, с.97-133]). «Дәфтәре Чыңгызнамә»нең нигезендә халык авыз иҗаты чыганаклары ята. Өченче, бишенче һәм алтынчы баблар Казан йорты тарихына караган кайбер мәгълүматлар бирә.

«Дәфтәре Чыңгызнамә» тексты чыганакның үз телендә һәм хәзерге татар теленә тәрҗемәдә берничә мәртәбә басылды. Шулай ук аерым дастаннарының текстлары һәм тәрҗемәләре дә берничә тапкыр дөнья күрде[20]. 2002 елда М.Г.Госманов һәм М.Иванич тарафыннан «Дәфтәре Чыңгызнамә» әсәренең тәнкыйди тексты дөнья күрде [Ivanics, Usmanov, 2002].

Күптән түгел, «Дәфтәре Чыңгызнамә»нең бер күчерелмәсе нигезендә, әсәрнең киң таралган варианттан дастаннарының саны һәм эчтәлеге (шул исәптән, төрки-татар дәүләтләре, аеруча Кырым йортының башлангыч дәвере тарихы турында үзгә мәгълүмат бирүе) җәһәтеннән аерылып торучы тагын бер варианты (редакциясе) барлыгы турында фараз әйтелде [Мустакимов, 2009б, с.122-131]. Бу фикер «Дәфтәре Чыңгызнамә»нең ТР ФА Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Язма һәм музыкаль мирас үзәге фондында эчтәлеге белән югарыда телгә алынган нөсхәгә охшаш тагын бер кулъязмасы саклануы белән раслана. Бу күчерелмәдә Әстерхан ханлыгы тарихы турында, буталчык булса да, оригиналь мәгълүматлар теркәлгән (кызганыч, кулъязма начар сакланган) [ЯһММҮ, 44аб кгз.][21].

Идел буе мөселман историографиясенең тагын бер кызыклы ядкәре булып, исеме мәгълүм булмаган авторның XVIII гасырның икенче яртысында язылган, шартлы рәвештә генә «Хикәять» дип аталучы фарсы телле тарихнамәсе тора [Салахетдинова, 1965, с.147-154]. Бу әсәрнең төрки варианты да булган. Аның нигезендә «Хикәять»нең рус теленә тәрҗемә ителгән ике өзеге һәм берничә факсимиль фрагменты басылып чыккан [История, 1937, с.122-124; 402-406]. Ядкәрнең башлангыч өлеше «Дәфтәре Чыңгызнамә»дәге дастаннарның кайберләре белән охшаш, әмма шул ук вакытта безгә билгеле булган башка мөселман чыганакларын кабатламаган мәгълүматлар да бар. А.Франк «Хикәять»кә XVIII гасыр дәвамында барлыкка килгән тарихнамәләр арасыннан (Кадыйр-Гали бикнең «Җамигыттәварих»ына һәм авторы билгесез «Дәфтәре Чыңгызнамә»гә караганда) «җирле тарихны күбрәк хикәяләгән» әсәр буларак карый [Франк, 2008, с.35]. Шулай ук, бу әсәр XIX гасыр татар-башкорт тарихчысы Таҗетдин Ялчыгол тарафыннан үзе кулланган чыганакларның берсе буларак искә алган, безнең көннәргә кадәр килеп җитмәгән «Фәрһәңнамә» тарихнамәсенең нөсхәсе, дигән фикер дә әйтелде [Мустакимов, 2008, с.144-145].

Татар тарих язмачылыгында киң таралган ядкәр булып тарихи вакыйгаларны теркәп барган кыска язмалар тора (кагыйдә буларак, алар җирле тарихка карыйлар). Аларның гомум кабул ителгән атамалары юк, чыганакларда «тәварих» яки «тарихлар»; фәнни хезмәтләрдә аларны гадәттә «вакаигънамә» яки русча «летопись» дип аталалар. Мондый фактик мәгълүматка бай «вакаигънамә»ләр XVII гасырдан да иртә очрамый. Шундый «вакаигънамә»ләрнең иске үрнәкләреннән берсе югарыда әйтеп үтелгән «Дәфтәре Чыңгызнамә»дә азаккы дастан буларак кертелгән. «Вакаигънамә»ләрнең кайбер үрнәкләре Г.Рәхимнең бу турыдагы махсус мәкаләсендә басылган [Рахим, 2008, с.125 — 192].

XIX гасыр башы тарихнамәсенә —

[20] Соңгы публикацияне кара: [Мирастан, 2011, с.38-94]. «Дәфтәре Чыңгызнамә» турында элеккеге публикацияләр һәм кулъязмаларының нөсхәләре турында кара: [Усманов, 1972, с.98-104].
[21] Форсаттан файдаланып, бу кулъязма белән танышырга мөмкинлек биргән өчен Марсель ага Әхмәтҗановка ихлас рәхмәтемне белдерәм.

1484 елда госманлы падишаһы Баязид IIнең Кырым ханы Миңле-Гәрәйне кабул итү мәрасиме.
Мөхәммәд бәк миниатюрасы. XVI йөз ахыры.
Зайцев И.В. Крымская историографическая традиция XV — XIX вв.: пути развития: рукописи, тексты и источники. — М., 2009. Тышлыктагы рәсем

Хисаметдин Мөслиминең «Тәварихе Болгария»сенә — шәрех буларак Казан мулласы Хөсәен Әмирханов шул ук исемдәге китабын яза. Китапта Казан һәм Казан ханнары тарихы турында да сюжетлар бар [Әмирхан, 1883; Амирханов, 2010]. Әмма анда китерелгән мәгълүматларның күбесе ганганәви (легендар) рухта, шунлыктан бу әсәр историографик җәһәттән генә кызыклы.

Без бу мәкаләбездә Хисаметдин Мөслиминең «Тәварихе Болгария» һәм Таҗетдин Ялчыголның «Тарихнамәи Болгар» кебек Идел-Урал мөселман историографиясе ядкәрләрен тикшерергә алынмыйбыз, чөнки аларда XV-XVIII гасыр төрки-татар дәләтләре тарихына караган мәгълүматлар юк диярлек (бу чыганаклар турында җентекләбрәк кара: [Усманов, 1972; Кемпер, 2008; Франк, 2008]).

КЫРЫМ ҺӘМ ГОСМАНЛЫ ЧЫГАНАКЛАРЫ.

Алтын Урда таркалганнан соң барлыкка килгән дәүләтләрнең тарихы буенча язма чыганакларның күпчелеге Кырым ханлыгы белән бәйле. Моның сәбәпләренең берсе — башка төрки-татар дәүләтләре белән чагыштырганда Кырым ханлыгының озынрак гомерле булуы. Икенче сәбәбе — ханлыкка үзенең үскән историографик традицияләре белән Госманлы империясенең көчле йогынты ясавы[22]. Моннан тыш, мөһим геополитик урын биләве һәм бу татар мәмләкәтенең озак вакытлар хәрби куәтне саклавы белән дә ул госманлы һәм аурупалы авторларның игътибарын үзенә җәлеп иткән.

Безнең көннәргә килеп җиткән Кырым ханлыгы тарихы турындагы иң борынгы чыганак булып, Сахиб-Гәрәй ханның Кырымда идарә итү дәверенә багышланган (1532-1551) «Тарихе Сахиб-Гәрәй хан» тарихнамәсе тора. Әсәрнең авторы — Бәдреддин Мөхәммәд бине Мөхәммәд Кайсунизадә Нидаи әфәнде (Рәммаль хуҗа исеме белән дә мәгълүм шәхес) 1532 елдан алып 1551 елгача Сахиб-Гәрәй ханның шәхси табибы булып, ханның үлеменә кадәр аңа хезмәт иткән [Зайцев, 2009, с.69]. Рәммаль хуҗаның сүзләренә караганда, үзенең «Тарихе Сахиб-Гәрәй хан»ын ул Сахиб-Гәрәй үтерелгәннән соң, ханның кызы үтенече буенча язган. Әсәр 1553 елда төгәлләнә. Тарихнамәнең нигезен авторның үз күзе белән күргән вакыйгалар тәшкил итә, шулай ук, вакыйгаларда катнашучы башка шәхесләрнең дә мәгълүматлары күренә [Остапчук, 2002, с.395]. Рәммаль хуҗа тарафыннан фәтехнамә[23], рәсми документлар кебек язма чыганаклар да файдаланыла [Зайцев, 2009, с.76-78]. Рәммаль хуҗаның хезмәтендә төгәл даталар сирәк очраса да, аңарда Кырым хан-

[22] Кырым йортына госманлы йогынтысы, ханлык Госманлы империясенә вассаль бәйлелеккә дучар булганнан соң, XV гасырның соңгы чирегендә көчәя.
[23] Фәтехнамә (шулай ук зафәрнамә) (гар.-ф.«җиңү турындагы язма») — зур хәрби уңышка ирешкән мөселман хөкемдарының яки гаскәр башлыгының җиңүен тасвирлап, тантаналы рухта язылган документ яки әдәби-публицистик әсәр.

лыгы турында гына түгел, ә өлешчә Казан, Әстерхан ханлыклары, Нугай Урдасы тарихына да караган кыйммәтле мәгълүматлар тупланган. И.В.Зайцев «Тарихе Сахиб-Гәрәй хан»ның ике яки өч варианты булуы турында яза [Зайцев, 2009, с.75]. Тарихнамәнең ике иң борынгы нөсхәсе нигезендәге җыелма тексты Г.Гүкбилгин тарафыннан басмага хәзерләнде һәм басылып чыкты [Tarih, 1973].

1556 елда Дәште Кыпчак аша госманлы адмиралы Сәйди-Гали рәис уза һәм үзенең язмаларында нугайлар турында кайбер мәгълүматлар калдыра [Seydi, 1313, с.71-73; Seydi, 1999, с.137-139].

Төрки-татар дәүләтләре турында төрле чыганаклардан җыйнап алынган кыйммәтле мәгълүматлар XVI гасыр госманлы авторы әл-Җәннабинең гарәп телендә язылган тарихнамәсендә бар. Аерым алганда ул, XV гасыр уртасына кадәрге дәверне тасвирлаганда, безнең көннәргә килеп җитмәгән фарсы телле автор хафиз Мөхәммәд Ташкәндинең «Тарихе але Чыңгыз» исемле тарихнамәсеннән файдаланган. Әл-Җәннаби әсәреннән өземтәләр В.В.Вельяминов-Зернов һәм В.Г.Тизенгаузен тарафыннан басыла [Вельяминов-Зернов, 1863, с.374-376; ал-Джаннаби, 1884, с.535-538].

Күчем хан һәм Себер ханлыгы турында кыска гына мәгълүмат XVI гасыр госманлы тарихчысы Сәйфи Чәләбинең «Тәварих» әсәрендә бар. Бу хезмәтнең «Тура вилаяте» турында мәгълүмат булган өземтәсе Т.И.Солтанов тарафыннан басмага хәзерләнде [Султанов, 2005, с.261].

1635 елга кадәрге Кырым һәм Кырым ханлыгы турында кыйммәтле һәм үзенчәлекле чыганак булып Габдулла бине Ризванның 1638 елда язып төгәлләгән «Тәварихе Дәште Кыпчак»

Сәед Мөхәммәд-Риза.
Әс-сәбгыс-сәйяр фи әхбары мөлүке татар.
— Казан, 1832. Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә саклanучы нөсхәнең титул бите

әсәре тора[24]. Тарихнамә авторының атасы 1611 елда Кәфә валисе[25] итеп тәгаенләнә. Шулай итеп, Габдулла бине Ризван XVII гасырда Кырымда булган вакыйгаларның шаһиты да булырга мөмкин [Зайончковский, 1969, с. 18]. А.Зайончковский искәртүенчә, «Тәварихе Дәште Кыпчак»ның XVII гасырның беренче яртысында Кырым ханлыгы тәхетенә дәгъва белдерүчеләр — Мөхәммәд-Гәрәй һәм Җаныбәк-Гәрәй арасындагы үзара сугышлар дәвере турында биргән мәгълүматлары аеруча кыйммәтле [Зайончковский, 1969, с.18-19]. Поляк галиме А.Зайончковский тарафыннан бу ядкәрнең тәнкыйди тексты хәзерләнде [Zajaczkowski, 1966].

Шартлы рәвештә генә госманлы чыганаклары рәтенә Павел Хәләбине «Па-

---

[24] Бу чыганак турында тәфсилле мәгълүматны кара: [Зайончковский, 1969].
[25] Кәфә (ит. Caffa, рус. Кафа, бүгенге көндә — Феодосия) — Кырым ярымутравындагы борынгы шәһәр. 1475 елдан Госманлы дәүләтенең санҗагы, XVI йөз ахырыннан — әяләте (вилаяте, провинция-се) мәркәзе була. Вали — губернатор.

триарх Макарийның сәяхатнамәсен»дә кертергә мөмкин [Крачковский, 2004, с. 687 и сл.]. Павел Хәләби үзенең атасы — Антакия (русча — Антиохия) патриархы Макарий белән ике мәртәбә Рус дәүләтендә була. Ул үзенең беренче сәфәре турында гарәп телендә юлъязмаларын калдыра. Макарий белән Павел 1653 елда Россиягә барганда һәм 1656 елда аннан кире кайтканда Молдавия һәм Украина территорияләре аша узалар. Үзенең язмаларында Павел Хәләби Кырым татарлары, Кырым-казак һәм Кырым-Мәскәү мөнәсәбәтләре турында вакыйгаларның шаһиты булган христианнар һәм татарлар белән әңгәмәләрдән һәм үз күзәтүләреннән кайбер мәгълүматлар китерә. Ул Касыйм ханлыгы, Касыйм хакиме Сәед-Борханны чукындыру турында, кыска, әмма кызыклы мәгълүматлар китерә [Муркос, 1898].

Татар мәмләкәтләренең тарихы һәм географиясе турында кайбер мәгълүматларны XVII гасыр госманлы әдибе Мостафа бине Габдулла Кятиб чәләби (Хаҗи хәлифә) үзенең «Җиһаннөма» («Җиһан көзгесе») исемле географик әсәрендә китерә. Шунысын әйтергә кирәк, Кятиб чәләби Казан татарларының солтан Сәлим IIгә (1566-1574) «Мәскәү кяферләре»нә каршы ярдәм сорап мөрәҗәгать итүләре турында хәбәр итә һәм Идел белән Дон елгаларын «ул җирләрнең» яулап алыр өчен канал белән тоташтыру идеясе «авторлыгын» татарларга нибәт итә (канал турында шушы мәгълүматны ул «Төхфәтел-кибар фи әсфарел-бихар» исемле тарихи әсәрендә дә кабатлый) [Кятиб, 1145, с.375-376; Кятиб, 1141, л.39].

Кырым ханлыгы турында тагын бер кыйммәтле госманлы чыганагы булып XVII гасыр төрек сәяхәтчесе Әүлия Чәләбинең «Сәяхатнамә» әсәре тора (бу әсәр турында кара: [Крачковский, 2004, с.624 и сл.]). «Кырым ярымутравында берничә мәртәбә булган Әүлия, гомумән алганда, күргәннәрен һәм ишеткәннәрен бик төгәл җиткергән» [Зайцев, 2009, с.218]. Автор шул замандагы Кырым ханлыгы турында мәгълүматлар китерә, шулай ук үзе ишеткән риваятьләрне сөйли [Эвлия, 1996; Эвлия; 1999; Эвлия, 2008].

Кырым ханлыгы турында кайбер мөһим мәгълүматлар XVII гасыр икенче яртысында яшәгән госманлы авторы Хөсәен Һәзарфәннең «Тәлхыйсел-бәян фи каванине але Госман» («Госманлы династиясе кануннарының асылын хикәяләү») исемле әсәрендә дә бар [Орешкова, 1990, с.228-305; Hezarfen, 1998].

В.Д.Смирнов Кырым ханлыгы, аеруча Кырым-Госманлы мөнәсәбәтләре тарихын өйрәнүдә XVII гасыр азагы — XVIII гасыр башы госманлы тарихчысы Мөхәммәд Фындыклылының хезмәте зур әһәмияткә ия, дип искәртә [Fındıklılı, 1928].

Сәед Мөхәммәд-Ризаның «Әс-сәбгыс-сәйяр фи әхбаре мөлеке татар» («Татар патшалары турындагы хәбәрләргә караган җиде планета») хезмәте хаклы рәвештә Кырым историографиясенең аеруча әһәмиятле әсәре булып санала. Тарихчының 1737 елда төгәлләнгән әлеге хезмәте, нигездә, Кырым ханлыгының Миңле-Гәрәй Iдән алып Миңле-Гәрәй II ханнары идарә иткән чорлар аралыгындагы (1466 елдан 1737 елгача) тарихи вакыйгаларны тасвирлауга багышлана. Моннан тыш, «Әс-сәбгыс-сәйяр»дә Алтын Урда тарихы буенча да кыска, әмма кыйммәтле мәгълүматлар китерелә. В.Д.Смирнов, Кырым тарихын өйрәнүдә Мөхәммәд-Риза тарихнамәсенең әһәмиятен бәяләп: «Бу әсәр үзенең эчтәлеге байлыгы һәм төрлелеге белән безнең Кырым ханлыгы тарихы турында кул астыбызда булган төрек чыганакларның барысыннан да өстен; моны Кырым татар ядкярләре буенча энциклопедик җыентык, дип әйтергә мөмкин», — дип яза [Смирнов, 2005, с.35]. Мәшһүр шәркыятчы белән хәзерге заман тикшерүчеләре дә килешә [Зайцев, 2009, с.97]. 1832 елда әсәр М.А.Кязыймбәк тарафыннан Казанда басылып чыга [Сеид, 1832].

«Сәед Мөхәммәд-Ризаның чамадан тыш авыр һәм чуар теле укучылары өчен кыенлыклар тудырды, бу исә ул хезмәтнең үзенә күрә бер кыскача редакциясенең барлыкка килүенә сәбәпче булды» [Зайцев, 2009, с.121]. Кыскача редакциянең авторы Кырымда яшәүче Хөррәми чәләби Акай әфәнде булды. Ул үзенең хезмәтен 1748 елга кадәр язган [Зайцев, 2009, с.121]. Әсәрнең үз исеме юк. В.Д.Смирнов аны «Кыскача тарих» дип кенә атаган. Галим, бу хезмәтне тасвиралап: «Кыскача тарихта без «Әс-сәбгыс-сәйяр»дә очрамаган фактлар яки җентекле тасвирлауларны очратабыз, һәм бу аңа мөстәкыйль чыганак кыйммәтен бирә. Шунысы күзгә ташлана — автор «Әс-сәбгыс-сәйяр»дән өземтәләр биргәндә, кайбер очракларда үзенең хикәяләвен тулыландырган башка ядкәрләрдән дә файдалана», — дип яза [Смирнов, 2005, с.36; Зайцев, 2009, с.106]. Хөррәми чәләбинең хезмәтеннән кайбер өзекләр рус теленә тәрҗемә ителеп басылып чыкты [Негри, 1844].

XVII гасыр азагы — XVIII гасыр урталарында «Гомдәтел-әхбарел-могтәбәр» (яки «Гомдәтел-әхбарел фи тарихет-татар») исемле китап авторы әл-хаҗҗ Габделгаффар бинел-хаҗҗ Хәсән бинел-хаҗҗ Мәхмүд бинел-хаҗҗ Габделваһһаб әл-Кырыми исемле тарихчы яши [Зайцев, 2009, с.179]. Эчтәлеге белән «гомуми тарих»ны тәшкил иткән әлеге әсәр 1744 елда язып тәмамланган. Анда Алтын Урда таркалганнан соң барлыкка килгән төрки-татар йортлары тарихының башлангыч дәверләре турында шактый кыска, әмма башка чыганакларда очрамаган мәгълүмат, шулай ук Кырым ханлыгы тарихы буенча мөһим белешмә бирә. Габделгаффар Кырыми Ширын дигән татар кабиләсенең күренекле вәкиле һәм «патриоты» була, шуның өчен ул үзенең әсәрендә бу кабилә тарихына зур игътибар бирә. Кырыми тарафыннан Алтын Урда тарихы һәм әлеге дәүләт таркалганнан соңгы вакыйгалар турындагы белешмәләр, һичшиксез, теге яки бу дәрәҗәдә фольклорлашкан. «Гомдәтел-әхбар»дагы Алтын Урда дәверенә караган аерым мәгълүматлары XVI гасырда яшәгән харәземле автор Үтәмеш хаҗиның «Чыңгызнамә»се белән тәңгәл килә.

Бүгенге көндә «Гомдәтел-әхбар»ның тулы бер нөсхәсе һәм, И.В.Зайцев фикеренчә, әлеге хезмәтнең күчерелмәсе булган бер кульязмасы мәгълүм [Зайцев, 2009, с. 179]. Тулы нөсхәсенең Алтын Урда һәм Кырым ханлыгы тарихына караган аерым кисәкләре 1924-1925 елда төрек тарихчысы Нәҗип Гасыйм тарафыннан дөнья күрде [Кырыми, 1343].

Кырым ханлыгы буенча соңгы зур чыганак булып Хәлим-Гәрәй солтанның 1811 елда язып төгәлләгән «Гөлбөне ханан» («Ханнарның гөл агачы») исемле тарихнамәсе тора. Әсәрнең авторы Кырым ханнары (Гәрәйләр) династиясе вәкиле. Хәлим-Гәрәй Кырым ханлыгының тарихын Хаҗи-Гәрәй хан заманыннан (як. 1426-1466) алып Бәхет-Гәрәй хан заманына (1789-1792) кадәр тасвирлый [Зайцев, 2009, с.183-186]. Тарихчының әсәре ике мәртәбә басылып чыга. Әйтергә кирәк ки, авторның стиле саклану һәм тулылыгы җәһәтеннән бары тик 1870 елгы беренче басма гына камил [Халим-Гирай, 1287/1870; Халим-Гирай, 1327/1909]. 1909 елгы басмасы латин транскрипциясендә рус теленә тәрҗемә белән 2004 елда яңадан дөнья күрде [Халим, 2004].

Татар һәм дөнья фәнендә төрки-татар дәүләтләре тарихына караган язма чыганакларны барлау һәм өйрәнү дәвам итә. Соңгы берничә дистә ел эчендә бу өлкәдә шактый ачышлар да ясалды. Шуңа күрә илебезнең һәм дөньяның архив-китапханәләрендә саклანучы кульязма чыганаклар арасында урта гасыр тарихыбыз өчен әһәмиятле ядкярләрнең табылуына өмет багларга нигез бар.

Русчадан ***Ленар Гобәйдуллин***
тәрҗемәсе

Искәрмәләр

ЯһММҮ – ТР ФА Г.Ибраһимов исемендәге ТӘһСИның Язма һәм музыкаль мирас үзәге, 39 ф., 6403 сак. бр.
Абуль-Гази, 1906 – Абуль-Гази. Родословное древо тюрков / перев. и предисл. Г.С.Саблукова. Казань, 1906.
Амирханов, 2010 – Амирханов Хусаин. Таварих-е Булгарийа (Булгарские хроники) / пер. со старотат., вступ. ст. и коммент. А.М.Ахунова. М., 2010.
Әбелгазый, 2007 – Әбелгазый Баһадир хан. Шәҗәрәи төрек. Казан, 2007.
Әмирхан, 1883 – Әмирхан углы Хөсәен. Тәварихы Болгария, өнтөхибә минәт-тәварихил-мөтәгаддидә вә минәррисалятил-мөтәгаддидә. Казан, 1883.
Бабер-наме, 1857 – Бабер-наме или Записки султана Бабера / Изд. в подлинном тексте Н.И[льминским]. – Казань, 1857.
Бабур-наме, 1958 – Бабур-наме. Записки Бабура / Перев. М.А.Салье. Таш., 1958.
Бартольд, 1963 – Бартольд В.В. Туркестан в эпоху монгольского нашествия // Академик В.В.Бартольд. Сочинения. Т. 1. М., 1963.
Библиотека, 1849 – Библиотека восточных историков, издаваемая И.Н.Березиным. Т. I: Шейбаниада. История монголо-тюрков. Казань, 1849.
Библиотека, 1854 – Библиотека восточных историков, издаваемая И. Березиным. Т. II. Ч.1: Сборник летописей: Татарский текст с русским предисловием. Казань, 1854.
Вельяминов-Зернов, 1863 – Вельяминов-Зернов В.В. Исследование о касимовских царях и царевичах. Ч. 1. СПб., 1863.
ал-Джаннаби, 1884 – Абу Мухаммад Мустафа ал-Джаннаби. Тухфат ал-ариб ва хадиййат ал-адиб // Тизенгаузен В.Г. Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды. Т. 1: Извлечения из сочинений арабских. СПб., 1884.
Зайончковский, 1969 – Зайончковский А. «Летопись Кипчакской степи» («Теварих-и Дешт-и Кипчак») как источник по истории Крыма // Восточные источники по истории народов Юго-Восточной и Центральной Европы. Т. 2. М., 1969.
Зайцев, 2009 – Зайцев И.В. Крымская историографическая традиция XV – XIX веков: пути развития: рукописи, тексты и источники. М., 2009.
Заходер, 1967 – Заходер Б.Н. Ширазский купец на Поволжье в 1438 г. // Заходер Б.Н. Каспийский свод сведений о Восточной Европе. Т. 2: Булгары, мадьяры, народы Севера, печенеги, русы, славяне. М., 1967.
Ибрагимов, 1956 – Ибрагимов С.К. Некоторые данные к истории казахов XV-XVI вв. // Известия АН Казахской ССР. – Серия истории, археологии и этнографии. – № 3. – А.-А., 1956.
История, 1937 – История Татарии в материалах и документах. М., 1937.
Кавагучи, Нагаминэ, 2010 – Кавагучи Т., Нагаминэ Х. Некоторые новые данные о «Чингиз-нама» Утемиша-хаджи в системе историографии в Дашт-и Кипчаке // Золотоордынская цивилизация. Сборник статей. Вып. 3. Казань, 2010.
Қадырғали, 1997 – Қадырғали Жалаир. Шежірелер жинағы. [Шағатай-казак тілінен ауда¬рып, алғы сөзін жазғандар Н.Мингулов, Б.Көмеков, С.Өтениязов. Жалпы редакциясын қараған М.Мағауин]. Алматы, 1997.
Қазақстан, 2005 – Қазақстан тарихы туралы түркі деректемелері. I том: Өтеміс қажы. Шыңғыс-наме. Алматы, 2005.
Кемпер, 2008 – Кемпер М. Суфии и учёные в Татарстане и Башкортостане: исламский дискурс под русским господством. Казань, 2008.
Кол Шәриф, 1997 – Кол Шәриф. И, күңел, бу дөньядыр... Казан, 1997.
Кол Шәриф, 2005 – Кол Шәриф һәм аның заманы = Кул Шариф и его время. Казань, 2005.
Крачковский, 2004 – Крачковский И.Ю. Арабская географическая литература. М., 2004.
Кухистани, 1969 – Масуд б. Усман Кухистани. Тарих-и Абу-л-Хайр-хани // Материалы по истории казахских ханств XV – XVIII вв. А.-А., 1969.
Кырыми, 1343 – ал-Хаджж Абд ал-Гаффар Кырыми. Умдат ат-таварих. Стамбул, 1343/1924-25.
Кятиб, 1141 – Кятиб Челеби. Тухфат ал-кибар фи асфар ал-бихар. Стамбул, 1141/1729.
Кятиб, 1145 – Кятиб Челеби. Джихан-нюма. Стамбул, 1145/1732.
Мәңгелеккә, 2006 – Мәңгелеккә аяк басканда = Навстречу вечности. Казань, 2006.
Мирастан, 2011 – Мирастан биш сәхифә: XVII-XIX гасырлар әдәби-тарихи ядкярләре / [транскр. эшләүче, хәзерге татар әд. теленә күчерүче, иск. һәм сүзл. төз., кереш мәкаләләр авт. С. Гыйләҗетдинов]. Казан, 2011.
Миргалеев, 2011 – Миргалеев И.М. «Чингиз-наме» Утемиша-хаджи: перспективы изучения // Золотоордынская цивилизация. Сборник статей. Вып. 4. Казань, 2011.
Муминов, 2012 – Муминов А. Суфизм в древних рукописях // Казахстанская правда. 9 ноября 2012 г. – http://www.kazpravda.kz/print/1352422834 .
Муркос, 1898 – Муркос Г.А. Путешествие антиохийского патриарха Макария в Россию в половине XVII века, описанное его сыном, архидиаконом Павлом Алеппским // Чтения в Обществе истории и древностей российских. Кн. 3 (189). М., 1898.
Мустакимов, 2008 – Мустакимов И. Термин «Золотой престол» в Поволжье по данным арабографичных источников (К вопросу о статусе г. Булгара на ордынском и постордынском пространстве) // Гасырлар авазы = Эхо веков. 2008. № 1.
Мустакимов, 2009а – Мустакимов И.А. Владения Шибана и Абу-л-Хайр-хана по данным «Таварих-и гузида – Нусрат-наме» // Национальная история татар: теоретико-методологическое введение. Казань, 2009.
Мустакимов, 2009б – Мустакимов И.А. Об одном списке «Дафтар-и Чингиз-наме» // Средневековые тюрко-татарские государства. Сборник статей. Вып. 1. Казань, 2009.
Мустакимов, 2010 – Мустакимов И.А. Владения Шибана и Шибанидов в XIII–XV вв. по данным некоторых арабографичных источников // Средневековые тюрко-татарские государства. Сборник статей. Вып. 2. Казань, 2010.
Мустакимов, 2011 – Мустакимов И.А. Сведения «Таварих-и гузида – Нусрат-наме» о владениях некоторых джучидов // Тюркологический сборник. 2009–2010. М., 2011.
Негри, 1844 – Негри А. Извлечения из турецкой рукописи Общества, содержащей историю крымских ханов // Записки Одесского общества истории и древностей. Одесса, 1844. Т. 1.
Орешкова, 1990 – Орешкова С.Ф. Османский источник второй половины XVII в. о султанской власти и некоторых особенностях социальной структуры османского общества // Османская империя: государственная власть и социально-политическая структура. М., 1990.
Остапчук, 2002 – Остапчук В. Хроника Реммаля Ходжи «История Сагиб Герей Хана» как источник по крымско-татарским походам // Источниковедение истории Улуса

Джучи (Золотой Орды). От Калки до Астрахани. 1223-1556. Казань, 2002.
Рахим, 2008 – Рахим А. Новые списки татарских летописей // Гали Рәхим: тарихи-документаль, әдәби һәм биографик җыентык / төз. Р.Мәрданов, И.Һадиев. Казан, 2008.
Салахетдинова, 1965 – Салахетдинова М.А. Об одном неизвестном персидском сочинении по истории народов Поволжья // Страны и народы Востока. География, этнография, история. М., 1965. Вып. IV.
Сеид, 1832 – Сеид Мухаммед Риза. Ассеб о-ссейяр, или Семь планет, содержащий историю крымских ханов от Менгли-Гирей хана 1-го до Менгли-Гирей хана 2-го. Казань, 1832.
Смирнов, 2005 – Смирнов В.Д. Крымское ханство под верховенством Отоманской Порты до начала XVIII в. М., 2005.
Султанов, 2005 – Султанов Т.И. Известия османского историка XVI в. Сейфи Челеби о народах Центральной Азии // Тюркологический сборник. 2003-2004: Тюркские народы в древности и средневековье. М., 2005.
Сыздыкова, 1989 – Сыздыкова Р.Г. Язык «Жами ат-таварих» Жалаири. А.-А., 1989.
Сыздықова, Қойгелдиев, 1991 – Сыздықова Р., Қойгелдиев М. Қадырғали би Қосымұлы және оның жылнамалар жинағы. Алматы, 1991.
Таварих, 1967 – Таварих-и гузида – Нусрат-наме / Исслед., критич. текст, аннот. огл. и табл. свод. огл. А.М.Акрамова. – Таш., 1967.
Таварих, 1969 – Таварих-и гузида-йи нусрат-наме // Материалы по истории казахских ханств XV–XVIII вв. А.-А., 1969.
Трепавлов, 2011 – Трепавлов В.В. Тюркские народы средневековой Евразии. Избранные труды. Казань, 2011.
Туған, 1994 – Туған Ә.В. Башкорттарзың тарихы. Өфө, 1994.
Усманов, 1972 – Усманов М.А. Татарские исторические источники XVII – XVIII вв. Казань, 1972.
Ўтамиш, 2009 – Ўтамиш Хожи ибн Мухаммад Дустий. Ўтамиш Хожи тарихи (XVI асрга оид тўркий тилда ёзилган тарихий манба). Тошкент, 2009.
Утемиш-хаджи, 1992 – Утемиш-хаджи. Чингиз-наме / Факсим., перев, транскр., примеч., исслед. В.П.Юдина; подгот. к изд. Ю.Г. Баранова; коммент. и указ. М.Х. Абусеитовой. А.-А., 1992.
Үзйәтгин, 2013 – Үзйәтгин М. Әстерханлы Шәрифинең 1550 елда язган «Зафәрнамә» се // Чын Мирас. 2013. № 5.
Франк, 2008 – Франк А.Дж. Исламская историография и «булгарская» идентичность татар и башкир в России. Казань, 2008.
Халим, 2004 – Халим Гирай Султан. Розовый куст ханов, или История Крыма / Перевод переложения А. Ильми 1909 г. и пояснения К.Усейнова 2004 г. Симферополь, 2004.
Халим-Гирай, 1287/1870 – Халим-Гирай Султан. Гулбун-и ханан, йахуд Кырым тарихи. Стамбул, 1287/1870.
Халим-Гирай, 1327/1909 – Халим-Гирай Султан. Гулбун-и ханан, йахуд Кырым тарихи. Стамбул, 1327/1909.
Шарифи, 1390 – Шариф ад-Дин Хусайн Шарифи. Джаддат ал-ашикин (Аз Ма-вара-ан-нахр та Харамайн-и Шарифайн). Гузариш-и сафар-и хаджж-и шайх Хусайн-и Хваризми. Сал-и 956-958 к[амари] / Би-кушиш-и Расул Джа'фарийан // Пайам-и Бахарестан. Осень 1390/2011 г. (на перс. яз.). – http://archive.ical.ir/files/payam/p13-0002.pdf.
Шәриф, 1995 – Шәриф Хаҗитархани. Казан вилаятенең җиңүе // Идел. – 1995. – № 1.
Шерифи, 1995 – Шерифи Х. «Зафер наме-и Вилайет-и Казан» //Гасырлар авазы = Эхо веков. 1995, май.
Эвлия, 1996 – Эвлия Челеби. Книга путешествий Эвлии Челеби. Походы с татарами и путешествия по Крыму (1641-1667 гг.). Симферополь, 1996
Эвлия, 1999 – Эвлия Челеби. Книга путешествий. Турецкий автор Эвлия Челеби о Крыме (1666-1667 гг.) /перев. и коммент. Е.В.Бахревского. Симферополь, 1999.
Эвлия, 2008 – Эвлия Челеби. Книга путешествия. Крым и сопредельные области. (Извлечения из сочинения турецкого путешественника XVII века) / Вступит. ст., перев. с османского яз., коммент. Е.В.Бахревского. Изд. 2-е. Симферополь, 2008.
Юдин, 1969а – Юдин В.П. [Введение к публикации отрывков из «Фатх-наме» Шади] // Материалы по истории казахских ханств XV–XVIII вв. А.-А., 1969.
Юдин, 1969б – Юдин В.П. [Введение к публикации отрывков из «Шайбани-наме» Камал ад-Дина Али Бинаи] // Материалы по истории казахских ханств XV–XVIII вв. А.-А., 1969.
Юдин, 1969в – Юдин В.П. [Введение к публикации отрывков из «Тарих-и Абу-л-Хайр-хани»] // Материалы по истории казахских ханств XV – XVIII вв. А.-А., 1969.
Юдин, 2001 – Юдин В.П. Персидские и тюркские источники по истории казахского народа XV-XVIII веков // В.П.Юдин. Центральная Азия в XIV-XVIII веках глазами востоковеда. Алматы, 2001.

Aboul-Ghazi, 1871 – Aboul-Ghazi Behadour Khan. Histoire des Mogols et des Tatares. Publ. par P.Desmaisons. T. I: Texte. St.-Petersbourg, 1871.
Fındıklılı, 1928 – Silâhdâr Fındıklılı Mehmed Ağa. Silâhdâr Tarihi. İstanbul, 1928. Cild I-II.
Hezarfen, 1998 – Hezarfen, Hűseyin Efendi. Telhisű'l-beyan fi kavanin-i Al-i Osman / Haz. S. İlgűrel. Ankara, 1998.
Ivanics, Usmanov, 2002 – Ivanics M., Usmanov M.A. Das Buch der Dschingis-Legende (Däftär-i Čingiz-nāmä). [Bd.] I. Szeged, 2002.
Kurat, 1972 – Kurat, A.N. IV-XVIII yy. da Karadeniz kuzeyindeki Türk kavimleri ve devletleri. Ankara, 1972.
Őtämiš, 2008 – Őtämiš Hājī. Čingīz-Nāma / Introduction, annotated translation,transcription and critical text by Takushi Kawaguchi, Hiroyuki Nagamine. Tokyo, 2008.
Őtemiş, 2009 – Őtemiş Hacı. Çengiz-Name / Haz. İ. Kamalov. Ankara, 2009.
Őzyetgin, 1993 – Őzyetgin, A.M. Astrahanlı Şerifi'nin 1550 Tarihli Zafer-name'si // Türkoloji Dergisi. XI. Cilt. 1. Sayı. Ankara, 1993.
Seydi, 1313 – Seydi Reis. Mir'atü'l-Memalik. Der-i Saadet, 1313/1895-1896.
Seydi, 1999 – Seydi Ali Reis. Mir'atü'l-Memalik / İnceleme-Metin-İndeks / Dr. Mehmet Kiremit. Ankara, 1999.
Tarih, 1973 – Tarih-i Sahib Giray Han / Neşr. Ö. Gökbilgin. Ankara, 1973.
Togan, 1965 – Togan, Z.V. Kazan Hanlığında İslam Türk Kültürü // İslam Tetkikleri Enstitüsü Dergisi. İstanbul, 1965. C. III. Sayı 3/4.
Togan, 1981a – Togan, A.Z.V. Bügünkü Türkili (Türkistan) ve Yakın Tarihi. Cilt I: Batı ve Kuzey Türkistan. İstanbul, 1981.
Togan, 1981b – Togan, A.Z.V. Umumi Türk Tarihine Giriş. Cild I: En eski devirlerden 16. asra kadar. İstanbul, 1981.
Togan, 1999 – Togan, İ. Altınordu Çözülürken: Kırım'a Giden Yol // Türk-Rus İlişkilerinde 500 Yıl (1491-1992). Ankara, 1999.
Zajaczkowski, 1966 – Zajaczkowski, A. La Chronique des Steppes Kiptchak Tevarih-i Deşt-i Qipcaq du XVIIe siècle. Warszawa, 1966. ■

ГАБДЕННАСЫЙР КУРСАВИ, ШИҺАБЕТДИН МӘРҖАНИ ҺӘМ ГАЛИМҖАН БАРУДИНЫҢ ЯҢА ТАБЫЛГАН КУЛЪЯЗМАЛАРЫ

ӘЛФРИТ БОСТАНОВ,
тарих фәннәре кандидаты,
Санкт-Петербургтагы Европа университеты ТАИФ профессоры

МИНЕМ ФИКЕРЕМЧӘ, БҮГЕН ТАТАР АРХЕОГРАФИЯСЕНЕҢ ИҢ МӨҺИМ БУРЫЧЫ –ӘДИПЛӘРЕБЕЗНЕҢ, ГАЛИМНӘРЕБЕЗНЕҢ МИРАСЫН, АЛАРНЫҢ ЯЗГАН ХЕЗМӘТЛӘРЕН КИҢ ҖӘМӘГАТЬЧЕЛЕККӘ ТӘКЪДИМ ИТҮ. БУ МИРАСНЫ ТАТАР ҺӘМ ИНГЛИЗ, РУС ТЕЛЛӘРЕНӘ ТӘРҖЕМӘ ИТЕП КЕНӘ ТҮГЕЛ, Ә ГАРӘПЧӘНЕ УКЫЙ БЕЛГӘН УКУЧЫЛАРГА ДА ҖИТКЕРЕП, СОВЕТ ЧОРЫННАН КАЛГАН КОНЦЕПЦИЯЛӘРДӘН АКРЫНЛАП АРЫНЫРГА КИРӘК, ДИП САНЫЙМ.

Соңгы елларда татар кулъязма мирасын өйрәнү, тикшерү, барлау эше шактый актив рәвештә бара. Казанда гына түгел, Көнбатыш илләрендәге хезмәттәшләребезнең дә бик кызыклы ачышлары турында еш ишетәбез. Шушы кыска гына мәкаләдә без археографик экспедициядә яңа табылган кулъязма чыганаклар турында берничә сүз әйтеп китәбез. Бу кулъязма мирас татар милләтенең иң күренекле һәм бөек затлары — Габденнасыйр Курсави (1776-1812), Шиһабетдин Мәрҗани (1818-1889) һәм Галимҗан Баруди (1857-1921) исемнәре белән бәйләнгән.

2012 елда Канаданың Монреал каласында ислам белгече, доктор Натан Спаннаус Габденнасыйр Курсавига багышланган диссертациясен яклады [1]. Галим, Санкт-Петербург һәм Казан китапханәләрендә эшләп, Курсавиның мәгълүм булган барлык әсәрләрен укып чыкты, аның фикерләрен һәм шул чордагы тарихи мохитне анализлап, шактый зур эш башкарды. Иң мөһиме — Н.Спаннаус Курсавиның татар фәнендә билгеле булмаган кулъязмаларын таба һәм аларның эчтәлекләрен өйрәнә. Әйтергә кирәк, татар тарихы өчен Төркия архивларының фондлары тиешле дәрәҗәдә өйрәнелмәгән. Мәсәлән,

доктор Н.Спаннаусның мәгълүматларына караганда, Истанбулда Курсавиның күпләргә бөтенләй билгеле булмаган ике кулъязма китабы саклана икән. Беренчесе — «Шәрх гала рисалә фи бәхсәс-сыйфат» [2], икенчесе — «Китаб фи бәйан әксамәл-хәдис» [3, 4]. Исемнәренә караганда, бу китаплар кәлам һәм хәдис фәннәре турында. Курсавиның тагын бер мөһим әсәре — «Шәрхәлгакаидән-нәсафия әл-җәдид» — Истанбулда [5] һәм Үзбәкстанның Нөкис каласында [6] саклана [7]. Курсавиның Н.Спаннаус кулланмаган ике томлык «Хәшия гала шәрхәлгакаидән-нәсафия [әл-җәдид]» исемле хезмәте Казанда — Татарстан Республикасы Милли музеенда борынгы язма чыганаклар белгече, археограф Зәйнәп Максудова (1897-1980) фондында бар. Бу кулъязмалар мелла Мөхәммәтсафа бине Мөхәммәтгали әл-Кәнави тарафыннан Гатаулла бине Мөхәммәди әл-Атави мәдрәсәсендә 1880-1881 елларда күчерелгән [8]. Доктор Н.Спаннаус Курсавиның хәнәфи фикъһенә багышланган «Шәрех мохтәсарәл-мәнар» әсәренең тулы нөсхәсе булмавы турында әйтә [9], әмма безгә бу хезмәтнең Төмән өлкәсе дәүләт музеенда саклана торган тулы нөсхәсе белгеле *(1 нче фото)* [10]. Без бу кулъязмага филология фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университетының өлкән укытучысы Илһам Гомәров белән уртак проектны гамәлгә ашырганда юлыктык. Һичшиксез, әлеге нөсхәне нигез итеп алып, әлеге әсәрнең тәнкыйди текстын бастырырга кирәк, чөнки бу — Курсавиның фикер-карашларын аңлар өчен, иң әһәмиятле китапларның берсе. Кызганыч ки, хәзерге заман укучыларына Курсавиның «Әл-иршад ли-л-гыйбад», «Тәфсир әл-бәян» исемле әсәрләре генә билгеле [11]. Курсавиның барлык кулъязмаларын да туплап, матур бер җыентык чыгарырга кирәктер, дип уйлыйм.



1. Габденнасыйр Курсави. «Шәрех мохтәсарәл-мәнар».
Төмән дәүләт музее. Шифр ВФ 6765, № 19064.

Шиһабетдин Мәрҗанинең мирасын барлаганда, без татар халкының Дагыстан белән элемтәләрен күз алдында тотарга тиешбез. Мондый элемтәләр бик борынгыдан килеп, безнең көннәргә кадәр дәвам итүенә карамастан, әлеге фәнни мәсьәлә тиешле дәрәҗәдә өйрәнелмәгән [12]. Мисал өчен Санкт-Петербург дәүләт университетының Көнчыгышны өйрәнү факультеты китапханәсендә татар шәкерте тарафыннан күчерелгән бер Дагыстан галименең «Тәзкиратәррагибин фи тәгърифат голүм» исемле әсәре саклана [13]. Казанда да Дагыстан галимнәренең кулъязмаларын очратырга була, шул исәптән Дагыстан



2. Шиһабетдин Мәрҗани. «Вафийәтел-әслаф...»ның бер бите.
Дагыстан фәнни мәркәзенең Тарих, археология һәм этнография институты (Махачкала шәһәре), М.-С. Сәетов архивы, № 90

авыл мәчетләренең китапханәләре һәм андагы шәхси архивлар, Казан басма китаплары белән шыплап тулган. Шундый кызыклы чыганакларның кайберләре безнең кулыбызга да килеп эләкте. Мәсәлән, атаклы Дагыстан галиме, энциклопедист Нәзир əд-Дүргәлинең (1891-1935) хезмәтләрен өйрәнү вакытында [14] археограф, текстолог, тарих фәннәре кандидаты Шамил Шихалиев белән Мәрҗанинең әсәрен таптык *(2 нче фото)*. Кулъязма җыентык авар халкының күренекле галиме Мөхәммәтсәет Сәетовның (1902-1985) архивында саклана [15]. Нәзир әд-Дүргәли материалларны төрле басма чыганаклардан туплаган. Китапның «Тарихәл-фәлсәфә вә-л-голүм вә гайриһа» өлешендә Мәрҗанинең «Вафиййат әл-әслаф вә тахиййат әл-әхлаф» әсәренең кайбер бүлекләре кергән [16]. Һәр бүлектән соң Нәзир әд-Дүргәли бу текстның ничәнче битләрдән алынганын күрсәткән. Димәк, Нәзир әд-Дүргәлинең кулында «Вафийәтел-әслаф...»ның бер нөсхәсе булган, ләкин безгә ул кулъязма әлегә кадәр билгеле түгел яисә ул сакланмаган [17]. «Вафийәтел-әслаф...» — Мәрҗанинең гомер буе язган әсәре, галимнең иң бөек тарихи һәйкәле [18]. Бу китапны да чыганак телдә һәм тәрҗемә итеп бастыру — татар фәненең изге бурычы. Әлеге эштә Махачкала каласында саклана торган кулъязма да ярдәм итәр, дип уйлыйм.

Шулай ук Мәрҗанинең «Хашия галә шәрхәш-шәмсия» мәнзумәсе (шигырь белән язылган әсәре) ике нөсхәдә билгеле. Бу кулъязмаларның икесе дә Мөхәммәтсафа әл-Кәнави тарафыннан шул ук Гатаулла әл-Атави мәдрәсәсендә 1880 елларда күчерелгән һәм хәзерге вакытта алар Татарстан Милли музеенда саклана [19]. «Мәрҗани» җыентыгында тәкъдим ителгән Шиһабетдин хәзрәтләренең язган китаплары исемлегендә бу әсәр «Шәрх мөкәддимә әр-рисаләтәш-шәмсия» исеме белән белдерелгән, дигән фикердә торабыз [20].

2013 елның июнендә Дагыстан җөмһүриятенең Карабудахкент исемле авылына археографик экспедиция оештырылды. Экспедициядә Шамил Шихалиев, Галәметдин Шәехаләви һәм Әлфрит Бостанов катнашты. Нәтиҗәдә, авылның җамигъ мәчетендәге гарәп, комык телләрендә язылган кулъязмаларны һәм иске басма китапларны тикшергәндә, Мәрҗанинең тагын бер әсәрен таптык *(3 нче фото)*. 17х22 см зурлыктагы кулъязма җыентык өч

өлештән гыйбарәт: дагыстанлы галимнәр Сәлим әфәнде әл-Мөнир (1б-6а битләр) һәм Габделхәлим әс-Согуринең (7а-14б битләр) фикъһе мәсьәләләре белән бәйле әсәрләреннән соң, Мәрҗанинең «Әл-бәркәл-вамид фи радд гала-л-багидәл-мусамма би-н-нәкид» әсәренең [21] ураза турындагы бер өлеше кертелгән (15б-19б битләр). Бу текст XIX гасыр ахырында яисә XX йөз башында мелла Гаделхан бине хан Гали әт-Торгули тарафыннан күчерелгән. Әлеге әсәрдән соң Ш.Мәрҗанине мактаган шигырьләр тәкъдим ителә. Аларны 1884-1885 елларда Мәрҗанинең дагыстанлы шәкерте Габделлатыйф бине Мөхәммәт әд-Дагыстани әл-Хәмзави әл-Хуҗи әл-Җәнгули әл-Әшгари әш-Шафигый Казанда Мәрҗанинең мәдрәсәсендә укыганда («фи-л-мәдрәсә әш-шамихә әш-Шиһабия») язган.



3. Шиһабетдин Мәрҗанинең «Әл-бәркәл-вамид»ының бер бите.
Карабудахкент авылы мәчете (Дагыстан Республикасы). 55 нче кулъязма

Галимҗан Барудиның шәхесенә нисбәтле кулъязмага уйламаганда юлыктык. 2007 елның җәендә Омск өлкәсе Ташыткан авылындагы мәчет китаплары арасында Галимҗан Барудиның автографы табылды *(4 нче фото)*. Шушы кечкенә генә (13,5х13,7) кулъязма фрагментта имам ән-Нәвавинең «Кырык хәдис» китабына рөхсәтнамәсе язылган: «Зикер санад хадимәл-гыйлем бимәдинәти Казан Галимҗан бине Мөхәммәтҗан әл-Баруди ли-китабәл-арбагыйн». Бу иҗазәт (рөхсәт язуы) мәүлана Зыяэтдин Әхмәт бине Мостафа әл-Гөмешханәви (1813-1894) тарафыннан бирелгән, димәк, кулъязма да XIX гасыр ахырында язылган. Кызганыч ки, иҗазәтнамәнең ахыры ертылган, аның беренче унбер юлы гына сакланган. Шулай да бу гаҗәеп табыш татарлар күпләп яшәгән төбәкләрдә, аеруча кечкенә авылларда, хәзер дә саклана торган иске китапларның әһәмияте зур булуын күрсәтә.

Мәкаләбезнең ахырында, янәдән, алда әйтелгән фикерне кабатлап үтәргә телибез. Татар халкы тарихы өчен файдалы булган чыганакларны чит ил, Казан, Санкт-Петербург архив, китапханәләрендә һәм татар авылларында табарга мөмкин. Аеруча зур игътибарны Дагыстанның бай шәхси һәм дәүләт кулъязма архивларына юнәлтү зарур. Татар әдипләренең китапларын оригиналда һәм тәрҗемә итеп, хәзерге заман укучыларына җиткерү кирәк. Гомумән, халкыбызның мирасын барлап, борынгы бөек галимнәребезне зурлап, аларның абруен күтәрсәк, хәзерге заман мәсьәләләрен дә хәл итәргә җиңелрәк булыр иде, дип уйлыйбыз.



4. Шәех Зыяэтдин әл-Гөмешханәви тарафыннан Галимҗан Барудига бирелгән иҗазәтнамәсе. Ташыткан авылы мәчете (Омск өлкәсе)

Искәрмәләр

1. Nathan Spannaus. Islamic Thought and Revivalism in the Russian Empire: an Intellectual Biography of Abu Nasr Qursawi (1776-1812). – PhD Thesis: McGill University, Montreal, 2012. – 275 p.
2. Suleymaniye Kütüphanesi, Izmirlı Ismail Hakkı, no.906.
3. Amasya Il Halk Kütüphanesi, no.1785.
4. Nathan Spannaus. Islamic Thought and Revivalism. – p.31, footnote 88.
5. Hacı Mahmud Efendi, no.1394.
6. Каракалпак Автономияле Республикасының дәүләт музее, КР737- 94/Х, 255б-347 б. [Ashirbek Muminov, Maria Szuppe, Abdusalim Idrisov. Manuscrits en écriture arabe du muse regional de Nukus (République Autonome du Karakalpakstan, Ouzbékistan). Fonds arabe, person, turki et karakalpak (Roma, 2007), description no.72].
7. Nathan Spannaus. Islamic Thought and Revivalism. – p.33, footnote 98.
8. Татарстан Республикасы Милли музее. №18369-56, 5а-130б; №18369-61, 284 б. Колофоннар бар.
9. Nathan Spannaus. Islamic Thought and Revivalism. – p.36.
10. ВФ 6765, №19064, 133 бит, XIX гасырның беренче яртысында күчерелгән. Карагыз: Бустанов А.К. Книжная культура сибирских мусульман. – М.: Издательский дом «Марджани», 2013 – С.51, 60. Әлеге кулъязманың тарихы монда да бераз яктыртылган.
11. Курсави Габдуннасыр. Наставление людей на путь истины (ал-Иршад ли-л-‘ибад) / Пер. с араб. Г.Идиятуллиной. – Казань: Татар.кн.изд.-во, 2005; Курсави Габдуннасыр. Тафсир ал-байан / Сост., пер. со старотатар. и араб. Р.Адыгамова. – Казань: Татар. кн.изд.-во, 2012.
12. Кайбер мәгълүматлар белән шушы чыганаклар аша таныша аласыз: Michael Kemper. Daghestani Shaykhs and Scholars in Russian Exile: Networks of Sufism, Fatwas and Poetry. – Moshe Gammer and David J.Wasserstein (eds.), Daghestan in the World of Islam. – Helsinki, 2006. – P.95-107; Усманов М.А. Книги-путешественницы // Дагестан и мусульманский Восток. Сборник статей / Под редакцией А.К.Аликберова и В.О.Бобровникова. – М.: Издательский дом «Марджани», 2010.
13. Кулъязма XIX гасырның беренче яртысында күчерелгән. Арабские рукописи Восточного отдела Научной библиотеки Санкт-Петербургского государственного университета. Краткий каталог / Составители: О.Б.Фролова, Т.П.Дерягина. – Санкт-Петербург, 1996. – С.47.
14. Назир ад-Дургели. Услада умов в биографиях дагестанских учёных (Нузхат ал-азхан фи тараджи улама Дагистан). Дагестанские учёные X-XX веков и их сочинения / Перевод с арабского, комментарии, факсимиле, указатели и библиография подготовлены А.Р.Шихсаидовым, М.Кемпером и А.К.Бустановым. – М.: Издательский дом «Марджани», 2012.
15. РФА Дагыстан фәнни үзәгенең Тарих, археология һәм этнография институты. М.Сәетов фонды. Кәгазьгә карап, бу китап 1920 елларда күчерелгән, дип уйларга мөмкин. Сәетовның тәрҗемәи хәлен моннан карагыз: Michael Kemper. How to Reconcile the Islamic Past with the Soviet Present? Mirasism in the Post-Stalinist Daghestan. – NISIS Studies volume, 2013.
16. «Фәсел фи-л-голүм»: «Гыйлемәл-лисанәл-гарәби», «Гыйлемәт-тарих», «Гыйлемәт-тәсаввуф», 420а-425а; «Әснафәл-голүмәл-гакълия», 426а-429а; «Гыйлемәл-һәндәсә», 429а-б; «Гыйлемәл-һәйа», 429б-430а; «Гыйлемәл-җәгърафия», 430а-442б; «Тарихан-нокуд кабләл-ислам вә бәгъд», 443а-448а; «Әнвагәс-сәнаигәл-гыйльмия», 448б-455а.
17. Гомумән, Нәзир әд-Дүргәли китапханәсендә татар китапларын күпләп очратырга мөмкин. Биредә «Шура» һәм «Дин вә мәгыйшәт» журналлары да бар. Әд-Дүргәли китапханәсенең күп кенә ядкярләре Мөхәммәтсәет Сәетовның архивында саклана.
18. Билгеле булганча, бу әсәрнең нөсхәләре Казан (Идел буе) федераль университеты китапханәсендә саклана: КФУ ФК КСКБ, 609г-615г.
19.ТР ММ. №18369-19, 4б-11б; №18369-56,144б-155б.
20. Мәрҗани. Мәрҗани виладатенә 100 ел тулу мөнәсәбәте илә нәшер ителде. – Казан: Мәгариф, 1915. – 368 б.
21. Бу әсәрнең эчтәлеге турында карагыз: Марджани Ш. Зрелая мудрость в разъяснении догматов ан-Насафи (ал-Хикма ал-балига) / Предисл. и пер. с араб. Д.Шагавиева. – Казань: Татар.кн.изд.-во, 2008. – С.87-88. ■

ҖӘМАЛЕТДИН ӘЛ-ӘФГАНИ ҺӘМ РИЗАЭДДИН ФӘХРЕДДИН

ДАМИР-СӘЕД ШАҺАБИ,
тарих фәннәре кандидаты,
Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының иҗтимагый фикер тарихы һәм исламны өйрәнү бүлеге мөдире

...«МОСКОВСКИЕ ВЕДОМОСТИ» ГАЗЕТАСЫ ХӘБӘР ИТҮЕНӘ КАРАГАНДА, 1888 ЕЛДА ШӘЕХ ҖӘМАЛЕТДИН ӘЛ-ӘФГАНИ (1839-1897)* ИРАННАН БАКУ АША МӘСКӘҮ ҺӘМ САНКТ-ПЕТЕРБУРГКА КИЛӘ. УЛ САНКТ-ПЕТЕРБУРГ КАЛАСЫНДА ЯШӘГӘН ВАКЫТТА [1] ҖИРЛЕ МӨСЕЛМАННАР БЕЛӘН ОЧРАШКАН, БИРЕДӘ ХӨРМӘТЛЕ КУНАК КАТНАШЫНДА УЗГАН МӘҖЛЕСЛӘРДӘ ИСЛАМ ҖӘМГЫЯТЕНЕҢ МӨҺИМ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ ТИКШЕРЕЛГӘН. ӘЛ-ӘФГАНИ АНДА РОССИЯДӘГЕ МӨСЕЛМАННАРНЫҢ ХӘЛЕ ТУРЫНДАГЫ ФИКЕРЛӘРЕ БЕЛӘН ДӘ УРТАКЛАШКАН.

Җәмалетдин әл-Әфганинең килүе Россия галимнәре өчен дә файдалы булган, алар кунакны Россия география җәмгыятенә әгъза итеп кабул иткән. Россия империясе башкаласында ул татар халкы белән дә танышкан, аларга аерым өметләр баглаган. Соңыннан, татарлар Мәккәгә хаҗ сәфәренә барганда, Истанбулда туктап, Җәмалетдин әл-Әфгани уздырган фәнни җыелышларда һәм түгәрәкләрдә катнашырга тырышканнар. Ул заман татар зыялыларының берсе әйтүенчә, Җәмалетдин татарларга ифрат дәрәҗәдә зур игътибар биргән, ә татарларның бабаларын

* Җәмалетдин әл-Әфгани (1839-1897) — ислам дөньясының мәшһүр дин һәм сәясәт эшлеклесе. 1858-1869 елларда Әфганстан әмирләрендә хезмәт итә. 1871-1879 елларда Мисырның иҗтимагый һәм сәяси тормышында катнаша. 1879 елда Александрия (Мисыр) шәһәрендә «Яшь мисырлылар җәмгыяте»н төзи. Актив сәяси эшчәнлеге өчен Мисырдан сөрелә. 1884 елда Парижда, М.Габдүһ белән берлектә, панисламизм идеяләрен пропагандалаган «Әл-Гурватүл-вуска» атналык газетасын нәшер итә. (Татар энциклопедия сүзлеге. — 1 т. — Казан, 2008. — 66 б.). Җәмалетдин әл-Әфганинең вафатыннан соң, аның эшчәнлеген шәкерте, танылган Мисыр мөфтие, җәмәгать эшлеклесе, реформатор Мөхәммәд Габдүһ (1849-1905) дәвам итә. *(Ред.)*

Ризаэддин Фәхреддиннең беренче фоторәсеме. Уфа, 1892 ел

искә алгач, хөрмәт күрсәтү гыйбарәсе «рәхиməһумуллаһ» («Аллаһ аларны рәхим-шәфкатеннән ташламасын!») [2] сүзләрен әйтә торган булган [3].

Ризаэддин Фәхреддин нәкъ менә Санкт-Петербург каласында ислам дөньясының мәшһүр шәхесе Җәмалетдин әл-Әфгани белән очрашкан. Бу очрашу Ризаэддин Фәхреддиннең шәхес буларак формалашуына гаять зур йогынты ясый. Очрашуның уңай йогынтысы хакында галим үзе һәм аның замандашлары күп тапкырлар искә алган, хәзерге галимнәрнең дә бу турыда язмалары бар [4]. Ризаэддин Фәхреддин Шиһабетдин Мәрҗанинең (1818-1889) 100 еллык юбилеена багышланган җыентыгындагы мәкаләсендә үзенә әлеге олы галим белән аралашырга, аннан сабак алырга насыйп булмаган өчен үкенгәнен хәбәр итә, ә әл-Әфгани шәех белән озак итеп әңгәмә кору бәхете тиюенә Аллаһка рәхмәт укый. Ризаэддин Фәхреддин язуынча, шәех күп хакыйкатьләргә аның күзен ачкан [5]. Ул болай дип яза: «Мәрҗани сохбәтеннән мәхрүм булуым әл-Әфгани

илә озын вакыт сохбәт кылуыма сәбәп булды. Әлхәмдүлилләһи галә кулли халь» [6].

Санкт-Петербургка Ризаэддин Фәхреддин биредәге хәрби округның ахуны чакыруы буенча бара. Ул соңыннан Җәмалетдин әл-Әфгани белән очрашуга әзерлеге булмавын, аңа лаек түгеллеген, атаклы ислам фикер иясен сәламләгәч тә, янынннан китәргә теләвен язып калдырган, ләкин, үз сүзләре белән әйткәндә, аны «ниндидер бер көч берничә минутка тоткарланырга мәҗбүр итә» [7]. Үзенең автобиографиясендә бу очрашу турында: «Петербургта вакытта миңа атаклы мөселман философы Җәмалетдин әл-Әфганидә кунакта булырга туры килде. Анда миңа мин лаек булмаган кадәр хөрмәт күрсәттеләр», — дип яза [8].

Җәмалетдин әл-Әфгани Ризаэддин Фәхреддинне үзен игътибар белән тыңлаучыны гына түгел, ә кызыклы әңгәмәдәш итеп тә күргән булса кирәк, чөнки 29 яшьлек имам-хатыйб һәм мөдәррисне көне буе үзендә тоткан. Ризаэддин Фәхреддин язганча, ул «бу шәехтән үз тормышында башка беркайчан да ишетергә туры килмәгән гыйлем һәм фикерләрне ишетү бәхетенә ирешкән һәм моннан зур ләззәт тә алган». Яшь имамга әңгәмәдәше киләчәктәге мөселман дөньясы, аның яңарыш юллары, әлеге процесста исламның роле турындагы концепциясен бәян иткән булса кирәк. Ризаэддин Фәхреддин шәех Җәмалетдин әл-Әфганинең: «Ислам үзенең хаклыгын бар дөньяда исбат итте инде. Европаның бүгенге динсезлеге — христианлык белән ислам арасындагы күпер генә, алар (европалылар — Ф.Б.) анда озак кала алмаячаклар, безгә (исламга) күчәчәкләр», — дигән сүзләрен китерә [9].

Уфага кайткач, яшь Ризаэддин, әл-Әфгани белән булган очрашу тәэсиратлары йогынтысында, үз-үзенә имтихан үткәрә һәм үзенең «гыйлем һәм игелеклелек» ягыннан бай булмавы, «авыл мәдрәсәсендә алынган дан ялган дан булган»лыгы турында нәтиҗәләргә килә. «Шулвакытта мин Җәмалетдин шәехтән ишеткән сүзләрнең хак булуына инандым, — дип яза Ризаэддин Фәхреддин, — күп сүзләрнең мәгънәләрен аңлый башладым, аларны күңелдә сакладым, мөстәкыйль рәвештә фән белән шөгыльләнә башладым. Аллаһка шөкер, мин үземнең инануларымны да тәртипкә сала алдым, гыйбадәт кылу һәм ураза тоту кебек бар гамәлләремне дә кабаттан тикшереп чыктым, төрле шәрехләрне, тәфсирләрне, аеруча хәдисләр гыйлемен, китапларны өйрәндем, вакытлы матбугат һәм яңа басылган әсәрләр белән шөгыльләндем. Төркиядә, Болгариядә, Мисырда, Америкада һәм Европада нәшер ителгән газета һәм журналларга язылдым. Аллаһы Тәгалә рәхмәте белән, минем бу тырышлыкларым бушка китмәделәр, заяга да булмадылар, гәрчә тиешле камиллеккә ирешә алмасам да, билгеле бер күләмдә мин гыйлем үзләштерә алдым» [10]. Чагыштыру өчен тагын бер мисал китерик: Мөхәммәд Габдүһ тә, Җәмалетдин белән танышканга кадәр, үзенең «сукыр, саңгырау һәм телсез» булуы турында язган [11].

Әлеге сүзләр Җәмалетдин әл-Әфгани абруена һәм аның Ризаэддин Фәхреддингә көчле йогынты ясавына дәлил булып тора. Бу очрашудан соң Ризаэддин Фәхреддиннең дөньяга карашында глобаль үзгәрешләр булган. Булачак ахун һәм мөфти тәкълид «яссылыгыннан» иҗтиһадка шулвакытта күчкән булса кирәк. Шуңа да ул үзенең бар инануларын һәм дини гамәлләрен яңадан тикшереп, күздән үткәргән. Нәкъ менә шулвакыттан, ягъни 1888 елдан башлап, Ризаэддин хәзрәт гыйльми эш белән тагын да активрак шөгыльләнә башлый һәм язылган хезмәтләрен бастыруга да керешә [12]. Бу вакыйгадан соң ул Илбәк авы-

лында ике ел имам булып эшли һәм 1891 елда, мөфти М.Солтанов чакыруы буенча, Уфага күченә, ә аннары Мәхкәмәи шәргыя Оренбургия әгъзасы була.

«Шура» журналының «Мәшһүр адәмнәр вә олуг хадисәләр» сәхифәсе кергән ун саны рәттән әс-Сәед [13] Җәмалетдингә багышлана (1917, №14-24). Әлеге күләмле мәкалә нигезендә без әл-Әфганинең Ризаэддин Фәхреддингә ясаган йогынтысының никадәр көчле булуы, аның бу гыйлем иясен ни дәрәҗәдә яратуы турында фикер йөртә алабыз. «Шура» журналында «Мәшһүр адәмнәр...» сәхифәсен Ризаэддин Фәхреддин үзе алып барган. Анда Аристотель, Платон, Алишер Нәваи, Әбүгалисина, хәлифә Могавия, Бату хан, ибне Хәлдун, ибне Фадлан, Ломоносов, Нобель, Мидхәт-паша, Декарт, Герберт Спенсер, Каюм Насыйри, Мәрҗани, Гаспралы һ.б. бик күп шәхесләр турында мәгълүмат бирелә. Кайбер тикшерүчеләрнең исәпләве буенча, бу сәхифәдә 180 күренекле шәхеснең тормыш юлы яктыртылган [14]. Әл-Әфганигә багышланган мәкаләнең күләмлелеге, әлбәттә, аның ислам дөньясының иң әһәмиятле шәхесе булганлыгы турында сөйли, шул сәбәпле «Шура» журналының мөхәррире галимнең тормыш юлын һәм идеяләрен укучыларга җиткерергә тырышкан. Ризаэддин Фәхреддин өчен Җәмалетдин әл-Әфгани һәр зыялы кеше белергә тиешле заман герое булган һәм аны төрле тәнкыйть-һөҗүмнәрдән якларга тырышкан.

«Шура» журналының 1917 елгы 14 нче санында Ризаэддин Фәхреддин Җәмалетдин шәехнең нәсел-нәсәбе турында төрле фикерләр булуын хәбәр итә. Мәсәлән, ул фарсы галиме Мөхәммәд Хәсән Ханның бу турыдагы фикерен китерә. Аның фикеренчә, Җәмалетдин Ирандагы Асадабад шәһәрендә туган. Ул шул ук вакытта Әхмәдбәк Агаевның әл-Әфгани белән өч тапкыр очрашуы, шәехнең әти-әнисенең Ирандагы Марага шәһәреннән булуы, аларның Хамедан шәһәренә күчүләре, үзенең шунда дөньяга килүе турында сөйләгәнен, «Төрек йорты» журналында бу хакта язып чыгуын да хәбәр итә [15]. Монда иң мөһиме — Агаев тарафыннан Җәмалетдин шәех төрки кавемнән булуы турындагы мәгълүмат китерелүе, чөнки Марагада төркиләр (азәрбайҗаннар) яшәгән була. Агаев әл-Әфгани белән әңгәмәсен дә төрки (азәрбайҗан) телдә алып бара. Ризаэддин Фәхреддин, бу һәм моңа охшаш фикерләрне анализлап, әл-Әфганинең төрки булуы турында әлеге сүзләрдә җитди дәлил юк, дип исәпли. Беренчедән, шәех күп телләр белгән, икенчедән, аның иранлы булуын күрсәтә торган анык дәлилләр юк. Ризаэддин Фәхреддин Җәмалетдиннең мәшһүр шәкертләре Габделкадыйр әл-Мәгриби һәм Мөхәммәд Габдүһләрнең фикерләренә кушыла. Алар үз остазларының сөнни һәм хәнәфи булуын, Әфганстандагы Асадабад шәһәреннән икәнлеген анык раслаганнар. Ризаэддин, әл-Әфганинең шәкертләре хатирәләренә таянып, мондый фикер каршылыкларының сәбәпләрен һәм чыганакларын ачыкларга тырыша [16]. Галим өчен үзенең рухи остазын яхшы яктан гына күрсәтү актуаль һәм мөһим булуы аңлашыла, чөнки ул җәдидчелек хәрәкәтенең рухи юлбашчысы була. Билгеле булганча, кадимчеләр, җәдидчеләрне тәнкыйть итүдә бер мөмкинлекне дә кулдан ычкындырмаган, шул исәптән Җәмалетдин әл-Әфганинең шигый тамырлары булу ихтималын күрсәтеп китүне дә файдаланганнар.

Бу уңайдан «Шура» журналында дөнья күргән «Шәех Җәмалетдин һәм Мөхәммәд Габдүһ» дип аталган икенче мәкалә бик кызыклы. Анда кайбер кешеләрнең Җәмалетдинне динсезлектә гаепләп чыгулары өстенә,

ваһһабилыкта да гаепли башлаулары турында әйтелә. Мәкаләдә Гарәбстанда иң бөек кешеләрне ваһһабилыкта, Төркестанда — масонлыкта, Персиядә — бабизмда, Россиядә — дәһрилектә (атеизмда) һәм марыйкылыкта (еретиклыкта) гаеплиләр, дип язылган [17]. Мәкалә авторы: «Халык хокукы өчен чынлап та көрәшкән, аларның тәрәккыяте өчен шулай тырышкан һәм үз-үзләрен шул юлда корбан иткән кешеләрне мөселманнар ни өчен шулай яманлыйлар?» — дип, әрнеп сорау куя [18].

Ризаэддин Фәхреддин үз рухи остазының әфганлы һәм сөнни булуын яклаcа да, сүзенең ахырында бәхәсне чын мөселманнарча йомгаклап куя. «Аның фарсымы [19] яки әфганлымы, төркиме яисә гарәпме булуы, Хамеданда туганмы ул, әллә инде Асадабадтамы — һич кенә дә мөһим түгел, ә иң мөһиме — ул кылган эшләр һәм гамәлләр» [20], — дип яза.

Хакыйкать өчен хәзерге галимнәрнең Җәмалетдин әл-Әфганине шигый һәм фарсы чыгышлы булуын исбат итүләрен дә әйтеп китәргә кирәк. 2008 елның ноябрендә миңа Иранда Җәмалетдин әл-Әфганигә (әл-Асадабадига) багышланган халыкара конференциядә катнашырга туры килде. Анда моның анык дәлилләре китерелде. Аңа кадәр дә безгә гарәп телендәге фәнни әдәбиятта әл-Әфганинең фарсы чыгышлы булуын исбатлаган кайбер чыганаклар белән танышырга туры килгән иде. Җәмалетдин шәех сөнниләр арасында танылмас өчен, динне яшерүнең шигый принцибын (такыя) файдаланган. Дөрестән дә, ул күпмедер вакыт Әфганстанда яшәгән. Фарсы телен белгән кешегә кыска гына вакыт эчендә дари сөйләшен (әфган фарсычасын) үзләштерү катлаулы эш түгел. Шул ук Әфганстанда сөнниләрнең хәнәфи мәзһәбен дә камил дәрәҗәдә өйрәнергә була. Гәрчә яшь Җәмалетдингә аны Гыйрактагы Нәҗәф каласында укыган чорында ук өйрәнү мөмкинлеге булган.

Ризаэддин Фәхреддин Җәмалетдинне башка хезмәтләрендә дә искә ала. Мәсәлән, Мөхәммәд (с.г.в.) пәйгамбәребезнең хәдисләренә аңлатма буларак иҗат ителгән «Җәвамигуль кәлим шәрхе» хезмәтендә ул түбәндәгеләрне яза: «Ислам дөньясында инде ни өчен ибне Рөшд вә Газалиләр, Фараби вә ибне Синалар, Табари вә ибне әл-Әсирләр заһир булмый?» — эчтәлегендә сүз сораучы бер дәрвишкә Шәех Җәмалетдин әл-Әфгани хәзрәтләренең: «Элек заманда ислам дөньясында тәрбия вә тәгълим [укыту] ысулы яхшы иде, соң вакытларда бозылды, бу көнге ысул әүвәлге заманнарда дәстүр [кагыйдә] тотылган булса иде, ибне Рөшдләр дә заһир булмаган булыр иде, тәрбия вә тәгълим ысулы төзелсә, Табари вә ибне әл-Әсирләр моннан соң да заһир булыр», — дип җавап биргәнен үзем ишеттем» [21]. Икенче урында Ризаэддин Фәхреддин, надан шәех һәм муллалар турында фикер йөртеп, шундый сүзләр әйтә: «Шәех Җәмалетдин вә Мөхәммәд Габдүһ кебек хакыйкый вә хәмиятьле [яклаучы] галимнәрне яратмыйлар вә һәрвакыт гавам арасына алар хакында яман сүзләр нәшер кылалар. Болар каршында Җәмалетдин белән Мөхәммәд Габдүһнең гаебе мөселманнарны укырга тәшвикъ итүләре [кызыксындырулары] вә Аллаһы Тәгаләдән башкадан истиганә [ярдәм сорауны] вә истимдадны [булышлык сорауны] манигъ кылулары, иҗтимагый сөннәтләр вә кәүнәен [матди һәм рухи дөнья] низамнарга муафикъ дөнья көтүккә димләүләредер» [22].

Үзенең «Ибне Тәймия» исемле китабында ул урта гасырлар дин галимнәре ибнеТәймия һәм аның шәкерте ибне әл-Каййим әл-Җәүзиййәне Җәмалетдин әл-Әфгани һәм шәкерте Мөхәммәд Габдүһ белән чагыштыра [23]. Автор бу китабында ибне Тәймия адресына

мактаулар ирештергән вакытта да, үзенең Җәмалетдин әл-Әфгани белән Петербургта очрашуы турында яза. Әл-Әфгани шәех ибне Тәймиянең «Әл-Җәваб әс-сахих ли-мән бәддәлә дин әл-Мәсих» («Гайсә динен бозган кешегә хак җавап») исемле хезмәтен югары бәяли торган булган. Ул Ризаэддин Фәхреддинне әлеге китап белән таныштыра һәм мөселманнар ибне Тәймиягә бу хезмәте өчен рәхмәтле булырга тиеш, ди [24].

Әлеге мәкаләбез белән без атаклы татар мәгърифәтчесе һәм фикер иясе Ризаэддин Фәхреддиннең Җәмалетдин әл-Әфгани йогынтысы астында булуын, аның шәхесе, идеяләре, эшгамәлләренә соклануын күрсәтергә теләдек. Галимнең Петербургта шәех белән озакка сузылган бер генә очрашуы булганмы яки берничә тапкыр очрашканмы — төгәл генә әйтә алмыйбыз. Тик бу очрашуның (яки очрашуларның) күренекле татар галиме эшчәнлегендә, аның мөселман җәмгыятендәге бер халәттән күпкә югарырак икенче халәткә күчү ноктасы булуын ышанып әйтә алабыз.

Русчадан ***Нияз Сабирҗанов*** *тәрҗемәсе*

Искәрмәләр

1. 17-18 айга якын.
2. Бу гыйбарәне ислам галимнәренең исемнәре аталганнан соң әйтү кабул ителгән.
3. Фәхреддин Р. Шәех Җәмалетдин // Шура. — 1917. — №16. — Б.364.
4. Моны исбат итәр өчен, Ф.Н.Баишевның «Ризаэддин Фәхреддиновның иҗтимагый-сәяси һәм әхлакый-этик карашлары» (Уфа: Китап, 1996) исемле хезмәте белән танышу да җитә.
5. Бу Р.Фәхреддиннең 1886 елда Мәрҗани белән булган уңышсыз очрашуына нисбәтле әйтелгән.
6. Фәхреддин Р. Мәрҗани // Мәрҗани [җыентыгы]. — Казан: «Иман» нәшрияты, 2001. — 181 б.; Фәхреддин Р. Болгар вә Казан төрекләре. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1993. — Б.153-154.
7. Баишев Ф.Н. Ризаэддин Фәхреддиновның иҗтимагый-сәяси һәм әхлакый-этик карашлары. — Уфа: Китап, 1996. — Б.48; РФА ФҮ УФА. 7 нче фонд, 1 нче тасв., 17 нче эш (иске акт). 32 б.
8. Фәхреддинов Р. Фәнни-биографик җыентык. — Казан: «Рухият», 1999.
9. Баишев Ф.Н. Күрсәтелгән хезм. — Б.48.
10. Баишев Ф.Н. Күрсәтелгән хезм. — Б.49; РФА ФҮ УФА. 7 нче фонд, 1 нче тасв., 12 нче эш (яңа акт). Б.110-110.
11. Дин һәм ислам / Осман Карабыйык әзерләвендә. — Истанбул: Хакыкат китабеви, 2004. — Б.257-258.
12. 1887 елда аның беренче китабы — морфология буенча дәреслек — басыла. 1888 елда галимнең тагын ике китабы дөнья күрә. Вафатына кадәр ул 140 хезмәтен нәшер итә.
13. Аның биографлары раславынча, Җәмалетдин шәех Мөхәммәд (с.г.в.) пәйгамбәрнең оныгы Хөсәен нәселеннән була, шуңа да аны сәед (әс-Сәййид) титулы белән олылаганнар.
14. Рәхимкулова М.Ф. Ризаэддин Фәхреддиновның китаплары һәм мәкаләләре библиографиясе. // Ризаэддин Фахретдинов иҗаты: Мәкаләләр җыентыгы / СССР ФА УрО Башк. Фәнни Үзәге. — Уфа, 1988. — Б.116-133.
15. Иран Асадабады Хамедан шәһәре янында урнашкан.
16. Фәхреддин Р. Шәех Җәмалетдин // Шура. — 1917. — №14. — Б.314.
17. Монда, иң беренче чиратта, Җәмалетдин әл-Әфгани күз алдында тотыла, чөнки нәкъ менә аны бар «гөнаһларда» да гаепләгәннәр.
18. Гакиф М. Шәех Җәмалетдин вә Мөхәммәд Габдүһ // Шура. — 1910. — №12. — Б.370-372.
19. Бу урында без Ризаэддин Фәхреддин «фарсы» дигән вакытта, шигыйларны күз алдында тота, дип исәплибез, чөнки ул моннан алда Мисыр шәехе Габделхода турында сүз алып бара, ә Габделхода — әл-Әфганинең чыгышы белән фарсы булуы турында иң беренчеләрдән сөйли башлаган кешеләрнең берсе. Әмма, дөресен әйткәндә, ул аның ватаны итеп башка шәһәрне күрсәткән булган. «Шура»ның 16 нчы санында Ризаэддин, Габделхода шәех әл-Әфганине шигыйлыкта гаепләгән, дип яза. Шуңа да «фарсы» һәм «шигый» сүзләре бу очракта бер үк мәгънәгә ия. Шул ук фикер буенча, «әфганлы» сүзе дә мәгънәсе буенча «сөнни»гә тиң. Ул вакытларда шигыйлыкта гаепләү диннән китүгә (мөртәтлеккә) бәрәбәр булган.
20. Фәхреддин Р. Шәех Җәмалетдин // Шура. — 1917. — №14. — Б.314.
21. Фәхреддин Р. Җәвамигуль кәлим шәрхе. — Казан: «Иман», 1995. — 296 б.
22. Шунда ук. — Б.306, 461.
23. Фәхреддин Р. Ибне Тәймия. — Оренбург: «Вакыт», 1911. — Б.18-19.
24. Шунда ук. — Б.96-97. ■

ШӘЕХ ҖӘМАЛЕТДИН[1]

РИЗАЭДДИН ФӘХРЕДДИН

VI. ГАКЫЛЫ ВӘ ГЫЙЛЕМЕ, ТӘГЪЛИМАТЫ ВӘ ФӘЛСӘФӘСЕ[2]

Сәед Җәмалетдин, үткен зиһенле вә гаять зирәк бер зат булып, күңелдә булган серләрне сизеп торадыр, каршысында булган адәмнәрнең фикерен йөзләреннән, күзләреннән укып, белеп утырадыр иде. Гакыл мәсьәләсе дә бик дикъкатьле вә дәлилләре куәтле, сүзләре тәэсирле буладыр иде.

Мәҗлесенә кергән адәм никадәр каршы вә тискәре булса, дәлилләрен ишетү берлән, итагать итәргә мәҗбүр буладыр иде.

Хәтере куәтле булуга исә үз-үзеннән уку ысулы илә өч айда французча үгрәнүе дәлил булырга ярар. Сәед Җәмалетдиннең гыйлеме дә гакылы берлә мөтәнасиб [тигез] булып, иске фәлсәфә берлә ислам тарихын вә ислам мәдәниятенең бөтен шөгъбәләре, фәргъләре [тармаклары] берлә беләдер иде. Асыл ана теле әфганча булган хәлдә, фарсычаны, гарәпчәне ана теле кадәр сөйли аладыр иде. Соң вакытларда французча берлә төркичәне лязим дәрәҗәдә белде. Гарәп вә фарсы телләрендә язылган әсәрләрдән Сәед укымаган вә күрмәгән әсәр, калган булса да, инде бик аз калгандыр.

Шәех Җәмалетдин ислам динен никадәр дөрес вә тугры белсә, яһүд вә христиан диннәрен дә шулкадәр беләдер иде. Коръән дәрәҗәсендә күп укымаса, укымагандыр, әмма Тәүрат вә Инҗил, гомумән гаһед гатик [борынгы заман әсәрләрен] вә гаһед җәдидне [яңа заман әсәрләрен] күп мәртәбәләр укыган, боларның французча булган тәфсирләреннән күпләрен күргән иде.[...]

Шәех Җәмалетдин мөселманнарны Коръән мәгънәсен белүгә, шуннан тугры файдалануга өнди вә бу көнге мөселманнарның аңсыз, надан, булуларын Коръәни Кәримне тәфәккерсез [фикерләмичә], тәдәбберсез [уйламыйча], аңламый укуларыннан күрәдер иде.

Шәех Җәмалетдин мәзһәб низагларын сөйми, хосусан сөннилек вә шигыйлык исеме берлә аерылуларны читләрнең аяк астында калуларына беренче сәбәп булганлыкны игътикад кыладыр, сөнниләр берлә шигыйларның берләшүләре һава

---

[1] Р.Фәхретдин «Шура» журналының «Мәшһүр адәмнәр вә олуг хадисәләр» сәхифәсендә басылган «Шәех Җәмалетдин» дип исемләнгән күләмле мәкаләсе «Асыл ватаны, нәсел вә кабиләсе, дөньяга килүе», «Сәед Җәмалетдин Истанбулда», «Кыяфәте, рәсеме, хосусый хәлләре», «Әхлагы», «Гакылы вә гыйлеме, тәгълиматы вә фәлсәфәсе», «Дәресләреннән мисаллар», «Гамәлләре, әмәлләре, мәсләге», «Әсәрләре, тәэлифләре», «Әдәби җәсарәте», «Җәмалетдин вә мөстәшрикъләр [шәркыятьчеләр]» дигән бүлекләрдән тора. Безнең өчен «Гакылы вә гыйлеме, тәгълиматы вә фәлсәфәсе», «Гамәлләре, әмәлләре, мәсләге» бүлекләре аеруча кызыклы, чөнки аларда олуг галимнең исляхчы буларак татар мәгърифәтчеләренә йогынты ясаган кайбер фикерләре бар. Бу бүлекләрне, кыскартып, сезнең игътибарыгызга да тәкъдим итәбез.

[2] Шура. — 1917. — №18. — Б.409-411.

берлә су дәрәҗәсендә лязим, дип сөйлидер иде.

Шәех Җәмалетдин мөселманнарны кәсеп вә һөнәргә, һәм дә баюга да димли: «Әгәр дә мөселманнар һөнәрсез, кәсепсез вә фәкыйрь хәлдә торсалар, түбән төшәрләр, бозыклыкка чумарлар, гомердә дә бәхет вә сәгадәткә ирешә алмаслар», — ди иде.

Җәмалетдиннең бөтен фикере вә сүзе мөселманнарны, ирләрне вә кызларны укуга, укытуга димләүдән гыйбарәт буладыр иде. Игътикад вә гыйбадәтләрне дөрес кылыр өчен — дин гыйлемен, байлык табар өчен дөнья гыйлемнәрен укырга тәргыйб кыла [кызыктыра] вә бу турыда: «Мөселманнарның зирәклекләре, тырышлыклары, гакыл вә аңнары, үз милләтләрен, диннәрен сөюләре, яратылышлары инглиз вә французлардан ким вә башкача түгел, шуның өчен инглиз вә французларның кулларыннан килгән эшләрне эшләү мөселманнарның кулларыннан киләчәк, шулай булгач, анларның һөнәрләренә искитәреп, хәйран булып йөрү урынына шул һөнәрләрне мөселманнар үзләре белергә, эшләргә тиешле. Хәзерендә дә мөселманнар эшли, ләкин эшләрнең иң авыр өлешен эшләп бетерәләр дә, җиңеле генә калганнан соң, француз вә инглиз һәм немечләргә бирәләр, тимерне потлап саталар да соңыннан шул үзләре потлап саткан тимерләрне тегеләрдән мыскаллап алалар, киндер вә җитен сүсләрен шалкан бәһасенә саталар да, соңыннан шунлардан эшләнгән сөлге, ашъяулык, салфит кебек нәрсәләрне үз авырлыкларына бәрабәр алтын вә көмеш биреп алалар. Мөселманнар надан кешеләрне үзләренә имам итеп тотулары вә Коръән белми торган кешеләрне галим кылып йөртүләре сәбәпле, ауропалыларга кара эшчелек хезмәте итеп тордылар, маңгай тирләре берлә франкларны киендерделәр, ясандырдылар, ашаттылар вә эчерттеләр, анларны тәмам симерттеләр. Ошбу сәбәптән ауропалылар сез мөселманнарның мәмләкәтләрен забыт иттеләр [яулап алдылар] дә муеннарыгызга менеп атландылар. Хәлбуки, сез дә ауропалылар шикелле үк кешеләрсез, алар сәяси як берлә сезләрне кысалар,

Җәмалетдин әл-Әфгани.
«Шура» журналы, 1917, №17

икътисади як берлә каннарыгызны сөлек урынына суыралар, усаллыкка каршы үзеңне саклау гыйззәте нәфес [үз-үзеңне сөючәнлек] икътизасыдыр [таләбедер]. Үзен әсир итүчеләргә каршы түзеп торучы халык нәфрәт ителергә вә дөньяда яшәмәскә тиешле. Әгәр дә сез нәфрәт ителүгә риза булмасагыз, башкалар кебек дөньяда яшәргә теләсәгез, сәбәпләренә керешегез. Аның сәбәпләре исә ауропалылар белгән гыйлемнәрне белү, анларның сәнәгать вә һөнәрләре, кәсеп вә сәүдә ысуллары берлә әшнә булу вә анлар төсле хөр вә мөстәкыйль яшәү. Сез шушы чараларга керегез, сез, бер дингә, бер китап вә пәйгамбәргә иярүче бертуган халык булуыгыз өстенә, ауропалылар тарафыннан залим вә җәбер күрүдә дә охшашсыз. Шуның өчен сез бер-берегезне сөегез, бер-берегезгә ярдәм кылышыгыз. Һич кичекми, яңа ысулда мәктәпләр ачыгыз, уку рәвешләрен яңалаштырыгыз, угыл-кызларыгызны укытыгыз, җәмгыятьләр ачыгыз, фәкыйрьләрегезнең кулларыннан

тотыгыз, берлектә эшләгез. Укырга-язарга белми торган мөселманнар калмасын, гакылы вә тәне сәламәт булган һичбер мөселман үзенең туганы булган икенче мөселманга салышып тормасын, йөк булмасын, инде үз кул көчләрегезнең вә үз маңгай тирләрегезнең файдасын үзегез күрергә вакыт җитте!..» — эчтәлегендә нәсыйхәтләр бирәдер иде. [...]

Сәед Җәмалетдин гарәп вә төрек һәм фарсы матбугатында «философ әшшәрык» дип зикер ителенер. Җәмалетдин бөтен гомерен мөселманнарның хәлләрен ислях кылу вә ислам дине мәдәниятка хилаф түгел икәнлеген күрсәтү юлында сарыф иткән кешеләрдән иде. Ошбу тугрыда бу адәм бөтен рәхәтен фида кылды, мәмләкәттән мәмләкәткә йөрде, сөйләгән фикерләре үзенең шәкертләре вә мөридләре аркылы бөтен ислам дөньясына таралды. Бу фикерләр гакыл әһелләре тарафыннан тәхсин берлә [хуплап] каршы алынды, вафат тарихы артта кала барган саен, шөһрәте вә хөрмәте арта вә халыкларга якынлаша барадыр. Ошбу сәбәптән шәрык тарихында моның исеме зур урын тотты. Хәтта Иранда вә Төркиядә булган инкыйлаб вә ислях хәрәкәтләре моның тарафыннан салынган орлыклардан үскән нәрсәләр итеп саналадыр. [...]

VIII. ГАМӘЛЛӘРЕ, ӘМӘЛЛӘРЕ, МӘСЛӘГЕ[3]

Шәех Җәмалетдин хәзрәтнең өмид-әмәлләре бик зур булып, җир йөзендә булган мөселманнарның күңелләренә Коръәни шәриф тәгълиматын урынлаштыру вә хакыйкый исламны тергезеп, аны хорафат вә бидгатьтән сафлау, ислам мәмләкәтләрен Төркия хәлифәте астына җыю, бу көн Америка вә Ауропада корал вә көймәләр ясый торган заводларны шул хәлифәлектә мөкәммәл [камилләшкән] рәвештә җитештерү, ислам мәмләкәтләрен бурыч алмаслык, бәлки үзләре бурыч бирерлек дәрәҗәдә баету вә шул сәбәпле мөселманнарны газиз вә шәриф бер милләт кылып, бөтен дөньяда тасдыйк иттерү [таныту] иде. Кыскасы, шәех Җәмалетдин, Дарвинча сөйләмәсә дә, эволюция (тәрәккый вә тәкәммел [камилләшү]) адәмнәреннән иде.

Җәмалетдин шушы өмиде юлында бик күп хезмәт итте вә олуг зәхмәтләр күрде, шушы өмидләре юлында хезмәт кылуга манигъ булудан [читләшүдән] куркып, хатын алмады, җария тотмады, хатын-кыз берлә бәйләнмәде вә берәр төрле кәсепкә дә керешмәде.

Мондый бер мәсләк ислам падишаһлары күңелләренә ошамау вә ислам хөкүмәтләре бөтен көчләре берлә бу рәвештәге фикерләргә каршы килүе сәбәпле, шәех Җәмалетдин ислам падишаһлары берлә мәгънәви сурәттә сугыш кылырга вә сәясәт берлә шөгыльләнергә мәҗбүр булды. Ислам дине берлә истибдад [деспотизм] бер-беренә дошман һәм дә ислам дине берлә фикердә хөрлек ислам дине берлә берлектә булганлыкларыннан, Җәмалетдин үзенең мөридләренә хөррият файдаларын төшендерәдер, истибдад зарарларын аңлатадыр иде.

«Шәех Җәмалетдин ошбу юлда сәясәт берлә шөгыльләнми, бәлки саф гыйльми җәһәт берлә генә шөгыльләнгән вә ислам яшьләрен үз фикерләре берлә тәрбия иткән булса, бәлки нәтиҗәләре дә яхшырак чыккан булыр иде», — диючеләр бар. Ләкин бу вакытларда мөселманнар булган мәмләкәтләр, хөкүмәтләр шәех Җәмалетдиннең мондый хезмәтләренә мөсагадә [ярдәм] кылырлык хәлдә түгел иде. Шуның өчен Сәед Җәмалетдин әгәр дә сәясәт юлына кермәгән булса, бөтенләй хезмәт күрсәтми киткән булуы да ерак ихтимал түгел иде. [...]

Шәех Җәмалетдин, ислам динен наәһелләрнең [дин белгечләре булмаган бәндәләрнең] мөсәллитъ булуларыннан [җитәкчелек итүләреннән] саклауга вә мәдәният берлә икесен бергә җыюга, мөселманнарның газиз бер кавем булып яшәүләренә ярдәм бирсен өчен, Мисырда бер хизеб [җәмгыять] тәшкил итте. Шулвакытта Мисыр хөкемдарының вәли

[3] Шура. — 1917. — №19. — Б.435-436; №20. — Б.457-459.

عدد ١٤ سنه ١٠

شورا

١٥ ايیول – ١٩١٧ سنه ٨ شوال – ١٣٣٥ سنه

مشهور آدملر والوغ حادثه‌لر

شيخ جمال الدين

يا گاغنه ايدى قرآن كريمنى مطبعه‌لرده باصو آنى حرمتسز ايتو بولادر، ديب توركياده دين عالملرى قرآن باصو حقنده نزاع چيقارغانلر وشونلرنگ تأثيرى برله استانبول شهرنده بولغان مطبعه‌لر، خلق طرفندن تالانوب، حرفلر اوراملرغه چيقارلوب تارالغان ايدى. بو كونده ايسه قرآن باصدرر ايچون ديب اعانت قيلغان وقفلر قالدرغان بايلر، «دين» اسمندن حرمت ايتوله‌لروقر آن كريم‌گه خدمت ايتوچيلردن صانالالر.

كوبدن توگل ايدى استانبولده رصد خانه صالنورغه باشلاغاندن صوك، دين عالملرى: «بزگه آندى دنيا علملرى كيره‌كمى بلكه هدايه اوقورغه كيره‌ك» ديب زور مسئله چيقارغانلر و رصد خانه‌نى صالدرتمى قالدرغانلر ايدى. اما بوكونده مصرده‌غى بتون طريقت و ايشانلر باشلغى بولوب، فرانسه‌ده «صوربون»ده اوقوغان ذات طورادر و مصرنك الڭ الوغ دين باشلغى صانالا طورغان ذاتنگ قز بالالرى‌ده «لوندون» مكتبلرنده اوقومقده‌لردر.

بوقبيلدن بولغان حادثه‌لر بيك كوب، شول حادثه‌لر وماجرالرنى كوز اوگلرينه كيتروب قويوچيلر صوگغى قرق ايللى يلدن اعتبارا اسلام دنياسنده بيك زور انقلابلر، فكر و مسلك آلماشنولر بولغانلقنى كوره‌چكلردر.

دنياده هيچ بر نرسه بر حالده طورمى. دنيا طوتاش بر اوزگارودن و يا گاردون عبارت. حديث عالملرندن بولغان امام بخارى‌نى اوز زمانده‌شلرى «دين بوزوچى» ديب بخارا شهرندن سورديلر. مذكور آدم، اوزينگ بلشلرندن، تانوشلرندن آيرلوب غربتده وفات بولدى. امام غزالى، اوز عصرده‌شلرى طرفندن باشلرنى آزدروچى حسابلانوب «احياء» اسملى كتابى اورامغه چيقارلوب ياندرلدى. كوب وقت اوتمادى امام بخارى اسلام دنياسينگ امامى و غزالى‌ده حجة الاسلام (اسلام دينينگ دليلى) صانالدى و هر ايكيسينگ كتابلرى آلتونلر برله يازلدى.

اسلام دنياسنده موندى حادثه‌لر بيك كوب. لكن ايسكى وقتلرده‌غى موندى اوزگارشلر جزئى وفرعى بولادر، اصل مسلك وعمومى فكر هميشه اوز يولنده باراردر ايدى. اما صوك وقتده‌غى اوزگارش ايسه بتونلاى آلماشنو و مسلك باشقارودن عبارت بولدى.

صوك وقتلرده اسلام دنياسنده بولغان دينى و اجتماعى اوزگرونگ سيبلرى، نتيجه‌لرى بيك اوزون همده اوزگارو سفرى بر تورلى مقصدغه باروب‌ده يتكانى يوق. اوشبو آوروپا صوغشلرى تمام بولغاندن صوك مسلمان دنياسى، قولاق ايشتمگان. خاطرلرگه كيلمگان روشده يوقارى كوتارلورگه ممكن. شونگ ايچون بو طوغروده سوز سويله‌و وقتى هنوز يتمگان. اما مسلمانلرنگ فكر دونلگندن، مسلكسزلكدن، يالقاولق و اشسزلكدن چيقولرينه، جهالت و تقليد زنجيرلرندن آزاد بولولرينه، اوز قوللرنده بولغان «دين»نڭ بيك عالى و سعادت يولى ايكانلگنى بلولرينه، يوقلاب ياتقان يرلرندن اويانوب‌ده ميدانغه چيقولرينه سبب بولغان كشيلرندن بعضيلرينى سويله‌رگه ممكن. بو آدملرنڭ برى بلكه الڭ زور خدمتلر ايتوچيلرى «سيد جمال‌الدين» اسمنده بر اسلام عالمى ايدى. شيخ جمال‌الدين‌نگ اسلام دنياسنده دينى واجتماعى اوزگه‌رولرنڭ باش عاملى بولغانلغى حقنده بو كونده اتفاق واقع. اوشبو سببدن

«Шура» журналының «Мәшһүр адәмнәр вә олуг хадисәләр» сәхифәсендә Җәмалетдин әл-Әфгани турындагы беренче мәкалә.
1917, №14

гаһеде [тәхеткә утырачак варисы] булган Тәүфикъ пашадан[4] «Мисырга хәдиф[5] булуым берлә милләт мәҗлесе ачтырырмын», — дигән вәгъдәсен алып, мәзкүр хизебкә әгъза кылырга муаффәкъ булды. Мәгәр дә Тәүфикъ паша ошбу вәгъдәсен вафа кылмау [сүзендә тотмау] берлә генә калмады, бәлки хәдиф булганнан соң, беренче эше Сәедне Мисыр мәмләкәтеннән сөрү булды. Шулай булса да, бу эштән Сәеднең күңеле кайтмады, рухы төшмәде, бәлки үзенең мәсләгендә тагын да артык гайрәт күрсәтте вә нәшат [шатлык] берлә гамәлен дәвам итте вә бу эш заигъ булмады [юкка чыкмады], көче җилгә китмәде. Хөррият берлә истибдадның [деспотизмның] нинди нәрсәләр икәнлекләрен ислам дөньясына ачык аңлатты, ничә гасырлардан бирле гафләт йокысында ятучы ислам галәменә яңа җан өрде, хәмиятьләрен [башкаларның зарарыннан саклап калу теләгең] кузгалтты, бөтен шәрык халыкларының гомуми бер һәлакәттән котылуларына сәбәп булды. Ислам дине вә мөселманнар өчен Шәех Җәмалетдин дәрәҗәсендә хезмәт күрсәтүче кешеләр тарихта күп күрелмидер, әгәр дә: «Дөньяда иң ләззәтле булган хәят алтын-көмеш күп булу яки мәртәбәгә мену вә яки олуг вә шөһрәтле бер нәсел вә кабиләгә нисбәт ителү түгел, бәлки соңларга яхшы бер эш калдыру вә башкаларга яхшы мисал булу», — диелгән сүз дөрес булса, һич шөбһә юк, шәех Җәмалетдин хәят ләззәтенә ирешүчеләрдәндер.

Җәмалетдин берлә Мөхәммәд Габдүһ «Мөселманнар иттифагы» исемендә бер иттифак төзүне лязим күрәләр вә моның сәбәпле мөселманнар наданлыктан вә хурлык берлә гомер сөрүдән котылырлар, дип өмид итәләр вә ошбу җәмгыятьнең мәркәзе Мәккәи Мөкәррәмәдә булуны тиешле табалар иде. Ләкин һәр икесе мондый бер эшне күрми вафат иттеләр.

Шәех Җәмалетдин хәзрәтләренең нинди бер мәсләктә булуы вә нинди мәҗбүриятләр берлә мәйданга чыгып та үзен һәртөрле хәтәрлекләр каршында тотуы хакында Әхмәд бәк Агаев[6] җәнапларының «Төрек йорты» журналында язган бер мәкаләсе дөрес вә шул нисбәттән кыска вә ачык булганлыктан, кыскачасын бу урында күчерәбез.

Әхмәд бәк Агаев бу рәвештә сөйли: «Шәех Җәмалетдин Әфгани, бөтен

[4] Тәүфикъ паша (1852-1892) — 1879-1892 елларда Мисыр хәдифе
[5] Хәдиф — 1867-1914 елларда Госманлы Төркиясе кул астында вакытта Мисыр идарәчесенең титулы һәм шул титулны йөртүче кеше.
[6] Әхмәд бәк Агаев (1868-1939) — мәшһүр азәрбайҗан дәүләт эшлеклесе, журналист һәм тюрколог.

мөселманнарның дучар булган хасталыгын яхшы белде вә шуның дәвалары нинди нәрсәләр икәнлеген күрсәтте. Шәех Җәмалетдиннең бу хезмәте ислам дөньясында беренче эш иде. (Аңа кадәр мөселманнарның хаста булулары сизелми торыла. Дәвасы вә чарасы, табигый, эзләнмидер иде.) Бу адәм динне вә әхлакый чараларны күрсәтү берлә генә калмады, бәлки иҗтимагый вә мәдәни чараларны да күрсәтәдер иде.

Мөселманнарның әхлакый-дини җәһәтләрдән түбән төшеп китүләренең сәбәбе исә наданлыклары вә хөкүмәтләренең идарәсезлекләредер. Наданлыкны бетерү өчен, гыйлем уку, нинди җирдә вә кемнәр кулларында булса да булсын, һөнәр вә сәнәгатьне мөселманнар үзләренә алу вә үз малларын һәм сәрмаяләрен [акчаларын] бар кылу кирәк. Ауропаның гыйлеменнән, фәненнән мөселманнарның хәбәрсез вә мәхрүм торулары һич дөрес түгел. Хакыйкать хәлдә ислам дине, гыйлем вә фән һәм дә хаклык вә нур берлә берлектә була торган нәрсәдер. Ислам диненең хакыйкате гыйлем берлә фән нурлары сәбәпле генә беленер. Бу көн дөньяда булган яңа фәннәр вә яңа гыйлемнәрнең анасы — ислам динедер. Ислам дине көчле вакытта, ислам дөньясында гыйлемнәр вә фәннәр дә көчле иде. Бу көн дөньяда булган бик күп гыйлемнәр вә фәннәрне башлап дөньяга чыгаручылар мөселманнар булды. Ауропалылар гыйлемнәрне, фәннәрне мөселманнардан алдылар. Бу көн ауропалылардан гыйлем вә фән үгрәнүебез бары үз малыбызны табылган урыннан үзебезгә алуыбыз гынадыр.

Бу көнге Ауропада булган хөкүмәт вә идарә ысуллары асыл игътибары берлә ислам диненә чит нәрсә түгел. Дөрес, мөселманнар бу көндә үз диннәрен вә үзләренең тарихларын яхшы белә алмыйлар. Ләкин бу эшләрнең асыл ислам дине өчен зарары юк. Золым вә җәберләр берлә мөселманнар арасына читтән кертелеп урнаштырылган вә ислам диненә тәмам ят булган чит идарәләр, истибдадтан [деспотизмнан] гыйбарәт ысуллар, ислам мәдәниятенең сүнүенә вә ислам диненең дә бөтенләй эштән чыгуына сәбәп булды. Гыйлем вә фән һәм дә сәнәгать инкыйраз булу [бетү, юкка чыгу] сәбәпле, ислам дөньясына ислам дине исеме берлә батыйль игътикадлар [бозык инанулар], хорафат вә бидгатьләр урынлашты вә шунлар берлә егылып хәлсез төште.

Ошбуның өчен бүгенге мөселманнар арасында дин галимнәренең вә җәмәгать хадимнәренең беренче вазифалары ислам динен хорафаттан аралау вә тазарту, хакыйкый исламның фазыйләтләрен [өстенлекләрен], голүвиятен [бөек идеяләрен] күрсәтүдер. Моның өчен иң яхшы юл яңа гыйлемнәр вә яңа фәннәр берлә кораллану вә шул кораллар ярдәме берлә хакыйкый ислам динен сәяси вә иҗтимагый, әхлакый вә икътисади нокталардан тикшерү вә тәхлил кылудыр [анализлаудыр]. Шушы вакытта гына мөселманнар үзләренең хасталыкларына дәва тапкан вә җаннарына юаныч хасил кылган булырлар.

Шәех Җәмалетдин Әфгани хәзрәтләренең мәсләге ошбу урында сөйләнгән нәрсәләрдән гыйбарәт иде. Аз заман эчендә шушы фикер бөтен ислам галәменә таралды вә һәр җирдә үзенә тарафдарлар пәйда кылды. Бер тарафтан Ауропаның гыйлем вә фәнен кәсеп итү вә икенче тарафтан да ислам дөньясының мазыен [үткәнен-киләчәген] тикшерү хакында мәхәббәт вә дәрт уйганды. Мөселман яшьләре, груһ-груһ [төркем-төркем] булып, Ауропа мәктәпләренә керә башладылар, беркадәр яшьрәкләре ислам диненең хакыйкатен вә тарихын тикшерергә керештеләр. Ошбуның тәэсире берлә Һиндстан вә Мисырда, Төркия вә Русиядә мөҗаһидләр вә хадимнәр [хезмәт итүчеләр] заһир булып [барлыкка килеп], ислам дине хаиз [ия] булган хакыйкать вә фазыйләтләрне берәм-берәм мәйданга чыгара башладылар, ислам динен голүм вә фөнүн җәдидә [яңа гыйлем һәм фән] һәм дә сәяси тәшкилат вә яңа идарәләр берлә тәмам имтизаҗлы [оешкан] икәнлеген бөтен тәфсыйлаты берлә дөньяга игълан кылдылар.

Ошбу сәбәптән ислам дөньясында яңа бер өмид вә яңа бер әмәл, яңа бер истикъбаль [киләчәк] ноктасы тугды. Бу исә гыйлем вә фән берлә кораллану, ислам әхлагы берлә әхлаклану сәбәпле, иске

исламны яклау вә шуның күләгәсендә мәсгуд [бәхетле] яшәүдән гыйбарәттер». [...]

Сәед Җәмалетдиннең гамәлләре вә әмәлләре хакында шәех Рәшид Риза[7] хәзрәтләре ошбу әчтәлектә сүз сөйли: «Сәед Җәмалетдин бик зур эшләргә икъдам кылу [көч кую] вә шул сәбәпле бу көндә пришан булып торган [һәлакәткә төшкән] мөселманнар дөньясын аякка бастыру хакында үз-үзенә вәгъдәләр биргән иде. Әлбәттә, бөтен гомерен шушы юлда үткәрде, ни генә күрсә дә, шушы юлда хезмәт итүе сәбәбеннән күрде, бер генә урында да тыныч вә рәхәт утыра алмады, ләкин бу олуг адәмнең табигатендә беркадәр ашыгулык бар иде. Зур эшне үзе эшләп тә, шуның нәтиҗәсен үзе күрүне арзу кыладыр [телидер] иде. Шуның өчен программасын хөкүмәтләр, хөкемдарлар җәһәтеннән башлады, моның гыйлеме вә җәсарәте [батырлыгы], фазыл [намуслылыгы] вә кәмаләте [өлгергәнлеге] хөкүмәт сарайларына керү, вәзирләр арасында игътибар кәсеп итү өчен бик яхшы вәсилә [чара] булды. Мисырга килү берлә, гыйлем башлыклары үзен бөтенләй урап алдылар, дәресләренә ябырылып килделәр. Җәмалетдин шәкертләргә фәлсәфә берлә ислам диненең нигезләреннән дәресләр бирде вә моның өстенә дә шәкертләренә сәясәт фәнен укытты. Шул шәкертләрнең ярдәме берлә үзенең морадларына җитүгә өмиде бар иде. Шулвакытта мөстәбид [деспот] Исмәгыйль пашаның[8] сизүеннән сакланырга тиеш күрәдер, әгәр дә Исмәгыйль паша сизеп алса, морадына манигъ булачагына [ирешә алмаячагына] шөбһә кылмыйдыр иде. Исмәгыйль пашаның мәкереннән, зарарыннан саклану өчен бердәнбер чара масоннар җәмгыятенә[9] әгъза булу дип белде вә шул сәбәпле үзенең мөридләре берлә масоннар җәмгыятенә әгъза булып язылды. Масон җәмгыятенең исә дин берлә эше юк, саф бер әдәби вә әхлакый җәмгыять булганлыктан, монда бер зарар да күрмәде. Шулвакытта Мисырның олугларыннан булган пашалар, әкабирләрнең [дәрәҗәле кешеләрнең] дә күбесе масон җәмгыятенә мәнсүбләр иде. Шулвакытта тәхеткә варис булган Тәүфикъ паша Сәедкә бик ихласлы булып, аны игътибар итәдер иде. Беркадәр вакытлар соңында Мисырга Англиянең варисы килде. Үзенең җәмгыятендә әгъза булу мөнәсәбәте берлә масон җәмгыяте моның шәрифенә мәҗлес ясарга карар бирде вә аңа үзләре каршыларында зур фәхер ганване [горур атама] булган «рәис әш-шәрык әл-әгъзам» дигән титулны бирде. Шушы вакытта Сәед Җәмалетдин: «Мондый әдәби бер җәмгыятьнең вәли гаһеде исеменә, адәм балалары өстендә болай газыйм [өстен] булып торучы инглизләрнең хөкүмәт адәмнәре хөрмәтенә мәҗлес ясау вә ганвәннәр бирү дөрес түгел, бу эш әдәби вә әхлакый җәмгыятьнең дәрәҗәсен төшерә, залимнәргә илтифат итү буладыр», — дип игътираз итте [каршы төште]. Күпчелек Сәед тарафында булмау сәбәпле, бу максуды җиренә килмәде, сүзе булмый калды. Шуннан соң Сәед үзенең мөридләре берлә масонлык җәмгыятен ташлап чыкты. Бервакыт минем үземә шәех Мөхәммәд Габдүһ рәхмәтулла: «Без остазыбыз философ Җәмалетдин берлә масонлыкка иҗтимагый вә сәяси бер максад өчен кергән идек. Соңыннан һәр икебез аны ташладык, масонлыкның бөтен максуды — гыйлем һәм хөррият берлә сугышучы руханиларга вә хөкүмәтләргә каршы тору вә анларның ниятләрен вә игътибарларын сындыру. Ауропаның күтәрелүенә ошбу җәмгыять зур хезмәтләр итте, ләкин инде Ауропада моның әһәмияте калмады, чөнки аның хезмәт мөддәте [срогы] күптән тәмам булды, әгәр дә Ауропада бу көндә булса, бары тик иске вакытта зур эшләр эшләгәнлеге сәбәпле, «асаре кадимә»[борынгы истәлек] хөкемендә генә дәвам итә торгандыр», — дип сөйләгәне бар.

Сәед Җәмалетдин берлә Мөхәммәд

[7] Рәшид Риза (1865-1935) — Мисыр фәлсәфәчесе, исляхчысы.

[8] Исмәгыйль паша (1830-1895) — 1863-1879 елларда Мисыр идарәчесе (1867 елга кадәр — паша, ә аннары — хәдиф).

[9] Масончылык — XVIII гасырда Англиядә барлыкка килгән, аннары Франция, Германия, Испания, Россия һәм кайбер көнчыгыш илләрендә таралган дини-этик хәрәкәт.

Габдүһнең Ауропада торган вакыттагы хезмәтләре «Әл-Гурватүл-вуска»ны чыгару һәм дә вәгазь вә нәсыйхәт кылудан гына гыйбарәт түгел иде. Бәлки анлар Мисыр вә Судан мәсьәләсе хакында Франция вә Англия хөкүмәтләре берлә мөзакәрәгә [сөйләшүгә] керештеләр, хәтта шушы мөзакәрәләрнең нәтиҗәсе Англия хөкүмәтенең Суданнан бөтенләй ваз кичүдән, бу мәмләкәтне бөтенләй үз халкының ихтыярына ташлаудан гыйбарәт булып калачак иде. Бу тугрыда рәсми карарлар игълан ителер вакытта Судан мәһдие Мөхәммәд Әхмәд[10] вафат булды вә бу эш тә тәмам булмый калды. Сәед берлә Мөхәммәд Габдүһнең Судан хакында бик гали [бөек] максадлары бар иде. Дөрес, бу эшне алып баручы кеше Сәед Җәмалетдин иде, әмма моңа Мөхәммәд Габдүһ тә ярдәмче булып йөрде. Әгәр дә Мөхәммәд Габдүһ бу рәвештә тырышып ярдәм итеп йөрмәгән булса иде, Сәед Җәмалетдин өчен бу эш, бәлки, бик авыр килгән булыр иде.

Мөхәммәд Габдүһ хәзрәтләре: «Бервакыт остазыбыз Сәед Җәмалетдингә: «Безнең бу сәясәтебез вә максудыбыз ахырына барып чыга алмастыр, гадел булган ислам хөкүмәте төзү хакындагы манигъ [тыю] чит падишаһлардан гына гыйбарәт түгел, бәлки башка манигъләр да бар. Ул юл берлә йөргәнче, без сәясәттән ерак вә истибдад тырнаклары батмаган аулак урыннарга барыйк та, надан халыклар арасына аң вә гыйлем таратыйк, ифрадны [ялгызларны] үзебез теләгән рәвештә тәрбия итик, күпчелек арасында үзләрен милләт вә дин хезмәте юлына вәкыф итүче, аз булганда да, ун кеше чыгар. Бу кешеләр җир йөзенә таралырлар, надан халыкларны безнең юлыбыз берлә тәрбия итәрләр вә һәрберенең хезмәте сәбәпле, үзләре кебек ун фидаи [фидакяр] җитешер. Шулай иттереп, аз заман мөддәтендә дин вә милләт юлында үзләрен корбан кылырга хәзер торучы йөз кадәр адәмебез хәзерләнгән булыр, шушы фидаилектән бик күп файдалы эшләр мәйданга чыгар», — дигән идем, бу сүземә каршы Сәед хәзрәтләре: «Эшне кичектерергә план кормакчы буласың, без инде бер юлга кергәнбез, я максудыбызга барып җитәбез, яки арып, хәлдән таеп, юлда егылып калабыз, алдыбызда шушы ике нәрсә, өченчесе юк», — дип сөйләде.

Сәед Җәмалетдин хәзрәтләре 1884 ел 12 шәүвәлдә чыккан «Әл-Гурватүл-вуска»да ошбу эчтәлектә бер җөмлә язадыр: «Бу номерны үз вакытында чыгарудан сәламәтсезлегебез манигъ булды [тоткарлады]. Шулай булса да, без эшсез, тик ятмадык, һәмишә [һаман] мөселманнарның хокукларын яклау берлә шөгыльләнәбез, без инде шушы хезмәтне өстебезгә алганбыз, Аллаһы Тәгаләгә шөкерләр булсын, шул хезмәт артыннан барсак иде, барыбыз шул юлда булсак иде. Шул юлда йөрүчеләр җөмләсеннән кубарылсак иде».

Бу көндә Мөхәммәд Габдүһ, мөселманнарның хокуклары хакында инглизләрнең сәяси адәмнәре берлә сөйләшер өчен Лондонга барды, комсыз инглизләрнең нинди аулар корып ятканлыкларын бераз аңлады. Инглизләр инде җир йөзенең өч кыйтгасыннан бик күп урыннарны үз идарәләренә алдылар, тәмам җиһангир бер дәүләт булдылар. Хәзер инде калганнарын да үз кулларына алырга хәзерләнәләр, боларның корсаклары һич тулмый, күзләре туймый. Бер мәмләкәткә барып керделәр исә, шуның аръягындагы күршесенә күзләре төшә вә, шуны эләктерми торып, җаннары тынычланмый. Болар үзләренең һәрбер бозык вә начар эшләренә яхшы исемнәр биреп, халыкларга гүзәл итеп күрсәтәләр, золым вә җәфаларын гаделлек вә инсанлык буяуларына буяп, дөньяны алдап яталар. Англия хәрби вәзире тарафыннан сөйләнгән сүзләрдән инглизләрнең Мисыр мөселманнарын хайван дәрәҗәсендә хисап кылганлыклары мәгълүм. Әй мөселманнар! Сез кайдасыз? Үзегезне кимсетүгә ничек итеп түзәсез?»

Текстны һәм искәрмәләрне басмага
***Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

[10] Мөхәммәд Әхмәд (1844-1885) — Суданны азат итү хәрәкәте җитәкчесе, Судан дәүләтенә нигез салучы.

И.Гаспринский Йосыф Акчура белән Гурзуфта. 1908 ел

ЯҢА ТӨРЕК ДӘҮЛӘТЕ УҢЧЫЛАРЫ

ЙОСЫФ АКЧУРА

ТЕЛДӘ «БЕРЕНЧЕ ТӨРКИЧЕЛЕК»НЕҢ БАШЛАНГЫЧ БИЛГЕЛӘРЕ. ӘХМӘД ВӘФЫЙК ПАША

Телдә төрекчелек Зыя пашадан[1] соң төрки телне тикшерү өлкәсенә күчә. Төрки телне тикшерү Госманлы шивәсеннән башка төрки телләрне дә өйрәнү тарафына юнәлтелә. Тюркологиянең бу сәхифәсен башлыча Әхмәд Вәфыйк әфәндедән (пашадан) башланганын күрәбез.

Шинаси[2] җыя башлап та азагына җиткерә алмаган сүзлекнең сәхифәләре Госманлы өлкәсе чикләре тышына чыга. Төрки тел сүзлеген төзү эшен Әхмәд Вәфыйк паша[3] дәвам иттерә. Вәфыйк пашаның «Ләһҗәи Госмани»га язган кереш сүзе «беренче төркичелек» турында бер ядкяр булып тора.

«Ләһҗәи Госмани»ның беренче басмасын күрмәдем. Китапның басылу тарихына кагылмыйм. Кулымда булган яңа басма 1888/1889 елда басылган. Бу яңа

[1] Зыя паша (1825-1881) — Танзимат дәверендәге төрек шагыйре һәм публицисты.
[2] Ибраһим Шинаси (1826-1871) — мәшһүр госманлы язучысы, тәрҗемәче, җәмәгать эшлеклесе. Яңа төрек әдәбиятына һәм драматургиясенә нигез салучы шәхесләрнең берсе.
[3] Әхмәд Вәфыйк паша (1823-1891) — дәүләт эшлеклесе, әдәбиятчы, университетта фәлсәфә һәм тарих мөгаллиме.

басмасының язылу вакыты күрсәтелмәгән. Мөкатдимәсе азагында: «Төрек телләре арасында иң киң таралганы — угыз теле. Ул Татарстан, Төркестанны иңләп, Көнчыгыш диңгезеннән Маҗарстанга кадәрге киңлекне биләп алган, хәзер гуз теле дип атала торган шивә. Аның яңасы — төрекмән исеме белән аталып, Иран һәм Сүрияне иңләп, Анатолиядә тамырланган, Фирганәдән Үргәнечкә кадәр җәелгән әфган халаҗлары теле. Иске тармаклардан, кыпчак шивәсе Хивадан Себергәчә, кыргыз, коман вә Болгар дәүләте — Казан якларын биләгән. Кытай ягыннан Кашгарга таба уйгыр теле җәелә. 1300 елларда Чыңгыз явы кавемнәре төркилеккә һәм исламияткә күчкән вакытта, чыгатай теле туып[4], 1398 еллардан башлап киң мәйданга җәелгән. Уйгыр, кыпчак, чыгатай китаплары, «Мәхбүбелколүб» кебек гүзәл әсәрләр, аеруча 600-800 (1200-1400) елларда күп таралып, алар тәэсирендә телләребез тармакларга аерыла. «Һиммәт үртиҗаль так-лагыль, җөбаль [кеше тырышлыгы тауны урыныннан күчерә]», — ди Әхмәд Вәфыйк. Пашаның бу кереш мәкаләсендә төрки телләргә бөтен киңлекне иңләп алган бербөтен тел дип караганы аңлашыла. Асыл телебез — бөтен Азиягә һәм Көнбатыш Европагача җәелгән телдер: госманлы шивәсе, чыгатай шивәсе һ.б. тел тармаклары шивәсеннән гыйбарәт. Бу шивәләрне нечкәләп тикшерү белән без тармаклар аерымлыкларын ачыклыйбыз. Аерымлыкларны билгеләүдән уртаклыклар калкып чыга. Кыскасы, Әхмәд Вәфыйк паша тел васитәсе белән төрек бердәмлеген югары киңлектә күрә һәм күрсәтә.

Вәфыйк паша «Ләһҗәи Госмания»сендә беренче мәртәбә асылы гарәп һәм фарсы тамырыннан булмаган сүзләрне, асылы гарәп вә фарсыча булганнардан аерып, аерым бер сүзлек рәвешендә тәртипкә сала. Шул рәвешчә, чиксез госманлы сүз диңгезенә күмелгән кыйммәтле төрекчә сүзләрнең гарәп, фарсы телләреннән җиңелеп, мөстәкыйльлеген җуелудан саклый. Әхмәд Вәфыйк пашаның барлык әсәрләре тел ягыннан ачык билгеләнгән төрекче булуын күрсәтә. Мәсәлән, Фенелонның «Телемак»ын[5] вәиси һәм нәргисиләр шивәсендә тәрҗемә иткән Йосыф Кәмаль пашага ачуы кызып, Мольерның[6] кайбер әсәрләрен үзе шул заман госманлы хәятенә якынайтып, гади төрек теленә тәрҗемә итә һәм Истанбулның урам сөйләме төрекчәсен төрек сәхнәсенә чыгара.

Әхмәд Вәфыйк пашаның төрекчәсе, тел белеме белән генә чикләнеп калмыйча, тарих фәне сәхнәсендә дә чыга. Ул, пашалыгына кадәр үк Әбелгазый Баһадир хан[7]ның «Шәҗәрә-и төрек» атлы мәшһүр әсәрен чыгатай шивәсеннән госманлы шивәсенә күчерә. Бу әсәр өлешчә Шинасиның «Тасвир-и әфкяр» әсәрендәге «Төрле материаллар» бүлегендә, соңра аерым китап рәвешендә басылып чыга. «Шәҗәрә-и төрек»нең «Тасвир-и әфкяр»енең «Төрлеләр» бүлегенә кертелүе Шинаси әфәнденең төрекчелек хәрәкәтенә хезмәте дисәк тә, әллә ни зур хата булмас. Әхмәд Вәфыйк паша язучы булуы өстенә, күренекле мөдәррис буларак та танылган. Солтан Габделгазиз[8] патшалыгының башлангыч елларында ачылган университетта ул гомуми тарих фәненең беренче укытучысы була. Әхмәд Вәфыйк әфәнде беренче лекциясен 1863 елның февралендә укый башлый. Көчле кыскартуга дучар булган гомуми тарих дәресләренең сөземтәсе бер кечкенә китап рәвешендә басылып та чыга[9]. Гомуми тарихның иң борынгы дәверенә бәйле кайбер хәбәрләрдән

[4] Аксак Тимер империясе теле күз алдында тотыла.
[5] Француз язучысы Франсуа Фенелонның «Приключения Телемака» исемле романы.
[6] Жан-Батист Поклен (театраль псевдонимы — Мольер) (1622-1673) — мәшһүр француз комедиографы.
[7] Әбелгазый Баһадир хан (1603-1664) — 1645-1663 елларда Хива ханы.
[8] Габделгазиз (1830-1878) — Госманлы империясенең 1861-1876 елларда идарә иткән 32 нче солтаны.
[9] Атуфәтле Әхмәд Вәфыйк әфәнде хәзрәтләренең дарелфөнүндә «Хикмәт-и тарих дәресләре»нең сөземтәсе. Беренче китап. Әүвәлге гасырлар бүлегенә кереш. Җөз-и әүвәл. Варварлык гасыры. Елы, мәтбагә исеме күрсәтелмәгән.

гыйбарәт бу сөземтәдән пашаның төрекчелек позициясендә торганмы, юкмы икәнен, әлбәттә, билгеләп булмый.

Кайберәүләр фикеренә караганда, Әхмәт Вәфыйк паша — Госманлы төрекләреннән беренче төрекчелек хәрәкәте вәкиле. Әйе, Шинаси һәм Зыя пашаларга караганда, Әхмәд Вәфыйк пашаның төрекчелеге ачыграк. Барлык язмаларында, хәтта яшәеш рәвешендә дә, аның төрекчелеге күзгә ташлана.

«Ләһҗәи Госмани» керешендәге карашларыннан һәм «Шәҗәрәи төрек»не Истанбул төрекчәсенә тәрҗемә итүеннән Әхмәд Вәфыйк пашаның «гомуми төрек»лек сафында торганын күрәбез. Шул ук вакытта Әхмәд Вәфыйк пашадан алдарак иҗат иткән Шинаси әфәнде, Зыя пашаларның да төрекчелек фикеренә бәйле булуларын онытырга ярамый.

ФИЛОЛОГИЯДӘ ҺӘМ ТАРИХТА ТӨРЕКЧЕЛЕК. МОСТАФА ҖӘЛАЛЕТДИН ПАША

Әдәбиятта һәм телдә күзәтелгән һәм яшәгән төрекчелек эволюциясе кыска вакыт эчендә Госманлы төрекләре филологиясе, этнологиясе, тарихы һәм тышкы сәясәте өлкәләренә үтеп керә. 1869 елда Мостафа Җәлалетдин исемле бер зат француз телендә «Иске һәм яңа төрекләр» дигән бер әсәр бастыра. Солтан Газизгә багышлап чыгарылган бу китап Истанбулда «Курьер д`Ориент» газетасы матбагасында дөнья күрә. Әлеге әсәр — Госманлы дәүләтенең яшәү куәтен арттыру, ил халкының муллыкта яшәешен тәэмин итәр өчен, дәүләт нәрсәләр эшләргә тиешлеген солтанга тәкъдим итү характерындагы бер рапорт. Китапта төрекчелек мәсьәләсенең шул көнге торышына ачыну да бар һәм башка күптөрле мәсьәләләр дә күзгатыла. Мәсәлән, бөек дәүләтләрнең Госманлы солтанлыгына каршы сәясәт йөртүләре һәм киләчәктә үзләренең дә шуңа лаеклы җавап табачаклары турында кисәтә. «Иске һәм яңа төрекләр» китабының ил тарихына багышланган бүлекләре француз, алман, рус һәм поляк чыганакларына нигезләнеп язылган. Китерелгән вакыйгаларда төрекләрнең кешелек тарихында әһәмиятләре, кешелеклелекләре, мәдәни яңарышка зур тәэсир күрсәтүләренә игътибар бирелә. Җәлалетдин паша карашынча, төрекләр — бүген дә европалы халыкларның берсе. Автор дөньяның бу төркемгә кергән халыкларын «төркиари иркы» [расасы, төркеме] халыклары дип атый һәм, «индогерманизм, урал-алтаизм» теорияләренә охшатып, «туркоарианизм» дигән этнологик атама мәйданга китерә. Аны соңгы заманнарда Прага, София шәһәрләрендә яшәгән рус мөһаҗирләре мәйданга керткән «европа-аризм» теориясе белән чагыштырып бәяләп була. Аннан бу төркемнең тел-лингвистика мәсьәләләренә күчә. Китапның өчтән береннән артыграк күләмен биләгән бу бәхәс беренче карашка, асылда, ике гамәли мәсьәләне чишүгә кагыла. Госманлы өлкәсендәге халыкның күпчелеген һәм төп кавемен тәшкил иткән төрекләрнең кодрәтләрен һәм дәрәҗәләрен киңәйтеп, үз көчләренә ышанычларын арттыра. Үзләрен төрекләргә чит халык санаган һәм шул заманнарда көчәя башлаган милләт принцибына таянып, төрекләргә каршы аякка калкырга әзерләнгән яки аякка калка башлаган валахлар, болгарларны, хәтта серб, румыннарны төрекләр белән бер кавемнән икәнлекләренә ышандырырга тырыша. Үзләренә арилар исеме тагып, ариларга төрле, гадәттән тыш (затлы) сыйфатлар ябыштырып, үзләрен сями, турани, хамилардан өстен җенес санаган европалыларның бу мин-минлеге [эгоистлык] теориясенә тиңләшерлек ариannар-туранлыларның бер кавемнән икәнен исбатларга тырыша, Европа дәүләтләре һәм халыкларының туранилларга нәфрәт, дошманлыкларын йомшартырга чара эзләгәндәй итә.

Авторның «туран-арианизм» теориясе нык эшләнгән, дип әйтү кыен. Авторның дәлилләре ясалма, җитди тәнкыйтьне күтәрерлек түгел. Фикер йөртүләре, нәтиҗә чыгарулары, бәяны

турында әйтмик тә инде. Фараз-гипотезалары да ышанычсыз, ясалма. Мәсәлән, ул тәкъдим иткән фаразлардан берсе — грек һәм борынгы Рим аллаларының исемнәрен төрки ата-малар дип раславы. «Иске һәм яңа төрекләр»дән файдаланып, аннан соң да бу фикерне кабатлаучылар күп табылды. Мостафа Җәлалетдин паша кияве булган берәүнең дә төрек телен иң борынгы тел дип раславы, сүзләрнең килеп чыгышын предметлардан чыккан авазларны кабатлау, дип аңлатуы кебек «ачышлары» белән карт каенатасы китабына бурычлы булса кирәк. Әмма Мостафа Җәлалетдин паша китабында игътибарны үзенә тарткан, уйларны еракларга алып китеп, карашларын киңәйткән урыннар да аз түгел.

Безнеңчә, әсәрнең иң зур әһәмияте — «Бөтен төреклек һәм төрекчелек» хакында Европа чыганакларыннан алынган фактларны беренчеләрдән булып, госманлы укучылары арасында таратуда. Бу әсәрдә беренче мәртәбә төрек кавеменең тарихта күренекле роле, төрек теленең башка телләр ярдәменә мохтаҗ түгел дәрәҗәдә бай тел икәне, үзе башка телләргә көчле тәэсир күрсәткәне, Азия һәм Европада киң мәйданнарга җәелгәнлеге, Госманлы дәүләте эчендә төркилек фикеренә бәя җитәрлек бирмәү нәтиҗәсендә туган кыенлыклар, мөселман динендә булмаган госманлы тәбагасын бер төрек массасына бәйләү һәм бу бәйләнешне ныгыту зарурлыгы кебек карашларны очратабыз. Яңа төрекчелекнең теле, тарихы, барлык сәяси тармакларына әлеге китап азмы-күпме кагылмый үтми. Саф төрекчелек мәсьәләләренә каратылган бу темалардан тыш, бүгенге мәгърифәтчеләребезнең көндәлек хезмәтенә әйләнгән төрки тел закончалыкларын тәртипкә салу, чистарту, хәрефләр алфавитына исляхы [яңарту], хатыннарның йөз пәрдәләрен ачу, Көнбатыш мәдәниятенә тиңләшү кебек темалар һәм сюжетлар «Иске вә яңа төрекләр»дә күренекле урын тота.

«Туран-арианизм» теориясенә нигез салган автор төрекләрнең Көнбатыш мәдәниятенә керүен үз теориясенең мантыйкый нәтиҗәсе кебек күрсәтә. Чынлыкта, Көнбатыш мәдәниятен туран-ариан халыклары мәйданга китергән, ягъни Көнбатыш мәдәнияте ариларныкы булганы кебек үк, туранилар, тулысы белән төркиләр әсәре дә. Тураниларның бер өлеше, ислам кабул иткәнгә кадәр, сямиләр [семит телле халыклар мәдәнияте] белән берләшкән була. Аларның бүгенге Европа мәдәниятенә кушылулары үз кавемнәренең борынгы мәдәниятенә кайтудан башка нәрсә түгел. Мостафа Җәлалетдин паша телне чистарту, алфавит исляхы мәсьәләләрендә дә фикерләрен шул башлангычларга бәйләп йөртә. Әсәр бу мәсьәләләргә кагылган беренче хезмәтләрдән саналырга тиешле. «Иске һәм яңа төрекләр» китабы, кызганычка каршы, төрек телендә түгел, француз телендә язылган. Бу китап француз телендә һәм төрекчәгә тәрҗемә ителеп, бастырылып, җәмәгатьчелек арасына таратылырга тиеш. Төрекчелек тарихын һәм ул замандагы Госманлы вакыйгаларын өйрәнүдә зарури материал булган әлеге әсәрне әйләнешкә кертү Мәгариф министрлыгының һәм «Төрек учаклары»ның кичектергесез бурычы булып тора. Бу әсәр авторы Мостафа Җәлалетдин паша, Зыя һәм Әхмәд Вәфыйк пашалар кебек үк, Госманлы тарихының онытылмас шәхесләреннән булганга, биредә аның кыскача биографиясенә тукталып үтик.

Мостафа Җәлалетдин паша — 1848 ел революцияләрендә катнашканы өчен, ватанын ташлап китәргә мәҗбүр булган поляк асылзадәләреннән Константин Боянски (Борзецки) дигән шәхес. Ул 1826 елның 22 апрелендә Клечев [Клезцов] шәһәрчегендә яһүд гаиләсендә туа. Якындагы Влоцлавек [Виолавек] семинариясендәге классик һәм дини мәктәпне тәмамлый. 22 яшендә, Познаньдагы Польшаны азат итү хәрәкәтенә тартыла, 1848 елгы революциядә катнаша. Кузгалыш бастырыла. Кайбер иптәшләре белән Константин ул чакта маҗар һәм

поляк милләтләренә юмарт куенын ачкан Госманлы иленә кача (1849). Госманлы хөкүмәте яшь поляк милләтчесенең гомуми һәм хәрби белемнәрен, аерым алганда, карта сызуга маһир осталыгын искә алып, йөзбашы дәрәҗәсе бирә һәм Госманлы гаскәренә кабул итә, карта әзерләү бүлегенә эшкә урнаштыра. Йөзбашы Боянски рәсми рәвештә ислам динен кабул итә. Шәйхелислам аңа Мостафа Җәлалетдин дигән исем бирә, генераль штабтагы бригада генералы Гомәр паша кызына өйләндереп, бер мөселман төрек гаиләсе барлыкка килә. Сугышка китмәгән вакытларында Өскударда Карачыәхмәт каберлеге карамагындагы тыйнак бер өйдә музыка, танцыларны, типтереп яшәүләрне онытып көн кичерә. Европа колонияләре белән бәйләнеше булган бу поляк аксөягенең иң бирелеп башкарган эше — сугыш. Ул кече яшеннән, поляк революционеры буларак, туган илен коллыктан коткару нияте белән 1848 елгы революциядә катнаша. 1850 елдан 1870 елга кадәр, төрек офицеры буларак, яңа ватанын яклап, авыр сугышларда катнаша. Берничә мәртәбә яралана. Ниһаять, 1875 елдагы Карадаг [Черногорие] сугышында дивизия генералы (генерал-лейтенант) дәрәҗәсендә катнашып, җәядән атылган ук ярасыннан шәһит китә. Мостафа Җәлалетдин Слипоздагы мәчет йортында җирләнгән (Аллаһ рәхмәт әйләсен). Хәрби хезмәте турындагы шушы берничә юл шәһит Җәлалетдин пашаның яңа ватанына никадәр тирән, самими мөнәсәбәттә булганын ачык күрсәтә[10]. Яулар, походлар туктап торган заманнарда үзе өчен яңа дин — ислам һәм үзе төпләнгән җир — Госманлы өлкәсе өчен файда китергән әсәрләр язу белән шөгыльләнә. Тумыштан булган сәләтен туктаусыз уку, өйрәнүләр белән үстереп, Җәлалетдин паша белемнең күп тармакларында үзен зирәк талант иясе итеп таныта. Ана теле — полякчадан тыш латин, француз, немец, рус телләрендә иркен сөйләшә. Тарихи белемнәрен дә киңәйтә. Ул тумыштан сәнгатькярлек сәләтенә ия. Рәсем сәнгате белән җитди шөгыльләнмәсә дә, мәшһүр рәсемнәрен иҗат итә. Харита сызу остасы була. Госманлы гаскәре башлыклары беренче очрашуларда ук аның бу сәләтен югары бәялиләр, гаскәргә алып, Генераль штабның карталар төзү бүлеге җитәкчесе итеп тәгаенлиләр. Аның майлы буяулар белән ясаган рәсемнәренең кайберләре Думабакча сараенда сакланып калган. Өендә яшәгәндә, хәрби эш, тарих, биология буенча фәнни тикшеренү эшләрен яза. Әсәрләре байтак булса да, аларның «Иске һәм яңа төрекләр» һәм «Заманыбыз сугышлары» исемлеләре генә басылган. Әлеге әсәрләреннән кала Мостафа Җәлалетдин паша дусларыннан Али әфәнденең «Бәсыйрәт» газетасында һәм танышларыннан Жан Пиетринең «Курьер д`Ориент» [«Көнчыгыш хәбәрчесе»] газетасында да мәкаләләр бастыра. Әхмәт Рәсим бәйнең хосусый бер хатында: «Басыйрәтче Али бәйнең 1908 елда басылган «Истанбулда (соңгы) ярымгасырлык мөһим вакыйгалар» дигән китабында Мостафа Җәлалетдин әфәнде «Бәсыйрәт»нең корреспонденты дип телгә алына». Пашаның югарыда сөйләнгән «Иске һәм яңа төрекләр» турындагы хезмәте мөһим эчтәлекле һәм кыйммәтле әсәр дип бәяләнә.

Бу сәләтле белем иясенең яңа ватанына файдалы эшләренең кыйммәте каләменең фикер олылыгында гына да түгел. Госманлы иле өчен ул башын сала, җанын фида кыла. Җәлалетдин пашаның затлылыгы, әхлагы кайбер кешеләр күңелендә аңа карата хөсетлек уята. Гаскәрбашы Гомәр Лотфи паша вафатыннан соң, яңа сәргаскәр [гаскәр башы] Хөсәен Ауни паша 44 яшьлек генерал-майор дәрәҗәсендәге Мостафа Җәлалетдин пашаны отставкага чыгара, эштән читләштерә (1870). Хөсәен Ауни паша сөргенгә җибәрелгәч тә,

[10] Ул Карадаг (Черногория, 1852), Рус (Кырым) сугышы (1853-1856), Багдад (1857), Карадаг (1861), Гирид (Крит, 1857), Һәрсәг (Герцеговина, 1875), Карадаг (1876) сугышларында катнаша. Бу сугышларда башы, муены, уң кулы, уң аягы яралана һәм соңгы Карадаг сугышында алган ярадан шәһит була. — *Й.А.*

Җәлалетдин пашаны эшенә кайтаралар һәм серблар белән сугышта җиңү казанган өчен, вафаты алдыннан, генерал-лейтенант дәрәҗәсе бирәләр.

Мостафа Җәлалетдин пашаның улы — Генераль штаб хезмәткәре генерал-лейтенант Әнвәр Җәлалетдин паша әле сәламәт. Ул миңа әтисе хакында язылган, әмма басылмаган «Фикерләрем» дигән кулъязма әсәре белән танышырга рөхсәт итте. Мәрхүмнең биографиясен язганда, мин бу чыганактан да файдаландым. Моның өчен Әнвәр пашага рәхмәтемне белдерәм. Әнвәр Җәлалетдин паша, әтисе юлыннан китеп, мәрхүмнең кайбер каралamaларыннан файдаланып, «Әдәбият-и гомумия» мәҗмугасында [журналында] төрекчелек тарихына һәм филологиясенә багышланган мәкаләләр бастыргалый. Ул мәкаләләрне туплап, бер җыентык итеп чыгарырга тәкъдим итәм.

БЕРЕНЧЕ «ТӨРЕКЛӘР» ХӘРӘКӘТЕНЕҢ ТУУЫ ҺӘМ БЕРЕНЧЕ АДЫМНАРЫ. ГОМУМИ СЫЙФАТЛАМАЛАРЫ

Тел өлкәсендә төрекчелек фикеренең беренче ачык билгеләнгән эзләрен Ибраһим Шинаси әфәнденең әсәрләрендә очраттык. Мәрхүм Әхмәт Мидхәт[11] әфәнденең вафатына багышланган биографиясен язганда, Шинаси — Госманлы әдәбиятында төрекчелек фикерен башлап җибәрүче, дигән нәтиҗәгә килгән идем. Шинасинең төрекчелек идеясен, фикерен һәм телен, әдәбият тармагында — Зыя паша, сүзлек эшендә — Әхмәд Вәфыйк паша, филологик тикшеренүләр өлкәсендә Мостафа Җәлалетдин паша дәвам итте. Әхмәд Вәфыйк паша тарафыннан пантюркизм юнәлешендә дә кайбер чаралар оештырыла. Җәлалетдин паша исә төрек филологиясеннән тыш төрки халыкларның этнологиясе һәм тарихы белән дә мавыга. Госманлы җирендә беренче мәртәбә Көнбатыш чыганакларына нигезләнеп, төрек тарихына, төрек этнологиясенә багышланган әсәрен мәйданга китерә. Җәлалетдин пашаның «Иске һәм яңа төрекләр» исемле әсәре — филология, этнология, тарих һәм сәясәтне өйрәнүгә юнәлдерелгән китап. Гыйльми төгәллеккә китерелмәгән булса да, төрек рухын, төрек мәнфәгатьләрен яклауга юнәлдерелгән. Француз телендә язылган Шинаси әсәрләрендә ике әдәби юнәлеш башлангычлары бергә катнашкан, ә кайбер урыннарда аерым-аерым чәчелгән. Бу башлангычларның бер өлеше уңай шартларга юлыгып чәчәк атты, Нәмыйк Кәмаллар, Габделхак Хәмидләр[12], Тәүфикъ Фикрәтләр[13], Халит Зыялар[14] кебек җимешләр бирде. Икенче бер тармагы чәчәк атып, Әхмәд Мидхәт, Шәмсетдин Сами, Мәхмәт Әмин, Нәҗиб Асим, «Төрек йорты», «Яшь каләм»нәр кебек җимешләр бирде. Бу ике тармак, ике мәктәпнең дә остазы — Шинаси. Ул — халык мәкальләре тупланган, бармак хисабы үлчәмендә шигырь язган, чит алынма сүзләрне телебездән куарга керешкән Шинаси — «Төреклек җәмгыяте»нең имамыдыр[15].

Госманлы матбугатында чын һәм көчле җитди тикшеренүләр белән шөгыльләнгән язучы һәм тарихчы Әхмәт Рәсим бәйдән[16] «төрекче»лек фикеренең кайчан һәм кем тарафыннан мәйданга чыгарылуын сорашкан идем, ул: «Матбугатыбыз тарихында, авырлыкларны йөкләп, беренче мәртәбә Госманлы җәмгыятендә милләт сүзен телгә алган шәхесләр Шинаси илә Нәмыйк Кәмал[17] булды. «Тәфкыйрь-и әхбар»ның чыга башлавыннан алып, «төрек» атамасы «Милләт Госмания» дигән сүзгә ачыктан-ачык каршы куелды», — дигән иде.

[11] Әхмәт Мидхәт (1844-1913) — төрек журналисты, язучы, тәрҗемәче һәм нашир.
[12] Габдлехак Хәмид (1852-1937) — төрек язучысы, төрек әдәбиятында романтизмга нигез салучыларның берсе.
[13] Тәүфикъ Фикрәт (1867-1915) — төрек шагыйре һәм журналисты.
[14] Халит Зыя Ушаклыгөл (1866-1945) — төрек язучысы һәм дәүләт эшлеклесе.
[15] Акчура Й. Әхмәд Мидхәт әфәнде // Төрек йорты. — №3. — Б.170.
[16] Әхмәд Рәсим бәй (1876-1933) — төрек язучысы.
[17] Нәмыйк Кәмал (1840-1888) — төрек шагыйре, журналисты, прозаигы һәм җәмәгать эшлеклесе.

Шинасинең төрек сүзлеген төзи башлау вакыты 1865-1870 елларга, Зыя паша иҗатында төрекчелек фикерләренең беренче күренүе дә шушы еллар аралыгына туры килә. «Эмиль» тәрҗемәсенең кереш сүзе азагында язылу вакыты «Женева, 15.07.1871 ел» дип күрсәтелгән. Әхмәд Вәфыйк пашаның «Ләһҗәи Госмани»сы языла башлануы һәм басылып чыгуы да шушы вакыт аралыгына туры килә. Җәлалетдин пашаның «Иске һәм яңа төрекләр» китабы да 1869 елда басылган. Шул мәгълүматларга нигезләнеп, Госманлы төрекләре арасында төрекчелек хәрәкәтенең башлангыч дәвере һәм беренче адымнары 1865-1879 елларга туры килә дип билгели алабыз.

ТӨРЕКЧЕЛЕК (ТӨРКИЧЕЛЕК) ХӘРӘКӘТЕНӘ ОРИЕНТАЛИСТЛАР ТӘЭСИРЕ

Төркилек фикере һәм төрекчелек (төркичелек) хәрәкәте башлап солтан Габделгазиз хакимлеге чоры урталарында Көнбатыш төркиләре (Госманлы төрекләре) арасында формалаша. Ул төрекләрнең гомуми бер сурәттә Көнбатыш (Европа) фикеренә тартылу һәм европалашу рухы белән сугарылу вакытына туры килә. Шуңа күрә бу хәрәкәт формалашуы де Гюйе, Сильвестр де Саси, Абело де Ремусат, хәтта Артур Ламблей Девидс кебек Европа ориенталист галимнәренең тәэсире астында бара, дип билгеләүне дә мин бәхәссез дип саныйм. Шинаси Сильвестр де Сасинең[18] гаилә дусты булган. Җәлалетдин паша «Иске һәм яңа төрекләр»дә де Гюйенең «Хуннар тарихы»ннан киң файдалана. Артур Ламблей Девидсның «Китабел гыйльмен нәфи фи тәхсил-и сарф-у-нәхв-и төрки» әсәренең французчадан тәрҗемәсен авторның әнисе 1833 елда солтанга бүләк итә. Артур Ламблей Девидс — англияле яшь яһүд ориенталисты. Әсәр, башлыча, төрек теленең сарыфы (морфологиясе) һәм нәхүенә (синтаксисына) багышланган булса да, баштагы бүлектә бөтен төрек тарихы, төрек теле һәм мәдәнияте хакында кыскача белешмәләр бирә. Белешмә шул заманга кадәрге Көнчыгыш белгечләре туплаган мәгълүматларга таяна. Ламблей төркиләр тарихы сөземтәсендә үзенә кадәрге ориенталистлар төркиләрне татар дип атап йөртүләрен билгели дә, моны тәнкыйтькә тота һәм бу кабиләнең исемен төрки дип атауның дөреслеккә туры килүен яклый. XIX гасыр урталарында яшәгән Шинаси һәм Вәфыйк пашалар кебек мәгърифәтчеләр бу әсәрләрне белмәгәннәрдер, дип уйлый алмыйм. Алга таба Вамбери[19], Радлов[20], Леон Кахоннар[21] кебек XIX гасыр азаклары ориенталистларының тәэсирендә төркичелек фикеренең күп халыклар арасында куәтләнүен күрербез. 1865-1870 елларда Госманлы төрекләре арасында төрекчелек фикере мәйданга килүенә башка тәэсирләр булганын да билгеләп үтик.

ТӨРЕКЧЕЛЕК (ТӨРКИЧЕЛЕК) ФИКЕРЕ ҺӘМ ИНГЛИЗ-РУС МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ

Мәгълүм булганча, 1860 елларда рус биләмәләренең Азия кыйтгасында киңәйтелүе инглизләрне куркытырлык дәрәҗәдән ашып китте. Русиянең Көнбатыш төркиләрен, ягъни Госманлы солтанлыгы биләмәләрен басып алуга юнәлдерелгән, йөз елдан күбрәк вакытка сузылган һөҗүмнәре XIX гасыр урталарында Көнбатыш Европа дәүләтләренең берләштерелгән кораллы каршылык күрсәтүе белән туктатылган иде. Рус империясе бу каршылык ачуын кайтарыр өчен, Көнчыгыш төркиләре — Урта Азия халыклары өстенә дәһшәтле рәвештә ябырылды. 1860 еллардан башлап руслар Урта һәм Көнчыгыш Төркестан якларында һөҗүмгә күчтеләр. 1865 елда генерал

[18] Сильвестр де Саси (1758-1838) — француз лингвисты һәм ориенталисты.
[19] Арминий Вамбери (1832-1913) — маҗар шәркыятьчесе, сәяхәтчесе һәм политолог.
[20] Василий Васильевич Радлов (1837-1918) — мәшһүр рус шәркыятьче-тюркологы, этнограф, археолог һәм педагог.
[21] Леон Кахон (1841-1900) — француз язучысы һәм тарихчысы.

Черняев[22] Урта Азиянең иң зур шәһәре Аксак Тимернең башкаласы — Ташкентны[23] басып алды. 1867 елда «Төркестан вилаяте» исеме астында Урта Төркестанның зур өлеше Русия империясенә кушылды. 1868 елда, вассал дәүләт рәвешендә Бохара әмирлеге Русия патшалыгына буйсындырылды. Шул елларда Көнчыгыш Төркестанның Кашгар өлкәсе, Мөхәммәт Ягкуб бәк[24] җитәкчелегендә Кытай хакимиятенә каршы баш күтәреп, Русия хөкеме астына күчәргә омтылыш ясый. Голҗә өлкәсе 1865 елда Кытайга буйсынудан чыгып, 1871 елда Русия кул астына күчә. Кыскасы, 1860-1870 елларда Урта Азия төркиләре Русия тәэсире һәм басып алулары казанында кайныйлар. Русиянең Азия киңлекләрендә көнчыгышка һәм көньякка җәелүе инглизләр нервысына бик каты тия. Тиздән казак атлыларының Һиндстан чикләренә кадәр килеп чыгу ихтималы инглизләрнең йокысын качыра. Алар Мөхәммәт Ягкуб ханга (Кашгарга) илчеләр күндерәләр. Башка вак-төяк ханнар белән дә рәсми булмаган бәйләнешләр урнаштырырга тырышалар. Ягкуб хан да, Һиндстан (инглиз колониясе) вице-губернаторына илче җибәреп, инглизләр белән союз эзли.

Шулчакларда Баб Гали [төрек солтаны сарае] белән дуслык мөнәсәбәтләрендә булган Англия премьер-министры Саин Джеймс кабинеты көнбатыш (Госманлы) һәм Көнчыгыш төркиләренең дин һәм нәсел берлегеннән мәйданга килгән бәйләнешләреннән файдаланырга кирәклекне дә истән чыгармый. 1857 елда Һиндстандагы синаһилар [һинди солдатлар] күтәрелеше вакытында, хәлифә сыйфатында, солтан Габделмәҗидтән Һиндстан мөселманнарына инглиз королевасына итагать сакларга чакырган бер фәрман яздырып алудан тайпылмаган инглиз сәясәтчесе әчке кыенлыклар хәлләрендә калган Урта Азия ханлыкларын Госманлы төрекләре белән бәйләнеш-элемтәгә кертергә тырышлык күрсәтүе бик мөмкин. Дөрестән дә, Ягкуб хан, кузгалышы җиңүгә ирешкәч тә, инглиз илчелеге киңәше буенча, төрек солтанына яклау, ярдәм сорап, илчесен җибәрә. Илче Истанбулда тантаналы рәвештә кабул ителә. Ягкуб ханга сугыш кирәк-яраклары, киңәшче итеп хәрби белгечләр җибәрәләр. Затлы бүләкләр — сокландыргыч бизәкле, ике ягы да үткен кылыч, флаг һәм солтанның хаты күндерелә. Кайту юлында, аларга Һиндстан һәм Төркестанның инглиз илчелеге төркеме кушыла (1873). Шулвакыттан Кашгар ханлыгы мәчетләрендә җомга хотбәсенә төрек солтаны-хәлифә исемен кушып укыйлар .

Ул чакларда Кашгар мәсьәләсе һәм Ягкуб хан хәлләре Истанбул матбугатының да игътибар үзәгендә була. «Шәҗәрәи төрек»нең чыгатайчадан госманлы төрки теленә тәрҗемәсе, Вәфыйк пашаның Урта Азия төрки теле сүзлегенә ябышып ятуы, Шәмсетдин Сәми бәй сүзе белән әйткәндә, «гасырның галимнәреннән һәм әдипләреннән Көнчыгыш һәм Көнбатыш әдәбиятына һәм яңа фәннәр мәсьәләсендә Европа телләренә тартылган» дәүләтнең һәрбер дәрәҗәле кешесе солтан Габделгазиз дәверендә чыгатай телен өйрәнергә керешү — Урта Азия, ягъни Көнчыгыш төркиләре Истанбул мәгърифәтчеләре күңелен ни дәрәҗәдә биләп алуына тагын бер дәлил.

Көнчыгыш төрекләре башына килгән һәлакәтле вакыйгалар, Русиянең Урта Азиягә табан җәелүенә каршы инглизләр һәм аларның сәясәтчеләре Көнбатыш (Госманлы төрекләре) төркиләре белән бәйләнешкә кереп, аларны бу вакыйгаларга катнашырга күндерүен төркичелек хәрәкәтенең башлануы, дип билгеләп булмыймыни?!

Төрекчәдән ***Мәсгуд Гайнетдин*** *тәрҗемәсе* ■

[22] Михаил Григорьевич Черняев (1828-1898) — рус генералы, Төркестан генарал-губернаторы.

[23] Автор үз заманы конкретлыгында гомумиләштерә. Аксак Тимер империясе башкаласы — Сәмәрканд.

[24] Мөхәммәд Ягкуб бәк Бәдөләт (якынча 1820-1877 еллар) — 1860-1870 елларда Кашгар хакиме.

[25] Кашгар хакиме Ягкуб ханның яңа төрки дәүләте төзү вакыйгалары һәм, гомумән, Урта Азия хәлләре Мәхмәт Акиф бәйнең 1885 елда Истанбулда басылган «Кашгар тарихы» китабы нигезендә бирелә.

Әдәбият

Тукай яшен узган чакта
Сөрлекте шагыйрь аты.
Яшьнәде камчы офыкта –
Вакытның кулы каты.

Марсель Галиев

КУТАДГУ БИЛИК*

(Котайткыч белем)

ЙОСЫФ БАЛАСАГУНИ
(ЙОСЫФ ХАСС-ХАҖИБ)

БӘХЕТНЕҢ ФАНИЛЫГЫН ҺӘМ ДӘҮЛӘТНЕҢ ВАФАСЫЗЛЫГЫН АҢЛАТУ

Бу Айтулды тапты бар теләгәнен,
Тик муртайды иске котның терәге[1].

Ни яхшы әйткән бер белемле белкә:
«Төгәл булса нигъмәт, калмас мәңгегә».

Тагы шәбрәк әйткән икенче бере:
«Тулы нигъмәт соңра бетәр гомереӊ».

Иң әйбәт әйтелгән бер галим сүзе
(Галимнәрнең сүзе — наданга күзлек):

«Түбәннәр үрләр һәм биекләр түнәр,
Елгырлар тынар һәм яркыннар[2] тонар.

Ни хәлләр булса да, оныт; бел аны:
Һәр кәмалның шиксез килә зәвалы[3]».

Айтулды да беркөн җиткәч кәмалы,
Җуйды сәламәтен, калды тик малы.

Кимелүгә китте нәкъ тулган ае,
Котылгысыз кышка юнәлде җәе.

Ил рәте бозылды, китте аш таты,
Күңел төште, каты тотты хастасы.

Ашавы бозылгач, көче кимеде,
Камыш кебек буе сынды-бөгелде.

Аяк чалып екты аны чирләре,
Түшәгенә ятып, моңлап иңрәде.

Табиблар җыелды һәм тикшерделәр,
Нинди чир икәнен әйтеп бирделәр.

Кайсы әйтте: «Каны тотадыр моны,
Агызырга кирәктер бераз канын».

Кайсы: «Эчйомшарткыч эчерик, — диде. —
Эч каткан, чарасын күверик[4]», — диде.

Кайсы салкынлатты, эчерде гөләп[5],
Кайсы ясап бирде шифалы шәраб.

Үлән-им калмады, барсын кылдылар,
Ни ярардай булса, табып килделәр.

Шифасы булмады — авыруы артты,
Хәле бетеп, кайчак аңын югалтты.

Ни ди, ишет, әнә фикерле кеше
(Фикерле кешеләр — җәмгыять башы):

* Дәвамы. Башы журналның 2013 елгы 10, 11, 12 нче саннарында.
** Курсив илә язылган юллар нәкъ оригиналдагыча, тик сүзләрнең фонетик йөзе генә борынгыча.
[1] Бу юллардан күренгәнчә, борынгы төркиләр агач кот ясап, аны җиргә утыртып куйганнар (ихтимал, борынгы язмалардагы **баган** дигәне шулдыр).
[2] Яркын (татар сөйләшләрендә дә бар) — якты янып торган.
[3] Шундый татар мәкале бар, «иң югары уңыштан соң төшенкеләнү килә», дигән мәгънәдә.
[4] Күверү — чара күрү, бара күр, яза күр кебек тәгъбирләрдә асылда «күз белән күрү» сүзендәге күрү түгел, ә «күверү» — башкару, эшләү ул. Бу этимологик җәһәттән дөрес әйтелеш диалекталь сөйләмдә дә саклана.
[5] Гөләп — билгеле шифалы үсемлек, монда борынгы «роза суы» мәгънәсендә.

«Кирәк шалиса кат, кирәк тирьяк куш,
Өгет, чурныйлар бир, кирәк — митридус[5].

Кирәк утачы[6] һәм кирәк кам[7] килсен,
Үлемгә дару — ул кайда? Кем белсен».

Гамьсез булма, и дус, тере чагыңда:
Үлем көтә сине киләчәгеңдә.

Ишетте Илбик бу Айтулды хәлен —
Батырган аңа чир үлем чәңгәлен[8].

Айтулдыга килде, сорашты аның
Нинди әхвәлләрдә авырып ятканын.

Илбик әйтте: «Сиңа ниләр булды соң?
Ни авыру булды бу, ничек йоклыйсың?»

Һәм Айтулды әйтте: «И Илбик котлым,
Әҗәл чире бу — юк аның им-уты.

Житеш иде эшем — китте җитешлек,
Бөтен иде дөньям — инде җимерек.

Таңым тәбрик итәр иде һәр көнне,
Хәзер ятам — таң һич атмас шикелле.

Яшәү сөенече ташлады мине,
Дөнья миннән йөзен чөерде инде.

Яшәү шатлыклары калдылар артта,
Сагыш, газап, кайгы көннән-көн арта.

Мәңгегә аерылам инде мин синнән,
Тик шуңа кайгырам, шуңа үкенәм.

Ни дигән акылдар белкә — ил бәге
(Барча юлбашчыдан иң игерәге):

«Ни шәп булыр иде бу дәүләт килеп,
Холыксыз тай кебек китмәсә җилеп[9].

Нинди әйбәт нәрсә — идарә эше,
Әгәр яши бирсә, үлмичә кеше.

Ни күрекле идем егет чакларда,
Ни шәп булыр иде яшьлек саклanса».

ИЛБИК ҮГЕТЕ

Илбик әйтте: «Куй бу сүзне, Айтулды,
Юкны сөйләп ятма, син ич акыллы.

Кеше авырыр да, тагын терелер.
Хасталап торучы син генә түгел.

Телеңә ник килә бу ямьсез сүзең.
Күңелеңне нигә бозасың үзең.

Мин тик сиңа карап юанып яшим,
Терелер дип уйлап йөримен, ә син...

Ходай ярдәм итәр. Сөйләмә юкны.
Кайгы учагына өстәмә утын».

АЙТУЛДЫНЫҢ СҮЗЛӘРЕ

Тик Айтулды әйтте: «И Илбик, котлым,
Чирем дәвасыздыр, юк име-уты.

Тумыш зат булгачтын, үләсе ич без.
Күтәрелгән шәйнең чүгәсе шиксез.

Югарыга — түбән, менүгә — төшү,
Сөенечкә — сагыш, ачыга — төче.

Үзем әйткән идем сиңа шундый сүз:
«Сүзем ышанычсыз, холкым тынычсыз».

Кылыгымны әйтеп биргәчтен, инде
Күңелеңне миңа багламас идең.

Үләм мин — моңа син бер дә шикләнмә.
Ышанма «бер тугач, үлмим» дигәнгә.

---

[5] Шалиса, тирьяк, өгет, чурный — борынгы дару атамалары; митридус — агу кайтаргыч (борынгы грек Митридат исеменнән: бу хөкемдар дошманнар агулавыннан саклану өчен, төрле агулар эчеп, шуларга күнегеп караган).
[6] Утачы — үләннәр илә дәвалаучы табиб.
[7] Кам — шаман, барабан кагып күрәзә итүче һәм дәвалаучы.
[8] Чәңгәл — ерткыч кош тырнагы.
[9] Җилү — шәп итеп чабу.

Инанычсыз димә һәм сүкмә мине.
Ташлар безне дөнья, төгәл билгеле.

«Җәфа булды», дип, син миңа җилләнмә.
Сиңа дөнья күбрәк җәфа бирәлә.

Гафил булма — үлем сиңа да килер,
Ышанма дөньяга — ул шундый инде.

Кадерләдең мине тиештән артык,
Хезмәтем булмады хөрмәткә лаек.

Теләгемә җавап түгел үлемем.
Беренче үлүче түгел инде мин.

Ихтыярсыз булып үләм азапта.
Котылыр җирем юк, юл юк ян-якка.

Юк идем — түрәтте тәңрем, үстерде,
Зәгыйфь олан идем — миңа көч бирде.

Шома йөзле идем — сакалтай булдым.
Козгынкара идем — аккоштай булдым.

Буем уктай иде — инде иелде,
Тереклек төкәнде — җитте үлемем.

Ничек әйбәт әйткән бөек аксакал
(И, алйөз егеткәй, моңа колак сал):

«Чәчләреңә аккош төсе кергәндә,
Хисләрең дә ак, саф булсын, и бәндә!

Аккош муенылай бөгелгәч буең,
Аккоштай ак булсын азаккы уең.

Хәзер бул — чәчеңә чал кергән чакта,
Аңдып[10] торган үлем килер кунакка».

Шулай ук бер шагыйрь әйткән бу сүзне
(Ишет, тыңла моны, и күңле изге!):

«Кара чәч агару — үлемнән хәбәр:
Кадерлә гомреңне үлгәнгә кадәр.

Ашыңны ашадың, яшең яшәдең,
Үзең син үлемгә азык-җим хәзер».

ИЛБИК СҮЗЕ

Илбик әйтте: «Сабыр уйла әле бер.
Авыруың — гөнаһлар өчен түләүдер.

Үлә торган булса һәрбер хәлсезең,
Беркем калмас иде уразадан соң.

Ходай бирер сиңа, иншаллаһ, сихәт,
Күңелең төшермә, тыныч кына ят».

Шулай дип Илбик, күр, күтәрде кулын.
«Шифа бир, тәңрем!» — дип,
күр, дога кылды.

Торып чыкты шуннан, сагышка батып,
Төшенке кәефтә сәрайга кайтты.

Өләште мал-туар ярлы халыкка,
«Вәзирем басмасмы, — дип үк, — аякка».

Йолып калса көмеш әгәр үлемнән,
Һәркем шат булачак мондый йолымга.

Йолым биреп калса үлемнән кеше,
Исән калыр иде бай һәм хан башы.

Үлемеңне тыйса җыйган малларың,
Вафат булмас иде җиһандарларың.

Айтулдыга да мал файда итмәде,
Өмет өзде шуннан, кулын селтәде.

Үкенде, әйтте: «И исәр гомерем!
Заяга үтте иң матур көннәрем.

Тереклек кичердем усаллык кылып,
Көчле чагым үтте юкка кызыгып.

Яшендәй яшьнәгән егет мин идем,
Эләктерде әҗәл, инде ни диим?

Хирысланып җыйдым мин дөнья малын.
Кала малым, ә мин китәм югалып.

Озын булды минем кулым һәм телем.
Сулышым кысылды, инде ни диим?

[10] Аңду — аучы турында: сагалап тору.

Шулай ул үкенде, озак елады,
Үкенеч үлемгә дару булмады.

Адәм баласының, һай, кызганычка,
Теләгәнчә түгел гомере — кыска.

Дәрман бар чагында җитми акылың,
Акыл бар, карыйсың — гомрең ахыры!

Көче барда бәндә оныта үзен,
Күк өстеннән, гүя, йөретә сүзен.

Көяз һәм көр булыр. Күрсәтер көчен.
Үлем килгәч, сөйләр тик үкенечен.

Туенса, кыланыр, ата дөядәй.
Ачыкса, агу да ашар бүредәй.

Ниятләрдән бизәр, рәхәттән качар,
Сөйгән ярыннан да тиз ераклашыр.

Үкенде Айтулды, тирән көрсенде.
Әйтте: «Мин күнелек юлын җөтердем[11].

Нигә җыйдым икән мин алтын-көмеш,
Нигә чыгармадым фәкыйрьгә өлеш?

Нигә мин һәрвакыт изге булмадым,
Нигә бик еш сүктем языксызларны?

Тәүдә изге эшләр кыласым калган,
Кирәктә тик усал буласым калган.

Ни файда бар хәзер бу үкенечтән,
Үлем тотты — сүзем өнемне кисте.

Ни ди җете күзле һәм көчле ирләр
(Туры сүзне әйтә тик кодрәтлеләр):

«Барча тын алмышка үлем — соң сулыш,
Иң соңгы керәсе ишегең шул ул».

Нәрсә ул тереклек һәм нәрсә — үлем?
Каян килдем, кая барадыр юлым?

Үләсе булгач, ник туганмын икән?
Елыйсы булгач, ник көлгәнмен икән?

«Үлемнән катырак дөньяда ни бар?» —
Диләр барча гомер кичкән инсаннар.

Бу фикер яңгырый шагыйрь сүзендә
(Мәгънәсен аңласаң, ачылыр күзең дә):

«Катыдан да каты ни каты — үлем.
Үлемне уйласаң, ката күңелең.
Үлем бер диңгездер, кырыйсыз, төпсез,
Беркем үлчәмәгән аның чоңгылын».

Үләрен дә белеп, гафил яшәүче
Үлем тоткач килеп, калачак сүзсез.

Дөнья кызыгына мавыгу колы,
Үлем килсә, уйга калыр — соң булыр.

Күзе сок бәндәләр әйбергә туймас,
Әҗәлдә үкенер — чара табылмас.

Дөнья куып, горур йөргән күп ирләр
Йөрәк ярырлык хәл гүрдә күрерләр.

Сөенеп күп йөргән гамьсез һәр бәндә
Еларга әзердер гүргә кергәндә.

Ни ди, ишет, ушлы, укыган белкә
(Бу сүзне, күр, тоту кирәктер эшкә):

«Ике дөнья бәхетен теләсәң, тыңла —
Гомердә һичкемгә явызлык кылма.

Кылма явызлык, и юньле зат, һич тә,
Игелеккә омтыл сүздә һәм эштә».

Айтулды, үкенеп, бик күп еглады,
Ни эшләсен инде, файда булмады.

Фәкыйрьгә өләште, күр, алтын-көмеш,
Нәселенә калды комарткы өлеш.

[11] Күнелек — гаделлек, җөтерү — бетерү, иске әдәби язмаларда һәм диалекталь сөйләмдә еш очрый.

Күзен күккә текте: «И Иям, тәңрем,
Синнән үзгә мин бер тәңре белмәдем.

Тудырдың, үстердең, бирдең дөньялык,
Бары синнән генә, беләмен анык.

Гыйбадәт кылдым мин сиңа үзем гел,
Әҗәл генә килеп кисте телемне.

Котылыр җирем юк, аңымны җуйдым,
Бары тик рәхмәтең насыйп булсын, дим.

Яманлыклар кылдым түбәнлек белән,
Мәрхәмәт кыл инде, и газиз Иям.

Исәр булдым — зая үтте көннәрем.
Билектә изгелек кыла белмәдем».

Сүзен кисте, бераз уйланды торып.
Агызды күз яшен, үз углын күреп.

АЙТУЛДЫНЫҢ УГЛЫ ҮГДЕЛМЕШКӘ ҮГЕТЕ

Берәү иде углы бу Айтулдының,
Кече иде яше шул бер углының.

Исеме Үгделмеш, ипле, килбәтле,
Йөзе күрекле һәм һәр эштә дәртле.

Чакырды Айтулды углын янына.
Кочып алды — күздән яше агыла.

«Менә үләм инде мин, газиз углым,
Сиңа калды барча мөлкәт, урыным.

Син идең күз нурым чын мәгънәсендә,
Исән кал, иге бул ятимлегеңдә.

Бу хакта шәп әйткән төрки бойрыгы[12]:
«Күрер күзнең нуры була кыз-угыл».

Угыл-кыз хәстәре — төпсез диңгездер.
Саулыкны ала ул, саргайта йөзне.

Каю кемдә, диләр, угыл-кыз була,
Йокылары аның тынгысыз була.

Угыл-кызы өчен кайгыра ата,
Угыл-кыз атасын атамый хәтта».

Һәм Айтулды әйтте: «И углым, берүк
Сүземне онытма, күңлеңдә йөрет.

Шуны бел: мин сиңа чын ата булдым,
Исеңнән чыгарма — исемем Айтулды.

Тереклеге тулды бу Айтулдының,
Үкенечкә ашап бетте ризыгын.

Бу тереклек татлы, ачыдыр үлем,
Аннан качарга һич калмады юлым.

Мавыктым, дөньяга булдым мин гашыйк,
Ул исә вафасыз — китәдер качып.

Дөнья мине алдап, чакырып көтте,
Күңел бирдем аңар — ул качып китте.

Җәбер кылды дөнья, картайды котым,
Сине аздырмасын, углым, белеп тор.

Кирәкле гамәлне бер якка куеп,
Кирәксезне кылдым, һәвәскә оеп.

Өермә шикелле тузан туздырып,
Гомер үтте-китте — зая уздырдым.

Бу хәлемдә файда итми мал, ришвәт,
Кем дә кулын бирми, булмый бер нишләп.

Ишет, ни ди миндәй сискәнгән кеше,
Үлем хәлен тирән хисләгән кеше:

«Бетеп китә тәмам, күргәч үлемне,
Ушлының уш-исе, галим гыйлеме».

Үлемнең чәңгәле шундый шәфкатьсез,
Кеше өчен үлем — юньсез, гадәтсез.

Корылган сәрайны боздыра үлем,
Җыелган җыенны туздыра үлем.

Менә ничек әйткән шигырь остасы
(Укысаң хәлемне, углым, аңларсың):

---
[12] Бойрык, боерык — борынгы титул, «министр».

КЫЙТГА

«Һәрнәрсәгә хәйлә-чара табыла,
Үлемгә чара да юк һәм бәй дә юк.
Хәйләгә бирешмәс һичбер шәй дә юк,
Һәм каршы торгысыз һичбер хәйлә юк».

Ишетте угыл, күр, атасы сүзен.
Сүз ачты, атага әверде йөзен,

Әйтте: «Әй, атам, бер сүзем бар сиңа,
Аны әйтим мин һәм җавап бир миңа.

Бу дөньяда яшәп күп эшләр кылдың,
Укыдың, ирдәмле, белдекле булдың.

Сораштың, тыңладың, өйрәндең чынлап,
Яшәдең дөньяны күзәтеп, сынап.

Үлемгә каршы һич юкмы чара?
Булса, үз хәлеңдә кулланып кара.

Әгәр бүтән хәйлә чыкмаса барып,
Бөтен мөлкәтеңне куллан, кыл сарыф.

Башыңны хәзинә йолса, тагы да,
Исән булсаң, алтын-көмеш табыла.

Ишет, ни ди, әнә ачкүз түгел зат:
«Икмәк-тозың булса, ир бул, бул юмарт».

Өләш малны илгә, ашат һәм эчер,
Мал сине кичерә[13], син аны кичер.

Иргә малдан бигрәк исәнлек кирәк,
Кошка җимнән бигрәк зәңгәр күк кирәк.

Тере зат теләккә ирешер бер көн,
Исәнлегең булса, һәрбер юл иркен».

АЙТУЛДЫНЫҢ ҖАВАБЫ

Җавапта Айтулды әйтте: «И угыл,
Ишеткел сүземне — бу уйдан түңел[14].

Үлемгә җим түгел алтын-көмешең,
Үлемне тыялмас гыйлемле кешең.

Үлемне тыялса бу дөнья җиме,
Үлмәс иде бер дә хан, бийләр бийе.

Хәкимнәрне хикмәт үлемнән йолмый,
Акыллы затлар да аннан котылмый.

Үлемнән коткарса иде угыт-им,
Утачылар яшәр иде һәрдаим[15].

Изгелегең күреп, үлем аяса,
Пәйгамбәрләр үлмәс иде ләбаса.

Тумыш икән, димәк, үлемгә дучар,
Үлем тимәс көбә кигән кемнәр бар?

Бу дөнья бер арбат[16] — килгәннәр китәр,
Җир — яган, аждаһа: йотар да йотар».

ҮГДЕЛМЕШНЕҢ СҮЗЛӘРЕ

Тыңлады Үгделмеш, әйтте: «И әти,
Үлем хәлен яхшы беләсең, әйе.

Нигә гафил булдың, гомер үткәреп,
Нигә илерәсең хәзер, үкенеп.

Каласы мал-мөлкәт — нигә җыярга?
Өләшергә иде аны сиңарга.

Күрсә кеше — гомер узган гафләттә,
Гаепләсен үзен генә, әлбәттә.

Бүген үкенүдән ни мәгънә, ата?
Башны җиргә орып төзәлми хата».

АЙТУЛДЫНЫҢ ҖАВАБЫ

Һәм Айтулды әйтте: «И углым, ишет.
Миннән гыйбрәт алып, гомреңдә эш ит.

---

[13] «Кичерә» сүзе оригиналда «коткара, саклый» мәгънәсендә кулланылган.
[14] Түңелү — баш тарту, ваз кичү.
[15] Угыт-им — үләннәрдән ясалган дару. Утачы —табиб, үләннәр илә дәвалаучы. Борынгы ядкярләрдә бу сүзләр еш очрый.
[16] Арбат — борынгы сәүдә юлларындагы кунакханә.

Гафиллек түбәнгә орды — үкенәм.
Гафил булма, углым, инде син менә!

Туу хәле үзе үлемнән хәбәр,
Карышсаң да, әҗәл алыр да китәр.

Үләсе зат инде вакытка тоткын,
Ае-көне җитсә, кузгалмас ботың.

Бу бапта шәп әйткән бер шагыйрь теле
(Аңласаң мәгънәсен — бик тә үтемле):

«Һәрнәрсәнең вакыты-көне билгеле,
Тын алуның хәтта саны билгеле.

Ел, ай, көн — тереклек исәбе болар,
Сиңа тиеш гомер үлчәме болар».

Һәм әйтте Айтулды: «Күрче, и угыл,
Минем хәлдән гыйбрәт ал һәм уяу бул.

Сагышым син минем, бердәнбер моңым!
Кечелектә ятим каласың бүген.

Ничек яшәрсең син, калгачтын миннән?
Минем юк сагыш һәм моңым бүтән.

Балага атаның хезмәте сеңә:
Угыл үсә ата тәрбиясендә.

Кырыс тәрбиядә ул була изге,
Якты була ата-ананың йөзе.

Каты тоталмаса, азына угыл,
Үстерүең әрәм — син аннан түңел!

Булсын дисәң углың белемле, ипле,
Дилбегәне кыска тот — шулдыр име.

Ни ди, ишет, угыл үстергән кеше
(Башыннан күп кичкән һәм шактый яше):

«Бигүк иркә үссә углың-кызың,
Соңын булыр яшьле һәм моңлы йөзең.

Яшьтән үк юл куйса әрәм ашарга,
Углыннан да бигрәк гаеп атада.

Угыл-кызы булса юньсез һәм ипсез,
Атасы гаепле, бала гаепсез.

Ата углын тотса яшьтән үк кулда,
Үсеп җиткәч, шатлык күрер углыннан.

Углыңны кырыс тот, и ата кеше,
Соңыннан булмасын синнән көлүче.

Угыл-кызга өйрәт белем, һөнәрне,
Балаң булсын юньле, ипле, ирдәмле».

ҮГДЕЛМЕШНЕҢ ҖАВАБЫ

Җаваплап Үгделмеш әйтте: «И әти,
Мин синең кайгыңда көям һәм төтим.

Теләмим синнән соң тере калуны,
Күрергә язмасын матәм кайгыңны.

Синең урыныңа ятыйм, йа Хода,
Шуны булдыр һәм мин калмыйм кайгыда.

Әгәр инде миңа килсә әҗәлем,
Димәк, миңа шулай язган әзәлдин[17]...

Тәңре хөкеменә бизәк ул — сыгыт[18],
Ул сыгыт йоласын без үтәп чыгыйк.

Моңача дөньяга килеп киткәннәр,
Дөньяны калдырып, шулай иткәннәр.

Белер идең инде: дөнья — җәфачы,
Гафил булып килдең, күрми җәфасын.

Бөтен дөнья малын бер учка алган
Кешегә тик ике кисәк бүз калгай.

Тереклегең өчен үкенсәң үзең,
Үкен, тоташ ела — корытма күзең.

[17] Әзәлдин — язмыш китабында язылганча.
[18] Сыгыт — мәҗүси җеназа, мәрхүмне искә алып елау. Бу сүз хәзерге татар сөйләшләрендә дә бар.

Янə кайтып килмəс кичермеш көнең,
Нишлисең, ап-анык инде китүең.

Минем өчен булса бу сагышларың,
Сагышланма — юктыр файдасы аның.

Түрəтелгəн идең, түрəлгəн — үлə.
Түрəлгəннəр үлə, түрəткəн кала[19].

Миһербанлы идең ата буларак,
Лəкин рəхимлерəк булыр бер Аллаһ.

Сине ул түрəтте, сиңа кот бирде,
Миңа тагы шуны бирмəсме инде?

Кадерсезгə кадер тия аңардан,
Һəркемгə бирə һəм ала яңадан.

Бу хакта бер белкə əйткəндер сүзен
(Акыллылар сүзе — наданга күзлек);

Шуны да аңла: бик хикмəтле бу сүз,
Болганчык уеңны шул сүз илə сөз:

«Газиз ул гыйззəтле бер газиз һаман,
Һичкем тарафыннан яратылмаган.

Кадерсезгə — кадер, көчсезгə — терəк,
Яманга — хурлык һəм яхшыга — бүлəк».

Ишеткəч Айтулды, күр, бу сүзлəрне,
Кул күтəреп, күккə текте күзлəрен.

Догалар укыды, кылды күп шөкер,
Ходай биргəн өчен углына фикер.

Əйтте: «Углым, булды күңелем бөтен,
Ходай бирсен — тулы булсын бəхетең.

Дөрес əйткəн ушлы берəү бу сүзне
(Бу сүз җете итə күңелең күзен):

«Ходай кемгə бирсə уш, акыл, гыйлем,
Телəге күп була андый кешенең.

Кемнең холкы иге, кылмышы уңай —
Телəгəнен табар: яктырыр көн, ай.

Күп уңышка нигез иге кыланыш.
Бер иге холыктан мең-мең куаныч».

Күтəрде Айтулды тагын куш кулын,
Тагын да шөкердə, догада булды.

«И Ходаем, — диде, — үзең ялттың,
Сансыз җан асрыйсыз карап-ашатып.

Юктан бар иттең син, бирдең җан-котны,
Языклы колыңмын, тупас бер утын.

Рəхимле булдың син миңа һəрчакта.
Ирештем мин һəрбер телəк-максатка.

Татылдылар барча лəззəт-нигъмəтлəр,
Сөенеп əйтəмен — күп канəгатьлəр.

Хөкемең иреште — китəмен менə,
Урыныма кала углым-бер генəм.

Ата идем əле — бу ата үлəр.
Иям, бир углыма бəхет һəм гомер.

Рəхəткə якын тот, бəладəн — ерак,
Ике дөньяда да бул аңар терəк.

Яхшыга яран ит, яманнан сакла,
Ашау һəм эчүгə аны моңайтма».

Чын күңелдəн бик күп кылды догалар,
Углымны бəладəн саклар, дип алар.
Ни ди, ишет, əнə, инсан изгесе
(Бу сүз үзе изге кеше билгесе):

«Башук кемгə бирсə ярдəмен Ходай,
Ике дөньяда да бəхетле булгай».

Бирелсə бер колга Тəңредəн бүлəк,
Ике дөньяда үтəлер телəк.

Кемгə насыйп Тəңре миһербанлыгы,
Барча нигъмəтлəргə ул ия булыр.

[19] Ягъни Аллаһ кала.

Бу хакта әйткән бер акыллы кеше
(Акыллы сүзне тот — уңар һәр эшең):

«Иям кемне сөйсә, шул зат сөелә,
Теләгәнен таба, нигъмәте түгәл.

Инанса кемдә-кем тик бер Аллаһка,
Ул меңбер бәланең юлларын яба».

«Янә тыңла, — диде Айтулды, — угыл,
Үлемне онытма, юкса соң булыр.

Ышанма гомергә — җил кебек кичәр,
Гафил булма — дөнья торыр да күчәр.

Ходайга тапшырдым инде сине мин,
Теләсә, саклар һәм бирер иминлек.

Аерылам инде синнән мин бүген,
Үкенечләр белән, елап-яшь түгеп.

Хәзер менә тыңла — мин ниләр белдем,
Шуны, углым, сиңа тапшырыйм, димен».

АЙТУЛДЫНЫҢ НӘСИХӘТЕ

Ни бар яхшы-яман — бары Ходайдан,
Син аңа ышан һәм дога кыл һаман.

Тый нәфес-телеңне, тапшыр Аллаһка,
Киләчәк эшеңне уйлап куй алдан.

Ниләр кирәк сиңа — Аллаһтан үтен.
Берни юк дөньяда аңардан өстен.

Кыйммәт тотсаң аның хөкемен — сүзен,
Аның өчен кыйммәт булырсың үзең,

Юлың тугры булсын — шуны онытма,
Телең тыныч торсын — сүздә очынма.

Фани дөнья өчен утка атылма;
Көчләшмә һәм кермә кеше хакына.

Яшәсәң беркадәр, китәргә юллан,
«Ни бирде бу дөнья миңа?» — дип уйлан.

Җыя белдем малны, җия белмәдем,
Үкенәмен көн-төн — фәтва булмады.

Сиңа калды малым, миңа юк бер дә.
Рәхәтләнеп аша, эч сөенеч берлә.

Тота белеп тотсаң шушы малыңны,
Ике дөньяда да йөзең ал булыр.

Ә тота белмәсәң, күпме булса да,
Мал ахырда йөзгә сары төс сала.

Тугры бул, намуслы һәрбер эшеңдә,
Тугрылыкка баглы сөенечең дә.

Ишет, ни ди, әнә, тугрылыклы ир,
Ике дөньяга да бап кылыклы ир:

«Рәхәт-шатлык белән яшисе килсә,
Юлын тугрылыктан эзләсен кемсә».

«Булыйм чын бәк»[20], — дигән кеше,
әлбәттә,
Тугры барса, җитәр ошбу шәрәфкә.

Кеше арасында бөек зат булыйм,
Дисәң, син ачык тот тугрылык юлын.

Юлың дөрес, холкың ипле булганда,
Нурлы булырсың һәр ике дөньяда».

Һәм әйтте Айтулды: «И, углым, тыңла:
Ит изгелек — саклан тәмуг утыннан.

Һаман игелек кыл, яманнан кач, биз.
Игелек үзеңә кайтачак, шиксез.

Яманга якынлык кылма, ул — агу.
Яманлык елан ул, бер килеп чагар.

Буза эчмә, надан катламга кермә,
Тыныч бул һәм сине изге диярләр.

Бу ике кылыктан изге рух качар,
Алар хәерчелек ишеген ачар.

[20] Бәк — рыцарь, дворян мәгънәсендә.

Ике төрле затка сөйләмә серне
(Шулар җәеп сөйләр — сатачак сине)[21]:

Ошакчы[22] кешене якын итмә син,
Бар сереңне илгә мәгълүм итмәсен.

Танылган, сыналган кешене дус күр,
Сиңа ул мең тапкыр файда китерер.

Һәр сүзне тыңла — тиз ышанма берүк,
Тиз үк ачып салма шәхси фикереңне.

Кешене типсәмә, булма кызучан,
Бәла азмы чыга шундый кылыктан.

Хатынны тый, капка тормасын биксез.
Хатыннар тәмугка илтәләр, шиксез.

Ятны өйдә йөртмә, хатынны — тышта:
Чит кешене кертмә син, сынамастан.

Холкыңны тыныч тот, кайгырма юкка;
Дөнья малы килә тыныч холыкка.

Моңа охшаш тагын бер сүзне ишет
(Ул сүзне эшкә тот, үзеңә иш ит):

Бәк кешегә яхшы юрык-заң[23] кирәк,
Әдәпле-тәртипле йортка кот керә.

Тиле бәккә нигә малың-туарың?
Барыбер ярлыга холкы тиң аның.

Оятсызга якын барма ялгыш та!
Оятлы затларга мең-мең алкышлар!

Һәр эшне уйлап кыл салкын кан белән —
Сабырлыклар илтә максатка гелән.

Ни эш эшләсәң дә, башкар әйбәтләп:
Шулай итсәң генә, уңыш киләчәк.

Телеңә баш бул һәм күзең уйнатма!
Хәләл һәм аз аша, намусың сатма!

Гавам рәтсезләнсә, ерак кач аннан:
Бәла-фетнәләргә кереп болганма!

Сөйләмә «югары» сүзләр, кузыем,
Гади уңай сүзләр сөйләп йөр үзең.

Һичкемгә яманлык теләмә, кылма,
Игелек кыл, явыз хискә юл куйма!

Чыгарыңны уйла керер алдыннан,
Ир-егет хур була ялгыш адымнан.

Үпкәң кабарса да, тыныч, салкын бул:
Сабырлының шатлык көне алда ул!

Ни ди, ишет, сабыр иткән бер кеше:
«Сабырлан — төзәлер бозылган эшең.

Сабырлар теләгәннәрен табырлар,
Һомай[24] күләгәсе төшә сабырга».

Әгәр сиңа килсә кайгы-сагышлар,
Бераз сабыр итсәң, килер шатлык та.

Әгәр уңышлардан баш әйләнмәсә,
Эшең уңар, артык гамьсезләнмәсәң.

Сабыр бул, чын ирлек билгесе — сабыр,
Сабыр иткән, диләр, күккә юл табыр.

Үлемне онытма — бул сак һәрчагын,
Үзеңне онытма — төбеңә багын[25].

Телеңнән чыгарма яман сүзеңне,
Ялган бик тиз арзан итәр үзеңне.

Якынлык тот кардәш белән үзара,
Олыга-кечегә елмаеп кара.

Ипи-тозны киң тот — ашат кешене,
Кеше гаебен күрсәң дә, тый телеңне!

Гыйбадәттән калма, табынсаң Хакка,
Языктан ерак тор — үзеңне сакла!

---

[21] Нинди төр кешеләр икәнлеге кулъязмада калмаган.
[22] Ошакчы — әләкче (татар сөйләмнәрендә бар).
[23] Юрык-заң — әдәп кагыйдәләрен белү.
[24] Һомай — бәхет кошы: аның күләгәсе кемгә төшсә, шул бәхетле була (оригиналда бүтән мифик кош — Үрәң Кош — исеме әйтелә).
[25] «Үзеңдә булган һәм үзең генә белгән кимчелекләреңне онытма — масайма» мәгънәсендә булса кирәк.

Ирешсәң байлыкка, йөрмә мактанып,
Кешене рәнҗетеп кылма ахмаклык.

Мавыкма дөньяңа — ул бозылучан,
Ышанма байлыкка — байлар бөлүчән.

Инанма гомергә — төш кебек үтәр,
Ышанма котка да — кош кебек очар.

Игелек кылмасаң — гомер заяга,
Һәр үткән көн үтсен мәгънә-файдага.

Буза[26] эчмә, ерак тот фисык[27] юлын,
Зина кылма, фасикъ[28] булма, и углым.

Бу ике языктан изге рух качар,
Алар фәкыйрьчелек юлларын ачар.

Ни ди, ишет күпне кичергән кеше,
Югалтыш-табышны күп күргән кеше:

«Буза эчмә, зина юлын белми тор,
Бу ике фәкыйрьлек тунын кидерер.

Бузадан киләдер азгын батырлык,
Зинадан кот кача, йөзеңә — хурлык».

Сүзен кисте, Айтулды, әйтте: «И угыл,
Онытма, сиңа сүзнең кирәге шул.

Төгәл сөйләдем мин, саф күңелдән, бәс,
Сүземне тыңласаң, бәхтең кимемәс.

Сиңа сөйләгәнем нәсыйхәт дип бел,
Яз аны күңелеңә, онытырга түгел!»

АЙТУЛДЫНЫҢ ИЛБИККӘ НӘСЫЙХӘТ БЕТЕГЕ[29]

Дәвәт[30] белән кәгазь сорап алды да,
«Бисмиллаһи», — диеп куйды алдына.

Илаһ аты белән башлады сүзен:
Тудырган, үстергән бер Тәңре Үзе.

Түрәтте халаек[31] — ун мең төрлесен,
Яшәтә аларны, ач тотмый берсен.

Баш итәр барчасын үз теләгенчә,
Бу дөньяда һәр шәй — Ул кылган нәрсә.

Теләгәнен эшләр һәр кешегә дә
Һәм Ул мохтаҗ түгел ярдәмчеләргә.

Үләргә яралган сансыз җан-мәхлук,
Тереләр үлә. Тик Аңар үлем юк.

Сәламлим сөекле пәйгамбәрне мин,
Сәламемне кимсез җиткер, Тәңрем, дим.

Сәхабәләргә дә сәлам шулай ук,
Сәламемне төгәл әйтсен Ходаем.

Озын-озак яшә, бәхетле илбик,
Сиңа бәйгать итсен[32] күп ил һәм билек.

Исемем Айтулды, холкым да тулы,
Тик бу тулылыкка чик куяр үлем.

Каты тотты инде үлем тоткамны,
Яшәү таты китте, берни коткармый.

Мине хөрмәт иттең, әллә жәлләдең,
Мин исә зур хезмәт күрсәтәлмәдем.

Бөек хәстәреңә җавап бу бетек,
Комарткы булсын ул сиңа, бий егет.

Дөнья эшләрендә катнаштым бергә,
Эшеңне башкардым тугрылык берлә.

Миңа күрсәтелгән дуслык, юмартлык
Өчен сиңа бүләк язма комарткым[33].

[26] Буза — төркиләр ясый торган исерткеч эчемлек, гомумән, исерткеч, аракы һ.б. Чагыштыр: русча бузить — исереп тавышлану.
[27] Фисык — тыйнаксыз рәвештә күңел ачу.
[28] Фасикъ — тыйнаксыз кылanучан кеше.
[29] Бетек — язу, хат һ.б. язылган нәрсә.
[30] Дәвәт — борынгы бөкеле кара савыты.
[31] Халаек — гарәпчә, гомумән, «халыклар» дигән сүз.
[32] Бәйгать итү — тугрылыкка ант итү.
[33] Комарткы — мирас, байлык.

Ни ди бер атаклы миһербан кеше:
«Миһербанлык, баксаң, инсанлык башы».

Рәхимле кешенең сүзен тотар бул,
Идарә эшеңдә ул сүз — төп ысул.

Рәхимле сүз әйтә инсанның чыны,
Ул сүз бөеклеккә күтәрер сине.

Мин дә, Илбик, сиңа булдым миһербан,
Һәм сүземне тыңла, эшеңдә куллан.

Үлемем килгәчтен үкенәмен дә,
Тик бу үкенечтин файда юк бер дә.

Үкенечсез минем бар гыйбадәтем,
Үкенечкә бик күп эшем, гадәтем.

Торып кала җыйган алтын-көмешем;
Җавап та бирәсем бар шулар өчен.

Үкенечләрем бар, юк тик өметем,
Үз-үземнән хәтта инде түңелдем.

Өметсез көенчә барам ирексез,
Уйла, бер көн син дә китәрсең шиксез.

Үлем килеп тотмас борын, и илбик,
Эшеңне эшләп кал изгеләр кебек.

Исән-сау чагыңда яула син яхшы ат,
Мал-туар барында өләш һәм ашат.

Көчләшү урнына яхшыча кылан,
Халыкны сөендер тел һәм кул белән.

Ни дигән, ишет, бер туры сүзле ир,
Кечедән уянган җете күзле ир:

«Әҗәл килмәстән үк, үлемне белеп
Яшә, тере чакта гыйбадәт кылып.

Үлем килеп тоткач, үкен-үкенмә —
Гомер калган кара җирнең өстендә.

И Илбик, катгый бул, мин үлгәч, эштә
Көннәреңне зая уздырма һич тә.

Өермәсен сине дөнья, җил булып,
Һәр эшеңдә маяк булсын тугрылык.

Гадел һәм халыкчан булса хөкемең,
Тыныч һәм болытсыз булыр һәр көнең.

Үзеңне утка атма дөнья өчен,
Бастыр ялган хисне, җан һәм тән үчен.

Бу дөнья — синең кол, колга кол булма,
Сине куймый икән, аны баш кылма.

Көязләнмә, артык күтәрмә күңел,
Ышанырлык түгел — дөньядан түңел.

Якын тот үзеңә изге затларны,
Үзеңнән ерак тот ярамасларны.

Ышанычсыз сукбай килсә, эш бирмә,
Вафасыз кешегә ашың җийдермә.

Гөнаһлардан саклан, бул гыйбадәттә,
Шулардан тыш өмет юк кыяматтә.

Үлемтек әзерлә — постырмасында[34]
Үлем сине күптән сагалап тора.

Үлем килеп тотар ничек качсаң да,
Барыбер бер йотар, ниләр кылсаң да.

Гафил булып йөрмә — үлем киләчәк,
Ничек яшәсәң дә, җир — соңгы түшәк.

Кайда кем котылды үлемнән качып?
Кайда кем яшәде гомердән артык?

Бер илбик бу хакта шәп әйтеп биргән,
Ай, көн һәм гомерне китереп бергә:

«Ибне-Адәм, баксаң, дөя кәрваны —
Килә, китә, һич юк озак калганы.

Ата орлыгыннан яралгач бала,
Ана карыны — мәнзил[35], бераз торала.

Анасыннан туып, исем кушуга,
Заман тулпарында чыга ул юлга.

[34] Постырма — засада.
[35] Мәнзил — тукталыш урыны.

Көнгелек ашың һәм төнгелек ашың —
Һәркайсы үлемгә таба бер адым.

Бу дөнья — бер арбат, күр шуны, төшен,
Шуңа килеп китү — шул көнкүрешең.

Арбаттан кузгалгач, ике юл очрар;
Карарсың: кайсына язмышың дучар.

Әгәр уңга китсәң, эшең уң була,
Әгәр сулга китсәң, баш и дә ела».

Бу дөнья бер басу, и илбик дустым,
Син аңа ни чәчсәң, шуны урырсың.

Ни чәчсәң, шул үсәр, шуны табарсың,
Табигать ни бирсә, шуны аласың.

Үлгәч, еларсың бу ике языктан:
Кешенекен алма, юкка түкмә кан.

Бер төш кенә булып үтәр бу гомер,
Кирәк бий, кирәк кол — барсына да бер.

Кайда төш шикелле үткән һәр көнең!
Алардан еш кала бара үкенеч.

Ни ди, ишет, берәү — уянмыш кеше —
Уяну соңында уйланмыш кеше.

Ул кеше, күрәсең, шагыйрь булганга,
Шигырь илә әйткән, мәгънәсен аңла:

«Аягүрә йоклап үтте гомерең,
Ни файда? Булдымы якты бер көнең?

Теләкләр артыннан кудың туктаусыз,
Табышың санаулы. Үкенеч сансыз».

Юанма тормышка. Кылма артыгын.
Яшәүдән үлемгә ара бик якын.

Саран булма, илбик, күрсәт юмартлык,
Калыр, мәңге үлмәс, «юмарт ир» атың.

Сүвгә[36] — гаскәргә һәм байлыкка һич тә
Ышанма, фәтва юк алтын-көмештә.

Үзгә өчен итмә үзеңне корбан,
Үзеңне көчләмә, үзеңне кызган.

Синнән элек килгән атаклы бийләр
Дөнья куйды, китте, шуны хәтерлә.

Әҗәлең сагалап тора күптәннән,
Кадер, игътибар бир һәр килгән көнгә».

Ни ди, ишет, дөнья гаебен белгән
Һәм акыллы сүзләр әйтүчән белкә:

«Ачы су кебектер бу дөнья малы —
Никадәр эчсәң дә, сусавың калыр».

И батыр, күләгә кебектер дөньяң:
Кусаң, кача, качсаң, куа артыңнан.

Сагым ул, карасаң, бу дөнья эше,
Тотыйм дип кул сонсаң, югалыр үзе.

И илбик, катгыйлан, үзең изге бул:
Бийе изге булса, иле изге ул.

Сәрайга җыелган төрле ач бүре,
И илбик, капкаңны күзәтеп йөре.

Халык ул — куй сыман, бийе — куйчысы.
Куена миһербан кылсын көтүче.

Кылтайма юкка, юл бирмә үпкәгә,
Килешми кылтаю бер илбиккә дә.

Эре сөйләшмә син кешегә телдән,
Эре сүз ялкындай көйдерә кинәт.

Саллы, ипле, төпле, рәхимле булып,
Һәрбер игелеккә катнашсын кулың.

Алдыңда катлаулы озын юл тора,
Юньчел кеше юлга азык булдыра.

---

[36] Сүв —борынгы төрки телдә «гаскәр».

Төзеп торма, илбик, сәрай һәм кирмән[37],
Сәраең — каты җир, кабергә кергәч.

Нигә кирәк җыйган алтын-көмешең?
Ике оч бәз бары соңгы өлешең.

Бу хакта бер шагыйрь әйткән ди болай
(Аның сүзен нигез итеп ал, уйла):

«Гафил бәндә бик күп җыя әйберләр,
Нигә икәнлеген уйламый бер дә.

Тәмам баеп беткәч, теләге төгәл,
Төгәтә яшәвен җаналгыч әҗәл».

Рәхәткә бирелмә, горурланма бий,
Сөенеч-куаныч сүнәр шәм кеби.

Гомерне дөнья дип үткәрмә зая,
Мәшәкатьләнмә бик, үзеңне ая!

Ефәкләргә күпме генә төренмә,
Ятарсың, акыллым, балчык гүреңдә.

Сөйгән ярлар белән күпме йөрсәң дә,
Ялгызың каласың, гүргә кергәндә.

Матур атлар белән әвәрә булдың —
Иярсез агач ат менәрсең соңын[38].

Әзерлән, шуларны уйлап, үлемгә:
Кара җир астына кергәч, үкенмә.

Ходайдан тәүфыйгың телә һәрдаим:
Ходай шиксез бирер сиңа ярдәмен.

Башыңа ни төшсә дә, каһәрләнмә:
Казага түз, авыр сүзгә гарьләнмә.

Үзең кирәк — бөтен җирне яулап ал,
Түбәндәге бу биш эшкә ягылма:

Хәрәмгә катылма һәм дә көчләшмә,
Кеше канын түкмә һәм дә үчләшмә.

Хәмер эчмә — ерак тор азгынлыктан,
Шундый шәйләр чын бий булуга дошман.

Үзең мәңге бийлек телисең икән —
Халыкка гадел бул, золымны китәр.

Халыкның башы син, и илбик, бүген
Уяу бул, уйлан һәм сакла ил-көнен.

Олы йөк йөкләдең муеныңа, илбик,
Гафил булма, саклан, и холкы иплем.

Җан вә тән еш төшә нәфескә полын[39],
Полын булма, булсаң, үзеңчә йолын.

Кичермеш гомереӊ үтте җил кебек,
Зая булмыш еллар намусыңа йөк.

Зая кылма инде калган гомерне,
Моның өчен төп юл — оныт үзеңне.

Вафалы булгыдай түгел бу дөнья.
Гыйбрәт ал хәлемнән, кара да миңа.

Ни ди, ишет, әнә, фикерле кеше
(Фикерлеләр була кешеләр башы):

«Бу дөнья — арбат ул, гомерең — аргыш[40],
Ничә аргыш, сана, арбатта кунмыш.

Сәрай, бел, дөньяны, байлык җыярга[41],
Ни җыйсаң да, озат теге дөньяга».

Үзең күчкәнче, бик, күчеңне[42] озат.
Кирәкне калдырма, кирәксезне сат.

Менә мин китәмен, хәзерлән син дә,
Тырыш — изге атың калсын бер җирдә.

---

[37] Бу киңәш кайчакта бик начар нәтиҗәләргә китергән, мәсәлән, Алтын Урда ханнары үз кальгаларын җимергәннәр.
[38] Ягъни колашага — мәет носилкасына менәрсең.
[39] Полын — плен.
[40] Аргыш — кәрван, олау.
[41] Мәгънәви байлык турында сүз бара.
[42] Күч — күченеп баручылар төркеме.

Мәңге калсын дисәң, исемең, илбик,
Кайбер эшләреңне эшлә бик белеп.

Гадел бул катгыйча, тик кулланма көч,
Гыйбадәт кыл — тәңре капкаларын коч.

Икенчедән, гафил булма, уяу бул,
Үзеңә тимәсен явыз, усал кул.

Бер эшеңне бүлмә ике вакытка.
Сабыр бул, гарьләнмә, йөзеңне чытма.

Түбәндәгеләрне белеп эш күндер —
Ил тынар һәм билек сиңа кул бирер.

Юаш изгене дә хөрмәтлә, күтәр,
Явызны илеңдә тотма, ку, китәр.

Низамлы заң[43] тотып, гаделлек сакла,
Көнең-бәхтең кәмәр баглар[44] шул чакта.

Ни ди, ишет, әнә, атаклы белкә
(Бер сүзне кагыйдә дип белсәң икән):

«Туры акыллы бул, илбашы батыр,
Җигәлмәссең юкса идарә атын.

Кем дә кем төз, дөрес идарә кора —
Шул исемен тарихка язып калдыра».

Чамаңны бел, борын чөймә, и батыр,
Үзеңә: «Сак бул!» — дип әйтеп кенә тор.

Исәрләнмә һич тә, и көчле кулым,
Яман кылык — ике дөнья хурлыгы.

Гомер уза — инде бетте, дип уйла,
Үлем якын, инде җитте, дип уйла.

Мине күр дә, миннән гыйбрәт ала күр,
Үкенеч булмасын — алдан чара күр.

Кеше үлсә, аннан кала тәүсыя[45],
Үгет-нәсыйхәтем — комарткы сиңа.

Яраттым мин сине, батыр илбигем.
Сүзем сиңа файда китерер, димен.

Иң әйбәт комарткы — акыллы сүз ул:
Акыллы сүзләрнең файдасы йөз ул.

Менә, белгәнемне яздым, чын-чынны,
Онытма сүземне, онытма мине.

Яшәп ни күрсәң дә гомер юлыңда,
Үлем килә юлның азак-соңында.

Үлем мыштым гына килеп чыга да
Яшәп торган җанны тәннән чыгара.

Дәшүче килүгә әзер тор икән,
Озын юл йөрергә хәстәр күр икән.

Үлемнән юк качып котылыр җиреӊ,
Әзерлән дә инде шул юлга җыен.

Ишет, җир астында ятмыш күп ирләр
(Үлемнәрен әйтмеш алар) ни диләр:

«Үлем шобагасы килә чираттан,
Ышанмыйча торма — килә чынлап та.

Алтын кәмәр баглап, мин, мин, дигәннәр,
Үлем тоткач, кинәт өзелә кәмәр.

Сиңа бурычымны, илбик, үтәдем.
Үземнән канәгать булып китәмен.

Игелегең өчен тәүфыйгың артсын,
Яшәү әхвәлеңне тәңре котайтсын.

Исәнлек-саулыкта мең еллар яшә,
Кинәнеч-шатлыкта уз илләр аша.

Миһербанлык белән әйтелә сүзем,
Сәламәт кал инде, күрекле йөзем.

Менә мин үләмен, и илбик, котлым,
Торып кала углым, бәгырем уты.

Ходайга тапшырдым — Аңа ялварам.
Ул аны утта да саклап калала.

Хаҗәтем шул минем: аны күзәт син,
Юньсезгә юлыгып, азып китмәсен.

[43] Заң — закон (оригиналда юк, «заң» сүзе Алтын Урда монгол теленнән килә).
[44] Кәмәр — кыйммәтле билбау: баглау — буып бәйләү.
[45] Тәүсыя — «завещание»: соңгы киңәш, күрсәтмә.

Ходай һәрнәрсәгә сәбәпче куйган,
Сәбәбеннән килә яхшы һәм яман.

Балага сәбәпче ана һәм ата,
Яхшы булса да ул, яман булса да.

Бүген шундый хәлем: мин үлгәнгә тиң,
Кечек калды улым, бер үксез ятим.

Хезмәтемнең хакы бераз бар булса,
Син сәбәпче бул һәм керт изге юлга.

Тик йөрмәсен, булсын гыйлем-һөнәрле,
Кирәксә ил-көнгә башчы итәрлек.

Тәрбиясе җитсен, әдәбе-холкы,
Хезмәткә ярасын, мөстәкыйль булсын.

Бик иркенгә куйма, кыс һәм каты тот,
Тиргәлгәнгә куна, диләр, бәхет-кот.

Угыл-кыз кечедән белгән нәрсәне
Картаеп үлгәнче онытмас аны.

Ни ди, ишет, бер карт, чәче ак кылган[46]
(Сынаган, күп күргән һәм күп укыган):

«Угылны гыйлемгә яшь чактан өйрәт,
Яшьли очкан лачын оча биегрәк.

Аяп торма, кыйна, талчыбык җийдер,
Угыл-кызга таяк күп гыйлем бирер».

Язып моны, салды томарга[47] төреп
Һәм әйтте, углының кулына биреп:

«Бу язуны, углым, кадерсезләмә,
Илбиккә тапшыр, бу — тәүсыянамә[48]».

Янә углын кочты, куенга кысты,
Үбеп елады, күп яшен агызды.

«И углым, — диде, — күрәсең хәлне,
Гомердә онытма мин үлгән мәлне.

Бу хәл, шиксез, беркөн киләчәк сиңа,
Гафил булма, яшәп, әзер тор шуңа.

Кирәкле сүземне язып җиткердем,
Син дә, укып, үзең дога кыл инде.

Сиңа эш тапшырса илбик, ышанып,
Ышанычын акла төгәл һәм анык.

Вакытың уздырып йөгермә бушка,
Күндәм һәм иплe бул, холыксыз булма.

Ятакка соңрак ят һәм иртәрәк тор:
Иртә торган, диләр, бәхетле булыр.

Онытма, онытма Тәңре бойрыгын:
Илбиккә чын күңел илә тугры бул!

Яманга юлама, ерак тор, ерак.
Гадәт-холкың булсын һаман яхшырак.

Сүзеңдә сак булсаң, исән булырсың,
Үз-үзеңне хөрмәт иткән булырсың».

Сүзен кисте, углын кочып елады,
Тагын тәшвишләнде, тыныч булмады.

«Инанычсыз дөнья, — диде, — вафасыз,
Үлгәндә дә куймыйсың ич җәфасыз.

Нигъмәтләр ал иткән йөзләрем сулып,
Камыш буем җиргә төшә ич сынып.

Анадан ни хәлдә туган икәнмен,
Шул хәлдә елап яткан ир ни ди:

Карыннан чыккан зат — җир карынына,
Шикәр ашаган зат — елан авызына.

Газиз тереклегем, газиз гомерем!
Үкенечтә сыктап гүргә керермен…»

Барча кардәшләрдән гафу сорады.
Җаны зәңгәр күккә тәмам юлланды.

[46] Ягъни корыган кылган (үсемлек) кебек.
[47] Томар — эченә документлар салына торган торба, күн янчык, аны башлыклар үзләре белән шнурга тагып йөрткәннәр.
[48] Тәүсыя — ирекле васыять, абруйлы киңәш, үтенеч.

Шуннан ушын җыйды, сыктавын куйды,
Мөлкәтен өләшеп, васыять кылды.

Күзен күккә текте, әйтте: «Илбигем!»
Шунда әҗәл кисте, сулышын, телен.

Җан нуры өзелде, көне төн булды,
Илаһ аты илә киселде тыны.

Идезлекле[51], гали максатлы җаны
Югарыга очты, калды бәдәне.

Бу дөньяда, гүя, юк иде бу җан.
Тик исеме калды, бер билге — нишан.

Ни дип әйткән, әнә, күңеле төз кеше
(Рухын гафиллектән ерак йөртүче):

«Мәетләр керәсе — уртак зур ишек,
Сөзек җаннар өе — җәннәт, идезлек».

Җәсәде буш калды — очып китте җан,
Кая куелыр ул — анысы Аллаһтан.

Урыны идез булса, нинди бәхет-кот!
Түбән түнсә әгәр, бәхетсезлек, йот.

Шул икенең инде берсе булачак,
Һәрхәлдә җан анда мәңге калачак.

Бер уйласаң, бәндә бик кызык инде:
Шаулый, дан казана, кинәт — юк инде…

Каян килгән, килә һәм кая бара,
Ни өчен ни кыла ул гомер ара?

Белкәләр беләме? Һәм ни ди алар?
Укыганнар ничек аңлата ала?

Бу шәйләрне белгән белкә кеше юк,
Һәм аңлатып биргән укымышлы юк.

Кеше ашый, эчә, йөри тирәдә,
Бер бар, бер юк кебек, гүя күләгә.

Ни кыска гомерле бу бәндә үзе,
Тик уе югары һәм теле озын.

Карасаң, бәндәнең ирке юк бер дә,
Ләкин ник ул шулай күкрәк киерә?

Дөньяны яулагач, арта тик хәстәр.
Һаман ул кыядай кукрая, хәтәр!

Ни ди, әнә, рухы уянган кеше,
Һәм үлем турында уйланган кеше:

«Ни юньсез үлем син, чыгымчы үлем!
Тынмыйсың, йөкләсәң дә мең-мең тулым»[52].

Һәркемгә тиясең — котылмас бере,
Яхшыга-яманга син бердәй бүре.

Яшәсәче галим озак бәхеттә,
Надан утын тизрәк үлсә һәм бетсә.

Ләкин яхшы-яман барсы да үлгән,
Олы-кече белән кара җир тулган.

Үлемнән качу юк, и җан иясе!
Ничек яшәсәң дә, үлем киләсе.

Иллә, ни шәп әйткән баш булган кеше,
(Мәгариф эшләрен башкарган кеше):

«Изге эш тә булмас, үлем булмаса.
Тик шәп булыр иде кеше үлмәсә».

Мәңге тынычлыкка илтә үлемем,
Тик төптән-тамырдан куптара мине.

Кеше яман түгел, кешелек яман.
Һичкем яман түгел, һәр халык яман.

Үлем гаҗәп түгел, һәркем дә үлә.
Җир асты туп-тулы үлгәннәр илә.

Үлем — кортка эше, янау һәркемгә,
Кирәк уңга юл тот һәм кирәк түңгә.

Дәвамы алдагы саннарда

Филология фәннәре докторы, профессор
Рифкать Әхмәтҗановның
шигъри тәрҗемәсе

[49] Идезлекле — рухи югарылык, татар телендә актив кулланылган сүз.
[50] Тулым – кәрвандагы терлеккә (дөягә, атка, ишәккә) төяләә торган күн капчык; шулай итеп, монда үлем йөк күтәреп баручы хайванга охшатыла.

ТАТАРСТАННЫҢ ХАЛЫК ЯЗУЧЫСЫ,
ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЫ

МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ

ТАБАРЛАР БЕЗНЕҢ ЭЗЛӘРНЕ

Еланнан елау көтмә син,
Еланнан елау көтмә;
Елатыр елларны йолып,
Дөнья тетмәсен тетмә!

Уйлар уйла бер утырып
Елантау итәгенә.
Халкыңның гомер агачы
Күрмәде ниләр генә.

Текә язмыш маңгаена
Күпме әр, күпме яра?!
Янә яшәреп, еланнар
Иске кабыгын сала.

Иске кабыгын сала да
Ысылдап урап ала.
Эчкә елан йотканнарның
Җан күзе салкыная.

Атилла оныкларының
Учагы сүнеп бара.
Үрчи мөгезле еланнар,
Кыйтгалар ятка кала.

Еланнан елау көтмә син,
Еланнан елау көтмә;
Бүген җуйган зурлыгыңны
Үткәннән өмет итмә!

Табарлар безнең эзләрне,
Әйтерләр хәйран калып:
— Үзе үстергән еланнан
Чагылып үлгән халык...

2005

* Шагыйрь Марсель Галиевнең кайбер сүз энҗеләре белән журналның башка битләрендә дә таныша аласыз.

Р.ФӘХРЕДДИН: «МИЛЛӘТ АНАЛАРЫ ЙИТЕШДЕРЕГЕЗ!»

АЛЬТА МӘХМҮТОВА,
тарих фәннәре кандидаты,
Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Ш.Мәрҗани исемендәге премиясе лауреаты

ХIХ ГАСЫР АЗАГЫ – ХХ ГАСЫР БАШЫ – ТАТАР ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫНДА ХАЛЫКНЫҢ ТАРИХИ ЮЛЫНА ЯҢАЧА КАРАУ, КҮП КЕНӘ ГАДӘТ-КАРАШЛАРГА ЯҢА БӘЯ БИРҮ ОМТЫЛЫШЫ ҮСКӘН, «ЯҢА КЕШЕ» ТӘРБИЯЛӘҮГӘ ЗУР ИГЪТИБАР БИРӘ БАШЛАГАН ЧОР. БУ ЧОРДА ТАТАР ҖӘМГЫЯТЕНДӘ БАРГАН ИНКЫЙЛАБЫЙ ХАРАКТЕРДАГЫ ИСКЕЛЕК ҺӘМ ЯҢАЛЫК КӨРӘШЕН, АСЫЛДА, ИСЛАМ ДИНЕ ПРИНЦИПЛАРЫНА ТАЯНГАН ТРАДИЦИОН КАРАШЛАР, ӘХЛАКЫЙ НИГЕЗЛӘР ӨЛКӘСЕНӘ ДАИМИ БӘРЕП КЕРҮ ДИП АТАРГА БУЛА.

Әлеге процессның бер тармагы булып татар җәмгыятендә хатын-кызлар хәленә карата яңа караш барлыкка килү дә торган. Яңарыш хәрәкәте тернәкләнгән чорда ислам дөньясында хатын-кызларга бәйле күп кенә мәсьәләләр алгы планга чыккан. XIX гасырның азагында әдәбиятка килгән язучылар юнәлештәге әсәрләрендә татар хатын-кызларының гаиләдә һәм җәмгыятьтәге хәлен кискен тәнкыйтьләгән, мәгърифәтчелек идеалларын гәүдәләндергән хатын-кыз образларын иҗат иткән. Ике гасыр кисешендә туып килгән җәдидчелек публицистикасында да хатын-кыз мәсьәләсе үз урынын бик тиз тапкан, татар иҗтимагый тормышындагы чишелергә тиешле мөһим проблемаларның берсенә әйләнгән.

Хатын-кыз тәрбиясе, аңа белем бирү, гаиләдәге һәм җәмгыятьтәге хәле, хатын-кыз хезмәте, шәхси иреге, мөстәкыйльлек чикләре ... һ.б., һ.б. Бу мәсьәләләр хакында язганнар, бәхәсләшкәннәр; аларны чишү юлларын язучылар, руханилар, мөгаллимнәр, ирләр, хатын-кызлар – һәркем эзләгән. Татар җәмгыятендә башланган буржуаз үзгәрешләрнең үзәгендә булган хатын-кыз мәсьәләсенең чишелеше төрле катламнарны кызыксындырган. Хатын-кыз иреге һәм тигез хокук проблемаларын кичектергесез чишелергә тиеш җәмгыяви проблемалар арасына кертү татар мәгърифәтчелеге үзенчәлекләренең берсе булган.

А.И.Герцен сүзләре белән әйтсәк, «иҗтимагый иректән мәхрүм ителгән халыкта, үз ачуын һәм вөҗдан авазын башкаларга җиткерү өчен, бердәнбер трибуна булып әдәбият тора». Мәгърифәтчеләр белән халык арасында күпер ролен

үтәп, бу чорда яңарыш идеяләрен халыкка җиткерү вазифасын үз өсләренә язучылар алган. Ике гасыр кисешендә әдәбиятка ыргылып килеп кергән яңа буын, чорның социаль заказын үтәп, эчтәлеге дини-әхлакый, мәгърифәтчел характерда булган, белемгә, яктылыкка чакырган китапчыклар — популяр брошюралар серияләрен бастыруга керешкән.

Ризаэддин Фәхреддин әсәрләренә игътибар итик. Чөнки киң эрудицияле, энциклопедик белем иясе булган галим — мәгърифәтчел позицияләрдә торып, яңарыш тарафдарлары арасында хатын-кыз хокукларын беренчеләрдән булып яклап чыккан шәхес. XIX гасыр ахырында Р.Фәхреддин мөселман (татар) җәмгыятендәге тәрбия-әхлак мәсьәләләренә багышланган зур күләмле «Гыйльме әхлак» исемле хезмәтенең аерым кисәкләрен бастыра башлаган. Аларның басылу вакытына игътибар итик: «Китабел-игътибар» (1888), «Тәрбияле бала» (1889), «Тәрбияле ана» (1898), «Тәрбияле ата» (1898), «Тәрбияле хатын» (1899), «Шәкертлек адабе (Шәкертлек кагыйдәләре)» (1899), «Адабе тәгълим (Укыту кагыйдәләре)» (1902), «Гаилә» (1902), «Нәсыйхәт», 1-3 кисәкләр (1903) һ.б. Бу китапчыкларның һәрберсендә әхлакый-тәрбияви проблемалар куелуы исемнәреннән үк күренә. Аларның хатын-кыз мәсьәләсе белән тыгыз бәйләнештә булуы да көн кебек ачык.

Исламның төп чыганаклары булган Коръән һәм хәдисләргә мөрәҗәгать итеп, Р.Фәхреддин «хатын-кызлар ирләр кебек үк кеше хокукларына ия», дигән тезисны заманы өчен бик кыю рәвештә нигезләргә алынган. Тәрбия-әхлак мәсьәләләрен һәм, аларга бәйле рәвештә, хатын-кыз мәсьәләсен чишү юлларын эзләгәндә, галим кешеләргә Аллаһ биргән табигый хокукларга таянып эш итәргә кирәк дигән фикердә торган. Хатын-кызның «чәче озын, акылы кыска» кебек гыйбарәләрне кулланып яшәгән җәмгыятьтә хатын-кыз мәсьәләсен кую үзе үк бик тәвәккәл адым дип кабул ителергә тиештер.

Җәдидчелек идеологиясе формалашкан чорда тәрбия мәсьәләләре алгы планга чыккан. Камил шәхес тәрбияләү татар җәмгыятендә дөньяга яңа карашлар булдыру өчен җаны-тәне белән тырышучы галим тарафыннан төп максат буларак кабул ителгән. «Өммәтләрне (халыкларны) дә, фәрдләрне (аерым затларны) дә бәхет мәйданына алып бара торган юлларның иң тугрысы — гүзәл холык вә яхшы тәрбиядер. Гүзәл тәрбия хасил кылыр өчен, мәктәпләр, гаиләләр, җәмгыятьләр исемендә өч төрле дәресханәләр үтәргә мәҗбүрләр. Әгәр дә шушы дәресханәләрдән яхшыларын сайлый алсалар, шул нисбәттә тәрбияләре яхшы, әгәр дә бәгъзе берләре яки бөтенләй бозык булса, шул нисбәттә тәрбияләре дә бозык булыр. Тәрбиясе бозык кеше, табигый, бәхет вә сәгадәткә ирешә алмас», — дип күрсәткән ул.

Тәрбия эшенең никадәр авыр, катлаулы һәм дәвамлы икәнен галим «Адабе тәгълим» әсәрендә түбәндәгечә тасвирлаган: «Тәрбия акрынлык вә тәртип белән камиллек булдыру димәктер... Сабанчы вә бакчачылар, орлык чәчмәстән вә җимеш икмәстән элек, җирләрен никадәр игътибар белән йомшартулары, чүп вә бозык үләннәрнең хәтта тамырларына кадәр чыгарып ташлаулары мәгълүмдер. Бу исә җир тәрбиясе булып, җир эшкәртү ысулынча мөһим бер шарттыр. Бу төркемнән бөек вә гүзәл кеше итәчәк кемсәләрне сабый вакытларында ук тәрбия итү тиештер. Тәрбиясе булмаган җирдә гүзәл ашлык җитешмәгән кебек, тиешле тәрбия бирелмәгәндә, гүзәл кеше дә җитешмәс. Шулай икән, тәрбия иң кирәкле бер эш булачактыр».

Тәрбия, беренче чиратта, гаиләдә бирелә. «Гаилә — кечкенә бер дәүләт кебидер», — дип билгеләгән Р.Фәхреддин. Гаиләдәге тәртип һәм тәрбия — «җөмләсе гаилә башлыгы улган хатын вазифасыдыр», — дип тә ассызыклаган. Баланы сабый вакытында тәрбияләү тулысынча хатын-кыз кулында булуын да күрсәткән. «Баланың иң кечкенә вакытында имезү, ашату, йоклату, киендерү, юындыру — кыскасы, ана вә яки ана

хезмәтендәге кеше кочагында булган тәрбиясе тәрбия галимнәре каршында «беренче тәрбия» вә мәктәптә булган тәрбия «икенче тәрбия» вә аннан соң булган тәрбия «өченче тәрбия» исеме белән билгеледер», — дип язган галим һәм беренчел тәрбиянең мөһимлегенә тукталган: «Бала тәрбияләү — ананың гаиләдәге генә түгел, ә бөтен җәмгыять алдындагы изге һәм җаваплы бурычы».

Аналарның җәмгыять алдында гаять дәрәҗәдә җаваплы булуларына да тукталган Риза казый. «Халыкның яхшы вә усал улмакларында күп вакытта аналарның һәм катышы уладыр... Тәрбияле аналар үз балаларына гына улмай, бәлки мөселманнарның барчасына хөрмәтле ана улмаклардыр, — дип ассызыклаган ул «Тәрбияле ана» әсәрендә. — Аналарның хезмәтләре иң авыр вә иң мәшәкатьле хезмәттер, аны язып бетерерлек, тел илә сөйләп бәян кыйлырлык түгелдер». Шулай булгач, ана булачак кызларның үзләрен тәрбияләү мәсьәләләренә дә зур игътибар кирәк, дигән фикердә торган галим.

1899 елда Р.Фәхреддин үзенең беренче «хикаят»ен — «Сәлимә, яки гыйффәт» исемле әсәрен дә бастырып чыгарган. Автор үзе традицион рәвештә «хикаять» дип атаган бу әсәрне әдәбият белгечләре повесть дип тә, роман дип тә билгелиләр. Исеменнән үк күренгәнчә, аның төп каһарманы — хатын-кыз. Иранлы сәүдәгәр кызы Сәлимә — чибәр, акыллы, белемле туташ, туган теле булган фарсыны гына түгел, гарәб, француз, инглиз телләрен дә камил үзләштергән, дөнья тарихы һәм мәдәниятеннән дә яхшы хәбәрдар, икътисад һәм сәүдә эшләре белән дә тирәнтен таныш. Ул әтисе вафатыннан соң калган бай малмирас белән дә уңышлы идарә итә.

Әсәрнең бөтен эчтәлеге хатын-кызлар да ирләрдән ким түгел, аларга бары тиешле тәрбия һәм яхшы белем генә җитми дигән фикергә нигезләнгән. «Сәлимә туташ гади кызлардан дәгел иде. Бәлки «яшь гомердә тырышканнар картлыкта рәхәт күрерләр», диелгән сүзгә муафыйк лязим тәхсилне (тиешле белемне) вә хаҗәте (кирәкле) тәрбияне алмыш иде, — дип тасвирлаган аны Р.Фәхреддин. — Ана диле улган фарсычаны Тәһранда укып, соңра Мисрел-Каһирәгә вармыш, анда исә кызлар дарелфөнүнендә (университетында) биш ел укымыш, гарәб, француз, инглиз дилләрене мөкәммәл сурәттә белмеш, кул һөнәрләрене, йорт итмәк вә мәгыйшәт кылмак гыйлемнәрене гүзәл үгрәнмеш...»

Сәлимә — акыллы һәм укымышлы булу белән бергә күркәм холыклы, итагатьле, гадел һәм гыйффәтле, кечкенәдән яхшы тәрбия алган шәхес. Бу гүзәл зат тирә-юньгә нур, игелек, чисталык-сафлык тарата кебек. Чорының тормышны яңарта алырлык актив мәгърифәт идеалын гәүдәләндергән Сәлимә туташның киләчәктә абруйлы милләт анасы булачагында һич тә шик юк. Сәлимәне шулай идеальләштереп, Р.Фәхреддин кызларга үрнәк күрсәткән, укучыларының (бигрәк тә, хатын-кызларның) игътибарын белем алу, мәгърифәтнең заруриылыгына юнәлтергә тырышкан.

Яшьләр Сәлимә дәрәҗәсендә белемле булсын өчен, татарларда борынгыдан яшәп килгән укыту-тәрбия системасын тамырдан үзгәртергә кирәк дип санаган Р.Фәхреддин. «Дөнья тормышы өчен дин илә дөнья гыйлемене һәм белмәк лязимдер... Инсан улмак өчен, гыйлем илә күркәм холык кирәктер. Һәм дә бонларны бер-берләреннән аермак дөрест улмаз», — дип күрсәткән ул. Милләт алга китсен өчен, аның якты киләчәге өчен, беренче чиратта, яшь буынга нигезле белем һәм яхшы һөнәрләр бирергә кирәк, дигән фикерне куәтләгән автор. «Русча яхшы белмәгәндә, бунларны мәйданга куймак мөмкин дәгел идеке шөбһәсез», — дип тә ассызыклаган. Шулай күләме ягыннан бик зур булмаган әсәрдә ул чорының иң мөһим мәсьәләләрен куя алган: укыту-тәрбия системасын яңа калыпларга салу дисеңме, хатын-кызга мөнәсәбәтне үзгәртү дисеңме — бу үзгәрешләр барысы да халыкка хезмәт итүне күздә тотып эшләнергә тиеш булган.

1903 елда Оренбургта басылып чык-

кан «Әсма яки гамәл вә җәза» исемле икенче әдәби әсәренең үзәгенә дә Р.Фәхреддин тәрбия һәм әхлак проблемаларын куйган. Гаиләне кечкенә бер дәүләт белән чагыштырып, язучы бөтен әсәр дәвамында «инсанның яшьлегендә алмыш тәрбиясе та каберенә кадәр берлектә улыр, аерылмас», дигән фикерне раслаган. Бу әсәрендә автор, Әсманы төрле ситуацияләргә куеп, аның тормышы үрнәгендә тәрбиянең төрле булуына укучының игътибарын юнәлткән, аларны кеше йөрәгенә барып җитәрлек итеп тасвирлаган.

Менә Әсманың балачагы узган бәхетле гаилә мохите. Менә афәтле язмышка дучар булган ятимә кыз туганы тиешле Йосыф бабай карамагында. Монда да кызны кыерсытмыйлар. Шулай да «тәрбия», дидек. Ләкин Йосыф бабай тәрбиясе ялгыз ашатыпэчертеп, хаҗәт киемнәрне бирмәктән гыйбарәттер. Әмма Габбас мелла тәрбиясе җан вә күңелне нурландырмак вә, зиһенне киңәйтеп, тәхсиле кәмаләт (камил гыйлем алу) юлыны ачмак вә рәгъбәтләндермәктән (үрнәк бирүдән, кызыктырудан) гыйбарәт иде. Ике төрле тәрбиянең арасында улан аерма бик бөектер», — дип ассызыклаган галим. Менә тәрбиянең тагын бер төре — җәмгыяви тәрбия. Җәдидчелекнең асылын тәшкил иткән яңа кеше тәрбияләү проблемасын Р.Фәхреддин хыялында туган, мөселман ятим балалары өчен махсус салдырылган ятимханә аша тасвирлаган. Ир һәм кыз балалар өчен аерым бүлекләрдән торган бу ятимханә камил белем, күркәм әхлакый тәрбия белән бергә гамәли һөнәр дә бирә икән. Мондый мохиттә тәрбияләнгән яшь буын киләчәктә милләтнең асыл ул-кызлары булып җитешәчәгендә һичбер шиккә дә урын калдырмаган мәгърифәтче.

«Бу талибәләр, бу мөтәгаллимәләр (укучы кызлар) атласларга гаркъ улынмыш (төренгән) кием калыплары улмай, бәлки гадәти киндергә вә тәкәллефсез (ясалмалыксыз) пәрдәләргә борынмыш энҗе вә алмазлардыр. Бонлар ислам милләтеннән ничә гасырлардан бирле зайг улып (юкка чыгып) килмәктә улан «милләт аналары»дыр», — дип күрсәткән ул. Бу рәвештә караганда, милләтне яңа дәвергә алып керәчәк буыннарны тәрбияләү аерым шәхесне укытудан күпкә өстен булып чыга. Мәктәп тәрбиясен, яшьләргә төпле һәм нәтиҗәле белем бирүне Р.Фәхреддин хәлиткеч көч итеп сурәтләгән, аны җәмгыять алдында торган иҗтимагый бурыч буларак кабул итәргә өндәгән.

Боларга авааздаш фикерләрне мәгърифәтче шул ук 1903 елда дөнья күргән «Нәсыйхәт» исемле хезмәтендә дә куәтләгән. Үрнәк өчен аның түбәндәге фикерләрен китерү дә җитәр. «Гыйлем күңел күзен ачар, наданлык караңгылыгын бетерер, дошманнарга каршы корал булыр, тереклекне саклар, дөнья көтү юлларын белдерер, йорт эчендәге кешеләр белән ни рәвештә булырга кирәк икәнен өйрәтер. Гыйлем галимнәрнең зиннәте вә кешеләрнең хөрмәте булып, угрылардан курыкмый торган байлык вә һич бетми торган байлыктыр», — дип гыйлемгә мәдхия җырлаган галим. Һәм шул ук вакытта укучыларын кисәтеп тә куйган: «Гыйлеме күп булган кешеләргә карап, аз гыйлемле булудан оялмагыз, бәлки белергә кулыгыздан килерлек нәрсәләрне белми калудан оялыгыз. Чөнки гаептер...»

Р.Фәхреддиннең шул ук 1903 елда басылып чыккан тагын бер хезмәте — «Мәшһүр хатыннар» — аеруча әһәмияткә ия. Ул мөселман дөньясында киң таралган традицион биобиблиографик әсәрләргә карый һәм галимнең танылган «Асар»ының дәвамы буларак кабул ителә ала. «Асар»ның беренче өлешендәге кереш сүзендә билгеләнгән максат — «гасырлар арасында үлчәү, кыяслар (чагыштыру, үрнәкләр) йөртеп, зиһеннәрне кузгатмак һәм фәһемнәрне (аңнарны) уйгатмак» — бу әсәренең дә максаты булып кала, чөнки — «әдип вә галимнәре улмаган кавем — бәхетсез, мәшһүр кемсәләрне оныткан кавем — хәмиятьсез (яклаучысыз), әдәбияты улмаган милләт — рухсыз» була.

«Мәшһүр хатыннар»га Р.Фәхреддин

биргән аңлатма — «Ислам әсәрләрендә вә әһле исламга күпме хезмәт күрсәткән хатыннарың тәрҗемәи хәлләре бәян ителгән бер китаптыр. Кызым Зәйнәп өчен яздым». «Мондый китапларны уку бик җиңел булмас», — дип кисәткән галим. Алар вакыт уздыру өчен генә укылырга тиеш түгел. Ул очракта алардан бер файда да булмас иде. Мондый китапларны аңлап, туктый-туктый укырга кирәк, чөнки аларның нигезен үгетнәсыйхәт тәшкил итә: укучы, китапта бирелгән биографияләр белән танышып, үрнәк яки яман кешенең тәрҗемәи хәле бирелгән очракта, гыйбрәт алып, тәҗрибә тупларга тиеш.

Кызы өчен генә язылган китапның башка кызларга да мөһимлеген аңлаган автор саллы хезмәтен (448 бит) бик вакытлы бастырган. Бу — Русия тарихына беренче рус революциясе чоры исеме астында кергән, Русия халыклары яңарыш өчен, демократик үзгәрешләр өчен көрәш башлаган вакыт. И.Гаспринский, Р.Фәхреддин, Г.Бубый һәм башкаларның, шул кадәр көч куеп, җәдидчелек идеологиясен формалаштыруы исә әлеге көрәшнең бер тармагын тәшкил иткән.

«Исламнар арасында бу көннәрдә Фараби, Ибн Сина, Мөхәммәд ибн Исмәгыйль әл-Бохари, Ибн Халдун, Ибн әл-Әсир, Әүзаги, Малик, Ибн Йосыф, Мөхәммәд бине әл-Хәсән әл-Шәйбани, Әхмәд бине Мөхәммәд бине Хәнбал, Шәфигый, Әбу Хәнифә, Габдулла ибне әл-Мөбарәк, Сибәвия, Хәлил, Ибн Рөшд вә гайре бу кеби затлар ни өчен заһир итмәюр (күренми)?» — дигән сорауны куйган Р.Фәхреддин. Бу сорауга җавап эзләгәндә, заманны гаепләү дә, хәзинәбайлык юклыкны, фәкыйрьлекне сәбәп итеп күрсәтү дә «иң биек ялган вә иң агыр бер ифтира (гаепләү) вә бөһтане сыйрфага (фәкать яла ягуга) раҗигъ улыр (кайтып калыр)», — дип ассызыклаган ул.

Аның үз җавабы: «Бәлки исламлар арасында бөек затларның элек заманда зоһур идеп (мәйданга чыгып) тә соң заманнарда зоһур итмәдекенең сәбәбе, элек заманда балаларын бөек адәм идәчәк сурәттә тәрбия илиян аналар мәбзул (күп) улыб, буның гакесе (киресе) уларак, бу заманда ул илә аналарың исламлар арасында мөнкариз улуыдыр (юкка чыгу). Әгәр дә бу заманда һәм бөек адәм идәчәк рәвештә тәрбия гыйлеменә татбикъ идәрәк (яраклаштырып, туры китереп) балалары тәрбия идән аналар улса иде, исламлар арасында һәм гали фикерле, һимmәтле (ялкынлы, дәртле), пакь күңелле, гүзәл холыклы галимнәр, инсанлык галәменә хезмәт күстәрән (күрсәтүче) мөҗәддид (яңартучы, новатор) вә мөхтәригъләр (ячып торучылар) зоһур идә белер иде». Шулай хатын-кыз мәсьәләсен автор иң зур иҗтимагый-сәяси проблемалар рәтенә куйган.

Милләтнең иң зур бәласын аның көчсезлегендә, фәкыйрьлегендә күргән затларга каршы чыгып, «милләтләрне хур вә зәлил (түбән, кадерсез) идән шәй (әйбер, нәрсә) көчсезлек дәгел, фәкыйрьлек дәхи дәгел, бәлки «киләчәкләр кичәннәр (үткәннәр) дәрәҗәсенә ирешмәячәкләр» игътикады (ышану, инану) тамырланмасыдыр», — дип дәвам иткән галим. Халыкның көченә, үз мөмкинлекләренә, киләсе көнгә ышанмауны Р.Фәхреддин каты авыруга тиңләгән. Ислам дөньясында хөкем сөргән торгынлыктан милләтнең хәле көннән-көн авырая баруын ассызыклап, ул җәмгыять әһелләрен милли эшләргә мөнәсәбәтне үзгәртергә, җиң сызганып, эш башларга чакырган.

«Мәшһүр хатыннар»ның «Хатимә»сендә (ахырында, эпилогында) галим милләтнең якты киләчәгенә, яшьләргә ышануын белдергән. Аның фикеренчә, өлкәннәр 25-30 елда үткән юлны яшьләр 5-6 елда үтәчәк, милләт шулай бик тиз алга китәчәк. Татар тормышын яңартуда төп адымнарның берсе итеп мәгърифәтче хатын-кызга мөнәсәбәтне үзгәртүдә күргән. «Хатынлар хөрмәтле тотылса вә кагыйдәсе илә тәрбия улынсалар, һәр төрле кәмаләт вә гыйлемнәрә үгрәнерләр. Хатынлары тәрбияле улан милләтнең балалары мәгълүматлы,

хөсне (яхшы, күркәм) холыклы, фазыйләт (өстенлек, яхшы сыйфатлылык) сүүче, тәрәкъкый арзу идүче (алга, үсешкә омтылучы), иттихад (фикер бердәмлеге, берләшү) вә гомум (барлык халык) хедмәте өчен җөмлә (барлык, бөтен) рәхәтене фида итмәклә бәрабәр мәхәббәте милләт (милләтне сөюче), хадиме гыйлем вә һәр эшләрендә шәҗигъ (кыю, батыр, йөрәкле), гаюр (гайрәтле, җитез, булдыклы) улырлар. Бу шәйләр милләтнең рухыдыр», — дип дәлилләгән Р.Фәхреддин фикерен.

Хатын-кызга тирән белем, яхшы тәрбия бирү кирәклеген җәмгыятькә аңлату бик авыр эш икәнен дә кисәткән галим, чөнки моның өчен халык арасында яшәп килгән стереотипларны үзгәртергә, дөньяга яңача караш тәрбияләргә кирәк. Һәм җәмгыятьнең хатын-кызга карата мөнәсәбәтен үзгәртү дә әлеге заманча карашларның бер өлеше булырга тиеш. Белем-мәгърифәт тарату, горефгадәтләрне үзгәртү, әхлак төзәтүдә төп рольне мәгърифәтченең әдәбиятка бирүе табигый хәл. Бу юлда да киртәләр бик күп булачагын кисәткән Р.Фәхреддин; аларның иң зурысы — иске карашларга ябышып ятучы һәм үзләрен галим дип атаучы затларның яңарыш идеяләренә каршы чыгуы. «Безләрдә голяма мөнсабына утырмыш затларның күбесе тарафыннан кызларны мәктәпкә йибәрмәк, кызларга язу белдермәк тиеш дәгел дия шәригать исеменнән нида (өндәү, чакыру) иделдеге бер вакытта бу илә китапны һич укучы булырмы?!.» — дип уфтанып куйган ул.

Шулай да Р.Фәхреддин төшенкелеккә бирелмәгән. Мондый заманнарның мәңгелек түгеллегенә язучының иманы камил. «Бер вакыт улыр, голяма мөнбәреннән уланнар ...: «Милләт тәрәкъкыйсын үстерү вә ислам актылыгын хәтта йир астында улан кечкенә ханәләргә кадәр төшермәкне өмид илер исәгез, кыз балаларыңызы укытыгыз! Кызларыңызы мәктәпләрә дәвам иттерегез! Милләт аналары йитешдерегез! Аналар улдыгыннан соң балалар улыр!..» — дия нида идәрләр, — дигән ышаныч белдергән ул. — Ихтимал ки, аш-су, күлмәк янчү, кунак, калфак сүзеннән башка шәйдән бәхәс идә белмәгән хатынлар йиренә ислахы гаилә, тәртибе идарә, тәрбияи әүляд (балалар, нәсел), идарәи мәнзил (йорт, торак) кеби мокаддәс вазифалардан бәхәс итмәктә улан хатынлар утырырлар».

Ул гына да түгел. «Ихтимал ки, «Таһир-Зөһрә», «Төш тәгъбире (юрау)», «Мәликә» кеби рисаләләр (мәкалә, кечкенә китаплар) укып, тәзйигъ (әрәм итү) гомер итмәкдә улан кызлар урынына ысулы тәгълим, низамы тәрбия (тәрбия кануннары), хөсне әхлак, ысулы мөгамәлә, адабе мәгашәрәт (аралашу кагыйдәләре), тасфияи әзһан (зиһеннәрне тазарту) юллары язылмыш китапларны моталәга (уку, өйрәнү) итмәктән ләззәт алган кызлар йитешерләр, — дип киләчәккә зур өметләр баглаган Р.Фәхреддин. — Кем белә? Бәлки гаиләләрнең хосуси мәҗлесләрендә вә гомуми зыяфәтләрдә (кунак итү, хөрмәтләү) бу кунакны гайбәт вә сафсаталар йирендә әдибләр маҗараларыннан, зарифлар (оста сүзлеләр) ләтыйфәләреннән (мәзәканекдот), галимләр тәрҗемәләреннән, гасырлар тарихыннан вә тарихлар фәлсәфәләреннән бәхәс иделәнәчәк бер вакыт килер».

Һичшиксез, Р.Фәхреддиннең бу сүзләрен төрки халыкларның алтын фондын тәшкил иткән һәм халык тарафыннан гасырлар буена сакланып килгән әсәрләрне кимсетү дип кабул итәргә ярамас. Галим бары тик кызларга төрле өлкәләргә бәйләнешле төпле белем зарурилыгына басым ясаган һәм шул вакытта гына аның үз әсәре дә игътибар үзәгендә булачагына ышануын күрсәткән. Язучының үзенә исә әсәрләрен укучы кызларны озак көтәргә туры килмәгән. Укучылары да, галим идеалларын тормышка ашырырга тырышучылар да бик тиз табылган. ■

МӘРЬЯМ

ЗАРИФ МӨЭМИНОВ*

(Повесть)

Д.Нәүрузова коллажы

Колчакчыларны тар-мар итеп бетергәч, япон бандитларын Ерак Көчыгыштан кугач, тынычлык урнашты.

Кызык бит, ә!.. Тыныч тормышка ни җитә!..

Ял көннәрендә ял итәбез. Сугышта чакта без ял көннәрен гел онытып бетергән идек бит әле. Үзебез арасында, артистлар булып, сәхнәдә уйныйбыз. Үзебезнең акларга каршы көрәшкән чагыбызда очраган кызыклы вакыйгаларны сәхнәдә күрсәтәбез. Көлә-көлә эчләребез катып бетә. Үз арабыздан оста әкиятчеләр табыла. Төрле кызык әкиятләр сөйлиләр — тыңлыйбыз. Тынычлык кына булсын! Безнең туксан тугыз төрле милләттән оешкан Русия халкы сугыш вакытында дошманнарга каршы бик оста көрәшә һәм җиңеп чыга белгән кебек, тынычлыкта эшли дә, күңел ача да белә.

Газета һәм журналлар укыйбыз. Кырыгар кеше бергә җыйналып укыганга, алар чүпкә әйләнеп, тузып бетәләр. Бер, ике тапкыр укыгансың икән, ул газета яки журналны яңадан укырмын дип уйлама. Чөнки алар, башка иптәшләр кулына күчә-күчә, бөтенләй юкка чыга. Шуңа күрә дә мин менә бу «Мәрьям» дигән хикәятнең кайсы газетада басылганын хәтерли алмый калдым. Моның өчен укучылар мине гафу итсен.

Безнең полкта бер егет бар иде. Тәскә-биткә кызлар кебек. Чибәр һәм, бик гаҗәп, тавышы кызларныкы кебек бик нечкә иде. Җырга һәм төрле әкиятләр сөйләргә шундый оста булуы безнең полкка зур бәхет. Кызыл Армиядән труппа оештыргач, бу егет һәрвакыт хатын-кызлар ролен шундый оста башкарды ки, һәркемнең исе китә иде. Шунда аны чын егет дип белмәгән кешеләр хатын-кыз дип ышаналар иде. Менә шул егетнең үзе хакында сөйләп биргән маҗаралары шушы инде.

...Матур җәйнең урталары иде. Без — бер төркем балалар, урамның уртасында — яшел чирәм өстендә, каз бәбкәләре кебек, өймәкләшеп утырганбыз. «Пештеле» уйнау хакында киңәшләшәбез. Атаманнар билгеләнде. Атаманнарның берсе итеп мине сайладылар. Димәк, мин хәзер икенче якның бер генералы булдым. Калган иптәшләр һәрберсе парлаштылар һәм йоплаштылар. Көрдәшү башланды, ягъни һәркем үзенә яшерен рәвештә ят исем атап, атаманнарның каршысына килә. Көрдәшү болайрак бара:

— Әссәламегаләйкем, өреп пыяла ватучы кирәкме? Әллә тешләп тимер өзүче кирәкме? — диләр. Атаманнар үзләренә ошаган исемне сайлый.

— Әссәламегаләйкем, атардай кирәкме, әллә кыярдаймы?

Шулай итеп, солдатларны сайлау тәмамланды. Һәрбер атаманга сигезәр «солдат». Атаманнар белән һәрякка тугызар кеше бүленде.

Иң башлап сызык эчендә калу хакында шобага салдык. Мин крепость тышында һөҗүм итәргә калдым. Миңа каршы яклар крепость эчендә оборонада калалар. Уенның тәртибе бар, әлбәттә. Анда оборонада торучылар аяк башлары белән һөҗүм итүчегә тибәргә, һөҗүм итүчеләр оборонадагыларның баш киемнәрен салдырырга тиеш. Шундый тәртиптә генә солдат стройдан, ягъни сафтан чыга. Ләкин тыштан һөҗүм итүчеләргә һәрвакыт хокук киң куела. Шунлыктан сызык эченә керүче атаман, сызыктан чыгып, җиңелүчегә калмас өчен, бик сак һәм сизгер көрәшергә тиеш. Тотамда мин төптә калдым.

*Повесть авторы – фольклорчы, мәгърифәтче әдип Зариф Мөэминов биографиясе һәм иҗат юлы белән журналыбызның беренче санында дөнья күргән Факил Сафинның «Әкиятче бабай» мәкаләсеннән укып таныша аласыз (Чын мирас. – 2014, №1. – Б.84-95).

Менә кычкырыш, көрәш башланды. Мин сызыктагы атаманга һөҗүм итәм. Тәмам уен кызып җиткәндә, урамда тавыш яңгырады:

— Кем өчен бу сугыш! Һә-әй, мир җыенына барыгыз! Иртәгә солдатларны сугышка озаталар!..

Дисәтник — авылдагы ун хуҗалык өчен җаваплы кеше — кычкыра-кычкыра, урам буйлап килә иде. Дисәтникнең тавышын ишетү белән шым булдык. Нинди солдатларны куалар, нинди сугыш икән ул дип, бер-беребездән сораша башладык. Ләкин арабыздан бу хакта белүче булмады. Кайбер балаларны: «Кайт, балам, иртәгә атаң сугышка китә бит!..» — дип, әниләре үкси-үкси елап чакырырга тотынды. Барыбыз да хәсрәтләнә башладык. Бу нинди эш? Хәтта иң сабыр саналган Госманның әнисе дә елаган дип, башларыбызны түбән иеп, өйләребезгә тарала башладык. Шулчакта урам капкасы төбендә басып торган Хәбип абыйны күрдек. Хәбип абый дигәч тә, ул олы кеше түгел иде, нибары унбиш-уналты яшьләрдәге малай. Шулай да ул сабан сөреп кайтып, битендәге тузаннарын да юарга өлгермәгән. Без аның янына килеп сорый башладык:

— Дисәтник нигә кычкыра? Госманның әнисе ник елый?

Хәбип абый безгә олыларча аңлатырга кереште:

— Япун дигән бер бик усал, сихерче патша бар икән. Менә шул патша безнең патшага каршы сугыш башлаган.

— Нигә сугыша икән ул патша? — дип сорадык без. Хәбип абый безнең сөйләп торганны да көтмичә, ашыгып сорау бирүебезгә бераз борчылды бугай. Аның тузанлы битенә тагы да каралык чыкты.

— Туктап торыгыз, сөйләп бетерим әле, — дип, сүзен дәвам итте. — Безнең Никулай патшаның рәгыятьләрен кысканга ачулана, ди ул. Крәстияннәреңә ник җир бирмисең? Боярларыңны ник тыймыйсың, дип әйтә ди. Япун патшасы үзе мөселман түгел, ди, түгелен. Ә шулай да түбәтәй кия, ди.

Без тагын да ышанып сорарга керештек:

— Алай булгач, нигә сугышка барырга? Госманның атасын сугышка җибәрмәскә кирәк. Дисәтник Шәйхелкәй бабайны кыйнарга кирәк. Урамга чыгып, солдат куып кычкырып йөрмәсен, — дибез.

Хәбип абый:

— Солдатларны Шәйхелкәй бабай куамыни аны?! Волостьтән патшаның начальниклары килеп куа бит аны. Начальникларга патша үзе куша…

Без, балаларның сорау бирер җире калмады бугай. Танауларыбызны гына тартып тора башладык.

Икенче көнне ишеттек. Зурлар сөйли: авылдан бала-чагаларын, хатыннарын калдырып, егерме җиде солдат киткән сугышка. Зурлар ачулана:

— Ник патшаны яклап сугышырга? Үзе крәстияннәргә җир дә бирми, ә боярлар җирдә эшләүчене имеп кенә яталар…

Шулай… Патшаны яклап сугышырга берәү дә риза түгел икән.

Күп тә үтми, хәбәрләр килә башлады: авылдан киткән солдат абзыйлар сугышта кайсы кайда үлгән, балалары тома ятим калган, бичаралар…

Исән калганнарының да хәлләре мөшкел — кайсының аягы туп белән өзелгән, кайсы кулсыз калган. Елаш та сыкташ авылда. Бигрәк тә карт солдат аналары, әбиләр киленнәре белән бергәләп елашалар, патшага каһәр укыйлар, ләгънәтләр яудыралар.

Яңа гына хезмәтләрен тутырып кайткан һәм сөйгән кызларын алырга өлгерә алмаган яшь солдат абзыйларның:

И алма бит, алма бит,
Алма битләр кала бит.
Алма битләр калмас иде,
Патша көчләп ала бит.
Өстемдәге күлмәгемнең
Яшел иде фарчасы.
Безне белгән, безне күргән —
Бәхил булсын барчасы, —

дип, өзелеп-өзелеп җырлаулары, яшь кенә солдат абыйларның сугышта һәлак булулары ничек соң олылар сүзен аңлый торган балаларның да үзәкләрен өзмәсен! Безнең белән һәрвакыт шатланып, уйнап йөрүче Госман, әтисе сугышка киткәч тә, ничек күңелсезләнде. Ул, без уйнаганда, уенга да катнашмый башлады. Күбесенчә, бездән яшерен елый да елый. Без аның күңелен бер чара белән дә күтәрә алмыйбыз. Бик кызыгырлык әйберләр бирсәк тә, ул һич тә шатланмый. Аңа әти кирәк. Әтисе бүген үләме, иртәгә үләме — сугышта йөри. Үзенә дошман булган, иреген кыскан патшаны яклап, сугышта йөри. Бер сөйләшкәндә: «Моннан да гарьлек дөньяда бар микән?» — дип уйладым мин.

— Әгәр дә егет булып җитешсәм, патшаны яклап сугышка түгел, солдатка да бармам, — дип куйдым.

— Бармыйча нәрсә эшләрсең? — диделәр.

— Качармын, — дидем.

— Кая качарсың?

— Урманга…. Оңгарның теге ягына, эт акланына качармын. Анда берәү дә барып йөрми, диләр. Патшаның начальниклары да анда бара алмас. Мин, солдатка бармыйча, шулай котылырмын, — дим.

Дөрес, минем бу уйларым ул чакта балаларча уйлар гына булганнар. Вакытлар узып тора, мин дә үз акылым үскән саен төплерәк, дөресрәге, баштагы уйларымның нигезсезлегенә төшенә барам. Тик бернәрсә үзгәрми, патшаны якларга ярамаганлык хакында башымдагы уйлар һәнүз саен ныгый бара. Ярый ла табиб солдат хезмәте өчен сәламәтлек ягыннан бер-бер кимчелегемне тапса… Ул чакта солдаттан калып та булыр иде. Ләкин минем, башым авыртып та, хаста хәлендә ятканым юк бит. Ул гына да түгел, абый һәм энеләрем арасында зур, таза гәүдәле булып үсәм. Кешеләр арасында хәтта мине «Гвардия» дип йөртә башладылар. Көчем җәһәтеннән дә мине «абыйсына караганда көчле», дип әти-әни һәм күрше-тирәләр дә мактый. Хәтта кызлар да мине мактый башлады. «Үзе таза, үзе чибәр, мәк чәчәге кебек егет», — диләр. Тик мине мактаган кем булса да: «Солдаттан исән-имин генә йөреп кайтса…» — дигән сүзне өстәп куймыйча калмый бит. Димәк, мин бүгеннән үк солдат!..

Солдат, солдат та бит, нинди солдат соң мин?

Крәстияннәрнең дошманы булган патшаны яклый торган солдат! Менә монысы хурлык инде! Булсаң иде крәстияннәрне яклый торган хөкүмәтнең солдаты! Андый хөкүмәтне каян табарга соң? Солдат булу хакында төрле уйларга чумып йөрим. Балалар хакында аналар күбрәк кайгыралар, күрәсең. Әни миңа бик еш сорау бирә башлады:

— Улым, син бик күңелсез йөрисең. Әллә авырыйсыңмы? — ди һәм өстәп куя. — Бала вакытыңнан бик таза булып үстең. Егет булып җиткәндә генә авырып китә күрмә. Ходаем исәнлегең бирсен инде, — ди.

— Шул исәнлек өчен кайгырам, әни, — дим. Үзем көлеп җибәрәм.

Әни дә минем солдатка китәргә курыкканымны сизә булса кирәк.

— Исәнлек өчен кайгырма, балам. Ходай бәхетеңне мул итсен, — ди.

Язгы матур көннәрнең берсендә киләсе көздә призывка барачак егетләрне, старостаның өенә чакырып, барлап куйдылар. Минем исем һәм фамилиям дә шунда теркәлгән иде. Староста, баш писарьга карап, мине күрсәтте:

— Менә минем артиллерия гвардиясе! — дип хәтта аркамнан кагып куйды. Старостаның бу мактавына минем яшь йөрәгем горурланып китте. Халык алдында мин үземне горур тоттым. Чөнки арабызда чирле чебеш кебек бөкшәеп беткән егетләр дә бар иде. Баш писарь Борис Иваныч русча ниләр сөйләп мине мактагандыр — мин аңламадым. Тик старостаның:

— Совершенно правильно! — дигән сүзе генә башыма кереп калды.

Матур яз артыннан иң ямьле җәй килде. Быелгы җәй шундый соклангыч булды. Хәтта мондый җәйләр бөтенләй истә дә калмаган. Игеннәр котырынып үсте — арыш басуына керсәң, дуга да күренми. Ул башакларын күр — песи койрыгыдай асылынганнар. Бодай, борай, ул борчак дисеңме — картлар да болай тигезе белән ашлык уңган елларны бик сирәк хәтерли. Шулай да карт-корылар бу мул уңыш биргән җәйне мактау һәм шатлану белән бергә, нәрсәдәндер яшерен генә шомлана да. Мул уңыш хакында сөенеч белән сөйләгәннән соң:

— Ходай күз куанычы итеп кенә биргәне булмасын инде, кайгы-хәсрәтсез генә барчабызга да ризык итсен, — дип куялар.

Безнең гаилә эчендә дә андый сүзләр кабатланып, көз көне минем призывка барачагым да бик еш искә алына.

Ярар, ямьле болыннарда, ямьле урманнарда, печәннәр чабып, эскерткә салып тәмамладык. Челтерәп аккан саф, тонык сулы чишмә буйларында, матур юкә куаклары төбендә карлыганлап, кура җиләкләп, кәрәзле яңа бал белән кабартмалап, күмәчләп эчкән чәйнең тәме теш төбендә генә калды.

Печән эше бетеп, арыш уруга гына керешү белән, ураза ае башланды. Җәһәннәм кебек кызу көндә ашамый-эчми урак урырга кирәк. Җитмәсә, арыш шундый уңган, урак тыккысыз. Кырыклы дисәтинәдән унөч-ундүрт йөз көлтә чыга. Көлтәләре кеше биеклеге, калынлыгы күәс чиләгедәй. Мин:

— Ураза тотмыйм быел. Киләсе елга тотармын. Көз көне призывка барасы егетмен. Моңа хәтле никрут булган егетләр берсе дә ураза тотмадылар, — дидем.

Әни белән түтәкәй:

— Никрут егеткә тоташ өч ай ураза тотарга кирәк. Ябык булсаң, солдатка алмаслар иде, — диләр. Үзләренең күзләреннән яшь бөртекләре тәгәрәп чыкты.

— Сез минем өчен кайгырмагыз. Әрвахларга багышлап, Коръән чыктым. Мөдәррис хәзрәткә унбиш көн арыш сугарга булыштым. Хәзрәт миңа: солдаттан котыл, дип фатиха бирде. Абыстайга бер сум сәдака биреп, Коръән ачтырдым. Солдаттан котыласың, сөйгән кызыңны ярәшәсең, диде. Мин солдатка китмим, вәссәлам!.. — дидем.

Шулай да бер көн уразага кердем.

Арыш урагының бик кызган чагы. Шулай бик кызу аяз көннәрнең берсендә басуда тавыш купты. Бөтен юл тармаклары тузан белән капланды. Халык арбаларга төялгән, авылга таба чаба. Авыл ягыннан төтен күтәрелгәне дә күренми, бу нихәл? Төялгән халык чиный, бакыра. Җыр тавышы дисәң, аңа да охшамый…

— Халык үкерешеп елап кайта. Нихәл булды икән? — диде апам. Без дүртәү гаҗәпкә калып, аяк өсте басып, тузан күтәрелгән юлларга карап торган чагында, бишмәтен иңсәсенә салып, җир башыннан Садри агай килеп чыкты. Ул кисәк кенә:

— Ярман патшасы сугыш башлаган. Солдатларны сугышка куалар, беттек, оланнар!.. — дип кычкырды.

Мин кисәк кенә:

— Безнең гаиләдә китәсе солдат юк әле. Алсалар, мин көз көне китәрмен, — дидем.

Садри агай салмак кына:

— Болай булса, көзне дә көтмәсләр, туган, хәерле булсын, — диде дә китеп тә барды. Эчемнән: «Садри булып Садри да бездән тарыга икән, — дип уйладым. — Ярар, китәсе кешеләрне, кирәк булса, табарлар. Оңгар артына киткән булсалар да, табып җибәрерләр. Без әлегә тыныч торыйк, урыйк әле», — дидем. Без вакытыннан алда кайтмадык. Авылдан безне эзләп килмәделәр. Икенче көнне запас содатларны авылдан озаткач кына, кабат басуга киттек.

Халык арасында төрле куркыныч сүзләр йөри. Имеш, герман патшасы бик усал һәм тәкәббер. Солдатлары куәтле, бөтен дөньяга машиналарны мимечләр ясап чыгара икән. Мимечләр — бик оста һәм белемле кешеләр. Герман патшасы әйтә ди:

— Мин үз халкыма гыйлем, һөнәр өйрәтәм. Рус патшасы русларны аракы эчәргә һәм чукынырга гына өйрәтте. Петербургны һәм Мәскәүне өч ай эчендә алып бетерәм. Русларның чиркәүләрен дуңгызлар лапасы итәм, — дип әйтә, ди. Герман патшасының ядрә яудыра торган болыты бар икән. Яраплан исемле ди ул болыт. Яраплан болытның төнлә яп-якты итеп чыгара торган кояшы да бар, ди. Караңгы төндә яктырып килә дә рус солдатлары башына ядрә яудыра икән, дип сөйлиләр.

Сугыштан һәм солдаттан калырга минем өметем өзелде. Нәрсә эшләргә соң, ничек бу сугыштан качарга, дип уйладым. Дөресе шул: сугышка барып, дошманнарга каршы сугышу миндәй яшь егеткә килешә дә иде. Тик бер хикмәт бар. Нәрсә өчен сугышам? Кемне яклап сугышам? Карты-яше, хәтта әбиләр дә, муллалар да — беркем дә безнең патшаның җиңүен теләми. Сугышка китүчеләр үзләре немецларның җиңелүен теләми! Димәк, сугыш беркем өчен дә кирәк түгел икән. Мондый сугыштан качу гына кирәк. Ә соң ничек һәм кая качарга? Мин бала вакытта уйлаганерактагы Оңгар сырты артындагы эт акланы хәзер басу булып, анда һәр елны бодай чәчәләр. Унбиш-уналты яшьтәге малайлар анда сабан сөрә, тырмалый. Шундый уйлар белән уйланып, бик озак баш ватканнан соң, менә дигән бер акыл керде башыма. Ул акыл менә болай иде.

Хәзер ирләр исемендә булган аксак-туксак, чулак-чукрак, тома сукырларга кадәр барлау һәм тикшерү барган чагында, хатын-кызларга — яулык бәйләп, шәл ябынып йөрүчеләргә — бернинди барлау да, тикшерү дә юк. Гәрчә егет кеше булсам да, минем яшь һәм чибәр чагым, сакал-мыек чыга да башламаган. Зур сакал, мыеклы кешеләр безнең нәселдә дә юк. Чөнки мин, әниемнең энесе шәкерт абыкайның шоп-шома ияген сыйпаштырып:

— Олыгая башлагач, сакал чыкмавы да күңелсез икән. Җиңгәгез мине картаймый, һәнүз яшь егет килеш тора, дип куана торгандыр да, узган гомерләр алай дими шул, — дия иде.

Миңа да, ашыгып, сакал-мыек чыкмас әле. Тавышым калынрак булса да, бик матур. Җырга һәм көйгә бер дә кызлардан ким түгел мин. Хатын-кызлар киеменә төреним дә бу ләгънәт төшкән патшаны яклый торган сугыштан котылыйм, дигән уемны ныклап беркеттем һәм сәфәр чыгарга хәзерләнә башладым. Үземне хатын-кыз кыяфәтенә китерү өчен илле чакрым ераклыкта булган рус һәм керәшеннәр яши торган катнаш бер авылга карап юл тоттым.

Сау булыгыз, туганнар!

Көзге озын төннәрнең берсендә, уянуым белән, сәфәргә китәсем исемә төште һәм йокым очып китте. Тышка чыгып, һаваны күзәттем. Төн шундый караңгы, тәмам мин теләгәнчә. Тагын, җитмәсә, мине, сугыш качкынын, һичкемгә күрсәтмәс

өчен, бөтен дөньясын куе томан каплап алган. Минем өчен иң кирәкле, уңай булган бу иртәне күреп, бик шатландым һәм тизрәк юлга чыгарга ашыктым.

Сау булыгыз, туган-үскән йортым, әти-әни һәм туганнарым! Минем чыгып китүемне гаиләмнән берәү дә сизмәде. Абзарлар аша — ындырга, ындырдан — басуга, басудан — урманга. Юллар миңа таныш иде. Хәтта юл буразнасына сураеп үскән тигәнәк, әрем сабаклары да миңа таныш иде. Шунлыктан томанлы караңгы төн мине тоткарлый алмады. Басуны тиз үттем һәм урман эченә кердем. Әле таң ату билгесе юк иде. Ниһаять, егерме чакрымлап киткәннән соң, урманны да уздым. Көн яктысы да беленде. Ярар, дидем мин, хәзер мине күрүчеләр булса да, танып эндәшүчеләр булмас. Шулай җәһәт йөрүем белән илле чакрым булган базарлы, рус-керәшен халкы катнаш авылга килеп җиттем. Бу авылга әти белән базарга килгән бар иде. Әти керә торган фатир хуҗасы — керәшен, бездән уздырып, татарча сөйләшә иде. Мин шушы йортка кердем. Хуҗа хатын миннән:

— Кайсы авылдан син, нинди йомыш белән килдең? — дип сораштыра башлады.

Мин аңа читләтеп җавап бирдем. Чөнки туп-туры җавап бирергә ярамый бит инде.

— Фәлән авылның фәлән татар малае. Атам-анам юк. Бары бер апам белән генә тормыш итәм. Бәлки тиздән үзем сугышка алынырмын да, апамның өс-башына кияр киемнәре юк. Искерәк булса да, апама өс-баш киемнәре юнәтеп булмасмы, дип килгән идем. Сездә артык хатын-кыз киемнәре булмасмы? Аның өчен мин акча түләр идем, — дип, хуҗа хатынга ун сумлык кәгазь акча күрсәттем. Акчаны күрү белән, хуҗа хатын икенче бүлмәдән күп кенә хатын-кыз киемнәре күтәреп чыкты һәм минем алга китереп ташлады.

— Үзеңә ошаганнарын сайла, — диде һәм күлмәк-күнчекләр өстенә сырган җылы киемнәр дә китереп куйды. Мин арадан үземә ярарлык күлмәкләр, яулык һәм шәл сайладым. Дөрес, бу киемнәр беркадәр киелгән булса да, әле тузмаганнар. Шундый ике күлмәк, ике яулык, бер шәл өстеннән бер сырган пиджак та алдым һәм хуҗа хатынга ун сумны бирдем. Хатын тагын бер иске күлмәк өстәде. Самавырын хәзерләп, чәй эчерде. Мин хуҗа хатыннан сатып алган кием-салымнарны капчыгыма салдым да чыгып китәргә хәзерләнә башладым.

— Көн кичегеп килә, кайтыр авылың ерак. Арып килгәнсең. Ял ит, сиңа кунарга кирәк. Юлга иртәгә чыгарсың, — диде.

Мин юл өстендәге бер авылда куначагымны әйтеп, хуҗа хатын белән саубуллаштым һәм чыгып киттем. Авыл читендәге ындыр араларына барып җиткәч, кеше-фәлән юк микән дип, ары-бире карандым. Ниһаять, кешеләр түгел, этләр дә күренмәгәч, туп-туры бер ындырга кереп, әвен лапасына яшерендем. Чөнки кич булып, караңгы төшә башлаган иде. Монда мин тәмам ирләр киемен салып ташлап, хуҗа хатыннан сатып алган хатын-кыз киемнәрен кидем. Ләкин килешлеме-түгелме икәнлеген карарга янымда көзгем булса да, төн караңгы иде. Әвеннән чыгып, авылның икенче башына барып чыктым. Бу авылны авыл дисәң дә, шәһәр кебек зур. Атна саен ике тапкыр базар һәм ел саен ике тапкыр ярминкә була. Авыл башыннан урамга килеп кердем. Һәрбер өйдә ут яктысы бар иде. Авыл очыннан берничә өйне үткәч, уң якта урамга кабыргасы белән салынган кечерәк бер өйнең тәрәзәсеннән карадым. Бер хатын баласын селкеп утыра һәм үзе җырлый да, җылый да.

— Апа, кунарга фатир бирче! — дип кычкырдым мин, тавышымны нечкәртә төшеп.

Хатын тәрәзәдән минем кыз кеше икәнлегемне күрде булса кирәк, сатулашып

тормады, керергә кушты. Өйгә кереп, исәнлек-саулык сорадым. Билгеле, үземне хатыннарча тотмакчы булам. Исеме белән йөртим, бу хуҗа хатын Анюта җиңги иде. Ул мине яп-якты өйдә күргәч, шикләнеп китте булса кирәк, төсе үзгәрде һәм миннән каты-каты сорашырга кереште:

— Төн заманында хатын-кыз башың белән нәрсә эшләп йөрисең? Кайдан килдең? Кая барасың?

Мин кыеклатып җавап бирәм. Хатын-кызларча борчылган булып:

— Фәлән авылдан көчкә килеп җиттем. Бердәнбер абыем бар иде. Ул да сугышка китте. Өйләнмәгән дә иде. Бер башым гына булсам да, торырга рәтем калмагач, шушылай йөрергә чыктым. Эш таба алсам, эш эшлим. Шушылай Ходай тәрбиясенә калдым инде, — дигәч, Анюта җиңги эреп китте:

— И, син бичаракай да сугыш ятиме икәнсең. Абыең кайсы шәһәрдә, хаты киләме? — ди башлады.

Аптырап калмадым. Сугышка киткән күпме авылдашка хатлар язган кеше бит инде мин.

— Башта Калуга шәһәрендә иде. Хәзер сугыш эчендә. Хаты-хәбәре күптән үк юк инде, — дидем. Анюта җиңги еларга кереште:

— Минем ирем Кузьма да Калуга шәһәрендә. «Бүген таңда сугышка китәбез», — дип хат яза. Сугыштан исән чыкса гына ярар иде, — дип өзелеп-өзелеп сөйләргә кереште. Анюта җиңги белән башка кайгы-хәсрәтләрне онытып, тик сугыш хакында гына кайгырырга, зарланырга керештек. Шулай да сүз арасында Анюта җиңгинең шикләнеп китүе сизелә иде. Ниһаять, Анюта җиңги минем шәхси ягымны тикшерүен әкренләп оныта башлады бугай. Бәлки ул минем шәхси ягымнан бер дә шикләнмәгәндер, бары мин үзем генә шулай уйлаганмын. Анюта җиңги дә, мин дә әкренләп тынычлана башладык. Ул миңа өс һәм аяк киемнәремне чишенергә кушты. Үзе өстәлгә самавыр китерде. Чәй хәзерләде. Бит-кул юып, чәй эчәргә керештек. Мин һәнүз сөйләнүне өзмәскә тырыштым, чөнки, минемчә, хатын-кызлар үзләре дә күп сөйләнәләр һәм күп сөйләүчене яраталар. Сугыш куркынычлары, толлар, ятимнәр хакында без бик озак зарланыштык. Анюта җиңги сүз араларында елап та алды. Ул ире Кузьма дәдәй белән бик тату тормыш иткән.

Минем дә күңел буш түгел: тотылып, һәлак булудан бик куркам. Мин гади генә качкын түгел бит. Бер-бер әйбер урлаган каракның хәле минекенә караганда күпкә яхшы. Хөкүмәт хезмәтеннән качкан иң явыз качкын итеп тотарлар дип, нык куркам. Үземне саклау өчен, һәрбер секундта, үз-үземне тикшереп, ролемне югалтмаска тиеш. Яралганнан бирле үземә хас табигатемнән баш тартып, ят җенес — хатын-кызлар холкын үзләштерү йөзендә, чын табигать законын бозарга тырышам.

Анюта җиңги миңа сәндерәгә менеп ятарга кушты. Үзе, бала бишегенә баш төртеп, караватта ятты. Көзге төннәр бик озын бит. Беренче уянып китүдә үк минем күзләремнән йокым очты. Уйланам. Төрле хыялларга чумам. Күзләремне көчләп йомсам да, уйлар, пружиналы парта капкачы кебек, кисәк ачылып китәләр. Гәрчә мин Анюта җиңги белән беренче очрашуда ук шактый уңыш казансам да, әле алдагы күрәчәкләр болай гына булырмы? Әлегә Анюта җиңги алдында, ул ышанса-ышанмаса да, кыз кеше итеп үземне тәкъдим иттем. Шунда да бу алышбирешем ышаныч бирми кебек күренә. Әгәр дә әлеге хатын мине әллә нинди хатын-кыз киемнәренә төренеп, үз йортына килеп кергән бер ят ир кеше дип белсә, шунда ук йөрәге ярылып үлмәсме? Бу гади шаяру түгел. Бу аулак өйдә сәвәнәйле уйнау түгел. Бу эшем өчен мине беркем дә шаркылдап көлеп гафу итмәс. Анюта җиңги, кыз кеше булуыма ышанса да, мин аның өендә күпме генә вакыт

торалам?.. Бу авылда озакка тукталу куркыныч булачак. Бердән, бу авылда волость начальниклары урнашкан. Икенчедән, үз авылыма бик якын. Бүген үк эзләп килмәсеннәр дип куркам. Тагын кире уйланып: «Йөрермен әле шулай. Бу хатында шик тудырмадым бугай ла! Хәтта аңа ошадым. Ул миңа: «Син кыз түгел, егет кеше бит», — димәде ич. Дөньяда бөтен эш тә кулыннан килгән хезмәтчеләр өчен үләрдәй булып торучы ялгыз калган бай солдаткалар күптер әле. Ирләр эшеннән дә сәләтле булуымны күрсәләр, кан булса да, төкермәсләр», — дип, әчеле-төчеле хыяллар белән көчкә таңны аттырдым.

Анюта җиңги иртәнге чәйгә бәрәңге шәңгәләре пешерде. Чәй әзерләп, урыныммнан төшәргә кушты. Бит-кул юып, чәйгә утырдык. Мин, нәкъ татар кызларыча, әдәп саклап, кыюсызланып утырган булам. Анюта җиңги исемемне сорады.

— Минем чын исемем Мәрьямбану. Ләкин, кыскартып, Мәрьям дип йөртәләр, — дидем.

— Сезнең халык арасында Бану исемле кызлар да була бит. Ничек Бану дип кенә әйтмәгәннәр сине? — диде Анюта җиңги.

— Әни имезгән вакытта ук мине Мәрьям дип атаган. Шунлыктан бар кешеләр дә Мәрьям дип йөртәләр.

Иртәнге чәйдән соң, китәргә җыена башлагач, Анюта җиңги бик ялварып, калуымны сорады:

— Кунак итәрлек яхшы ашларым булмаса да, берничә көн тор инде. Мин дә ялгыз бит. Су алып кайтырга чыксам да, балам ялгыз кала. Чана юлы төшкәнче, минем белән торсаң, бигрәк яхшы булыр иде. Чана юлы төшү белән, әти мине үзләренә алып китә, өем бикләнә инде, — дип, бөгелеп төшеп еларга кереште.

Аның ямансу тавышы белән үксеп елавы миңа да тәэсир итте. Чарасыз мин дә елап җибәрдем. Чөнки минем дә бурам буш түгел бит. Мин тотылудан куркып һәм Анюта җиңгинең шәфкатенә сөенеп елыйм. Шулай итеп җиңги белән тәмам туганлаштык. Ләкин чын серләр ачылу дәрәҗәсенә барып җитмәделәр. Мин һаман үземне хатын-кызларча булырга күнектерә идем. Анюта җиңгинең уе миңа хатын-кызларча өйрәнү мәктәбе булып хезмәт итте.

Үзебезнең өйдән чыгып киткәндә, гаиләдә мине беркем дә күрмәгәнен әйткән идем инде. Мин, гадәттә, йә иптәшләрнең берсендә кунам, йә бөтенләй күрше авылда әнинең бертуган энеләрендә йоклап, икенче көнне яки берничә кич кунып кайтам. Алар мине шулайдыр дип белгәннәр. Ниһаять, ике-өч көннән соң базар җиткән.

Әти, базарга барырга хәзерләнеп, акча сала торган киндер янчыгын кармалаганда, янчык эченнән бер кәгазь тартып чыгарган. Кәгазьнең ике ягын тутырып язган минем кулъязмаларымны күргән. Ул түбәндәге сүзләрне укыган:

«Шәфкатьле вә хөрмәтле әткәем һәм бәгырем парәсе газиз әнкәем! Минем өчен кайгырмагыз. Исән булсам, бер кайтырмын. Хәзер мин үз теләгем белән сугыш хезмәтенә китәм. Чөнки бөтендөнья котырган этләре нәкъ безнең кебек егетләрнең канына сусаганнар. Сынашып карарбыз, кемнәр безнең канны түгәрләр. Бәлки үзләренең башларына ашкына торганнардыр. Вакыты шундый. Безгә дә шул бөтен дөньясы ач, ялангач, тол, ятим, гарип итеп калдыра торган сугышка барып кереп, йә үлмичә, йә гомерлек гарип калмыйча, котылу юк. Мин призывка чакыруларын көтмәскә булдым, күрәсез бит, аяксыз-кулсыз, тома сукыр булмаса — барын да сугышка куалар. Тазасы да, зәгыйфе дә бер бәһадән йөри. Начальниклар мине сездән сорасалар, шушы язуны күрсәтегез. Бәлки ул вакытларда мин фронтта булырмын. Газиз әткәем, син миңа рәнҗемә! Мин синең янчыгыңнан ун сум акчаңны алдым. Исән булсам, кайткач та 20 сум итеп түләрмен. Хуш, исән булы-

гыз, бәхил булыгыз! Ирекле хезмәткә туганнар! Илебезнең намусын дошманнардан мәсхәрәләтмәбез. Шуны белеп торыгыз. Кәрами».

Гаиләм бу хатны укып елашкан һәм бу серне, вакыты җитмичә, беркемгә дә әйтмәгән.

Ниһаять, минем яшьтәшләр призывка барырга өч көн калгач, Калуга шәһәрендәге бер запасной частьтән хатым килеп җиткән. Бу хатны мин Анюта җиңгинең ире Кузьма дәдәйнең адресы белән юлладым, тик Кузьма дәдәйнең исем-фамилиясе урынына үземнекен язган идем. Кайда хезмәт итүем хакында призывка шушы хатны илткәннәр. Военный начальник:

— Кызганыч, миннән рөхсәт белән китсә, суточный акчалар биреп озаткан булыр идем, — дигән. Шулай итеп, мине гаиләм дә, начальниклар да, авыл старосталары да сугыш хезмәтендә дип белгәннәр. Тик яңадан бернинди хатым да килмәгән. Сугышта һәлак булган дип, әти-әни һәм туганнарым кайгырышканнар.

Анюта җиңгидә мин кызлар эшенә өйрәндем. Дәрт белән тотынган эш һич карулашмады. Җеп эрлим, чөлкә бәйлим, кер уам, идән-сәке юам. Татар хатын-кызларынча, итәк кыстырып, җиң сызганып, чын кызларча җыйнакланып йөрим. Миңа беркем дә:

— Һич килешмисең, — дими.

Тик беркөнне Анюта җиңгигә кич утырырга рус һәм керәшен кызлары кергәннәр иде. Бер рус кызы, Дунька диләр үзен:

— Син, Мәрьям, как-то абыема охшагансың. Гәүдәң бик тупас, — дип йөдәтте. Аның болай бәйләнүе мине яхшы ук өркетте. Дуңгыз Дуньканың бәйләнүенә хәтерем калганын сизеп, Анюта җиңги миңа ярдәмгә килде. Ул Дуньканы орышты:

— Син, Дунька, дөнья күрмәгәнсең, кешеләрне дә танымыйсың. Кешеләр үз туганнарына охшый икәнлеген дә аңламыйсың. Менә син үзең абыең Иванга яхшы ук охшагансың, — дигәч, Дунька артык карулашып тормады. Бу эләгешүне тизрәк оныту өчен, матур тавыш белән җырлый башладым. Дүртенче-бишенче җырларда кызлар да катнаша башладылар.

Агыйделне кичкәндә,
Беләгем талды ишкәндә.
Бер җырладым, бер җыладым,
Абыем исемә төшкәндә.
Ай-ли, лимонад,
Сусаганда эчәргә.
Бар куәтем, юк канатым
Сагынганда очарга.
Ай-ли, лимонад,
Сусаганда эчәргә.

Таштан күпер кем салдырган
Уфа калаларына.
Кайгы-хәсрәт килә икән
Ата балаларына.
Ай-ли, лимонад,
Сусаганда эчәргә.
Бар куәтем, юк канатым
Сагынганда очарга.
Ай-ли, лимонад,
Сусаганда эчәргә!

Анюта җиңгигә мин бик ошадым. Әйтерсең лә без икәү апалы-сеңелле торабыз. Мин аңа җеп эрләшәм, өен чистартам, утын кисәм, су китерәм, мунчасын ягам. Ләкин мунчаны үзем генә керәм һәм аңа бик яхшы сылтау да бар. Анюта җиңги мунчага киткәч, мин өйдә калам. Мин мунчага китсәм, ул үзе кала. Өй ялгыз тормый. Анюта җиңги, кибеткә барып, кершәнен, сандалын алып кайтып бирә. Хәтта беркөнне исле сабын да алып кайтты.

— Син кыз кеше, үзең тот, — диде ул.

Көннәр узды, җир катырды һәм беренче кар да төшеп өлгерде. Тыз да быз чаналар шуа башлады. Ниһаять, бер базар көнне Анюта җиңгинең әтисе Сандр бабай кызын алып китәргә килеп тә җитте. Түбәмә таш төшкәндәй булды. Мин хәзер тагын да ят кешеләр белән очрашырга тиеш. Минем бу авыр хәлгә калуым Анюта җиңгигә дә бик каты тәэсир итте. Ул елап җибәрде һәм:

— Миңа синнән аерылу Кузьма дәдәңнән аерылган кебек үк бик авыр. Әллә, Мәрьям, бергәләп, әтиләргә китәбезме? Берничә көн кунак булырсың, аннан соң тагы рәте табылыр әле. Үз авылыгызга кайтсаң, торыр урыным юк, дисең.

— Мин синең белән бик барыр идем дә, Сандр бабай ни әйтер бит, — дидем.

— Менә тагын, — диде Анюта җиңги. — Барасың килсә, сине алып бара ул. Бик яхшы, киң күңелле минем әти-әниләр.

Безнең бу киңәшебезне ишетеп, Сандр бабай:

— Анютаның дустын һич тә урамда калдырып китмим. Безгә барыйк әле бергәләп. Миңа баргач та үз теләгеңдә булырсың. Күпме кунак булсаң да, без йөз чыта торган кеше түгел. Ходайга шөкер, байлыгым бар. Тик бер-бер артлы ике улым сугышка китте. Өченчесенә Анюта кияве дә китте. Барысы да бер йорттан чыккан кебек, кызым, — диде.

Сандр бабайның мине «кызым» дип атавы шундый ямьле булып ишетелде. Мин Анюта җиңги белән Сандр бабайларга киттем. Чананың проводнигына утырып, дилбегәне үзем тоттым. Ат тотуымны Сандр бабай бик ошатты.

— Егетләрдән калышмаслык нык кыз икәнсең, — ди. Сандр бабайның мине егетләргә охшатуы эчемне пошырды. Ат үз юлыннан юыртты.

Көн дымык, болытлы, әкрен генә кар төшкәләп тора. Юл бик көйле, сүзсез баруны мәслихәт күрмичә:

— Юл бик көйле икән, бабай, көн бозылганчы китерәсе утының, печәнең булса, китер дә өй инде, — дидем.

Бабай да минем бу сүземне мәгъкуль күреп, китерәсе печән барлыгын әйтте, тагын шундый күп кенә сүзләр сөйләнде. Сүзгә Анюта җиңги дә катнашты. Көн караңгылана башлагач, без Алан дигән авылга кайтып җиттек. Анюта җиңги шушы авылда туып үскән. Сандр бабайның беренче улы Пётрдан кече кызы икән. Биек коймалы, такта капкалы, урам буйлата салынган зур ике бүлмәле, калай түбәле, тыштан караганда бай тормышлы күренгән шушы йорт Сандр бабай йорты икән. Ат туп-туры капкага килеп туктагач:

— Мәрьям кайдан белгән икән минем йортны, туп-туры капкага килеп туктады… — дип шаркылдап көлде.

Мин:

— Ат шушы хуҗаныкы булгач, белеп була, бабай, — дидем.

Безне бер карчык, ике хатын каршы алды. Барысы да бик ачык, уен-көлке сүзләр белән күтәренке күңелдән кабул иттеләр. Бабайга мин өйгә керергә куштым. Үзем ат тугара калдым. Теге ике хатын-кызның берсе бик яшь, кызларча бик чибәр, кара кашлы, кара күзле, тулы ал йөзле. Бусы Сандр бабайның иң кече килене икән. Кече улы Тарас сугышка шушы яшь кәләшне калдырып киткән икән.

Ат тугарышырга бу килен дә катнашты. Атны тугарып бәйләп куйгач, әлеге яшь килен мине дә өйгә алып керде. Өйнең беренче бүлмәсе — аш һәм кием-салым бүлмәсе икән. Шунда тышкы киемнәрне салып, икенче яктагы бүлмәгә кердек. Бүлмә бик чиста һәм унлы лампа белән яктыртылган иде. Өстәлдә зур ак самавыр гөжләп утыра. Иң башта Сандр бабай өстәл кырына утырды, һәммәбезне дә чәй эчәргә чакырды. Мине Сандр бабай кырына утырттылар. Сандр бабайның карчыгы ачык йөзле, ягымлы сүзле, ак һәм керсез күңелле булса кирәк. Өйдәгеләрнең һәммәсенә дә бик ягымлы эндәшә:

— Ничек әле исемең? Мәрьям бугай, — дип, миңа көлеп карады.

— Сөенеп кунакка килүләрем түгел инде, — дип, Анюта җиңги зарланырга кереште. Аны киләчәк өметләре белән юаттылар. Һәркемдә дә бер сугыш хәсрәте, сугыш кайгысы. Шулай күп кенә зарланганнан соң, Анюта җиңги минем дә бер сугыш ятиме икәнлегемне әйтте.

Сандр бабай сүзгә кушылды:

— Патшаларның татусызлыгы әллә кемнәр белән таныштырыр. Сугышта йөрүче солдатлар бер-берсеннән ил читендә ерак торсалар да, танышырлар, туганлашырлар. Бу зур һәм каты сугышлар һәркемгә дә дөньяны таныта, — диде.

Чәйдән соң безне алып килгән атны яшь килен Авдотья белән, бәйдән ычкындырып, коедан су алып эчереп, печәнгә куштык. Абзарда берсеннән-берсе зур тагын ике ат бар иде. Атларга сәндерәдән печән төшердек. Яшь килен шушы Сандр картның иң кече улы Тараска җәйге җыен чорында гына тормышка чыкканлыгын һәм әле тормышка чыкканнан биш ай да тулмаганлыгын, кияве Тарасның беренче көннән үк сугышка кереп, ранен булып, лазаретта ятканнан соң, тагын запасной частька китүен сөйләде. Шулай яшь килен белән, сөйләнә-сөйләнә эшне бетереп, өйгә кердек. Без өйгә кергәндә, барысы да үз эшләренә утырганнар иде. Әби дә кабасы кырында. Әбинең олы килене Зина җиңги чөлкә бәйли. Анюта җиңги дә кабасы төбендә эрләп утыра. Сандр бабай сәндерәдә ята. Өйгә керү белән, яшь килен Авдотья да, кабасын-орчыгын алып, эрләргә утырды. Тик мин генә бер эшсез калдым. Шунда кисәк кенә:

— Мәрьям, сиңа да эш бар. Җырлап җибәр әле бер, — диде Анюта җиңги.

— Җырлый беләме кызың? — дип сорады әби, көлеп кенә.

— Мәрьям грамофоннан уздыра ул, — диде Анюта җиңги.

Зина җиңги — салмак хатын. Ул бер сүзгә дә катнашмый иде, ул миңа күтәрелеп карады:

— Кунак кызының ят көйләре бардыр, тыңлыйсы иде, — дип куйды.

Үземне бу гаиләгә бурычлы дип санадым. Чыннан да, аларның үтенечләрен кире кагу урынсыз иде.

— Җырлауны бабай яратырмы икән? Олы кешенең тынычлыгын бозу булмасмы? — дип сорадым.

— Бабай яшь чагында үзе дә бик оста җырчы иде, — диде әби, көлемсерәп. Сандр бабай тамак кырып куйды.

— Әнә, эти дә синең белән кушылып җырларга әзерләнә, — диде Анюта җиңги. Аның бу сүзеннән барыбыз да көлеп җибәрдек.

— Дәрт юк түгел, дәрман гына юк, — диде Сандр бабай. — Әйдә, кызым,башлап җибәр. Мин бал эчкәндә генә җырлыйм, — диде. Мин әкрен тавышка сузып җырлый башладым. Авдотья да җырга кушылды. «Карурман», «Сакмар», «Лимонад» көйләрен бер-бер артлы җырладык.

Салмак табигатьле Зина җиңгигә дә безнең җырлау тәэсир итте.

— Бүген кич утыру күңеллерәк, — дип куйды.

Йокларга хәзерләнә башлагач, әби мине яшь килен Авдотья белән бер караватка ятарга кушты. Ул:

— Кешедән кеше ким булмый, барыбызны бер Ходай яраткан, — диде. Бу инде яшь килен Авдотьяга кимсенмәскә кушуы иде. Чөнки мине алар хәер сорашып йөрүче дип таныйлар. Җитмәсә, татар кешесе дә бит әле мин. Дин башка бит.

— Миңа идәндә ятсам да ярар, әби, — дидем мин.

Әби якын китермәде:

— Өстең-башың юылган, кеше чирканыр җиреңюк әле, — диде.

Анюта җиңги дә, аңа кушылып, чисталыгымны, тәрбиямне мактап алды. Шулай итеп, яшь киленнән качарга миңа юл калмады. Җитмәсә, әби болай дип тә өстәп куйды:

— Авдотья белән кочаклашып йоклагыз! Җылы булыр.

— Бик җылы булыр иде дә, минем арт ягым сыек шул, — дип уйланам. Паласка төренеп үк, стена кырына мин яттым. Юрганына бөркәнеп, миңа елышып Авдотья ятты.

Тар һәм юка күлмәгем эчендә чүбектән йомарлап ясалган ялган имчәкләрем урыннарыннан кузгалып, тәртипсез хәлгә килмиләр-килүен. Инде алар сыналган. Ләкин йомшак тәнле яшь киленнең миңа терәлеп үк ятуы, тәненең парлы җылысы тәнемә бер дә тынычлык бирми иде. Әле юньле-башлы ире белән сөешеп тә туя алмаган бит ул. Җилкенчәклеге белән ире кебек итеп кочып алса, мин нәрсә эшләрмен?

Йокламыйча, Авдотьяны саклап, төнне уздырырга мәҗбүр булдым. Авдотьянең кулы куеныма килеп керүдән сакландым. Ниһаять, татсыз гына бераз йоклап та алдым булса кирәк. Мин уянганда, әби иртән торып мичкә яккан һәм иртәнге чәйгә пешеренергә әзерләнә иде.

Урынымнан торып, тышка чыктым. Таң беленә башлаган иде. Кеше юклыктан файдаланып, лапастагы әрдәнәләр арасына кердем һәм Сандр бабайча, аягүрә баскан килеш печ итеп алдым. Моңарчы, күбесенчә, бу эшне мин хатын-кызларча үтәргә мәҗбүр була идем. Коедан су алып, улакка салдым һәм атларны эчереп, тагын да печән таратып кердем. Мин кергәч, йорттагыларның барысы да урыннарыннан торды. Сандр бабай да, торып, тышка чыгып керде. Ул:

— Кызым, атларны да туйдырып кергәнсең икән, рәхмәт, — диде.

— Көн бик әйбәт, бабай, печәнгә барабызмы? — дидем.

Бабай:

— Әллә чынлап та барыйк микән? — дигәч, Зина җиңги дә сүзгә кушылды. Ул салмак кына:

— Кышка кердек инде. Бураннар да булмый тормас. Көн яхшы чакта китереп калмасаң, кыенлашыр, — диде.

— Барабыз, бабай, барабыз, — дидем.

Әби:

— Мәрьям дәртләнде, Ходайның рәхмәте төшкере. Егетләргә биргесез нык кыз икәнсең, балам, — дигәч, куркып киттем.

Чәйдән соң мин, бабай, Авдотья өчәүләп, өч атны өч чанага җигеп, бастырыгын, тырма, сәнәген төяп, печәнгә киттек. Дүртенче көнне калган печәнне алып кайтырга бардык. Чаналарга гадәттән тыш авыр төядек һәм кайтыр юлга чыктык. Сандр бабай алда, уртада Авдотья йөге, иң артта минем йөк. Бүген җил дә каршы исә. Көн салкынрак та. Авдотьяның миңа кызыграк каравын иртән урыннан торгач та сизенгән идем. Ул иплән кенә сүз башлады:

— Сиңа бер сүз әйтәсем килә иде, ачуланмасаң, — ди. Үзе көлә.

— Ник ачуланыйм тагын. Әйт, — дидем, Авдотьяга туры карап. Ләкин үзем куркуга төшсәм дә, аңа белдермәскә тырышам. Яшь килен минем куркуга төшүемне сизенә бугай. Тагын да ныграк көлә. Минем йөземә ачуым чыкты. Ачуым да килә, куркам да. — Минем килешмәгән җирләрем күп булыр. Илдәге һәркемгә дә килешеп бетә алмам. Әйт тизрәк, минем сиңа кай җирем килешми? — дидем нык кына.

Авдотья һәнүз көлә. Ул:

— Килешмәгән җирең юк, ләкин шик бар синдә, — диде бу.

Аңымны югалта яздым. Үткән төннәрдә, печәннән бик арып кайтуым сәбәпле, Авдотьядан саклана алмадым. Бик каты йокладым. Мөгаен, ул мине тикшергәндер дип, бик курка башладым. Авдотья әйтә:

— Үткән төнне син бик каты саташып йокладың. «Җаным... Сара... Үпкәләмә!» — дигән сүзеңә уяндым. Нәрсә эшләптер, кулым синең куеныңа кергән. Синең имчәкләрең урыныннан кубып чыкканнар... Аптырадым. Әллә мин әйтәм, саташып, төшемдә шулай күрәмме дип кабат-кабат тикшердем. Һәнүз шулай. Кажется, ими урынында йомшак чүбек өемнәре бугай. Мин синнән бик курыктым. Калганын үзең сөйлә, — диде бу.

— Минем күкрәкләрем үсми. Мин аны форма өчен шулай ясап йөртәм. Гаҗәп, ник үсми ул? — дигән булдым.

— Ә күрем күрәсеңме? — дип сорады Авдотья.

— Белмим. Нәрсә була соң ул күрем? Ничек күренә ул? — дигән булдым.

— Син ничә яшьтә соң әле? — дип сорады хатын.

— Уналтыда бугай. Белмим мин ничә яшьтә булуымны.

— Гаҗәп, — диде Авдотья. — Шундый таза гәүдәле кыз уналты-унҗиде яшьтә генә буламы соң? Үзең гаҗәп көчлесең. Булыр-булмас егетләрне бәреп егарлык... Ә күкрәгең юк...

Авдотья кайткан шәпкә шулай сөйләнә. Сөйләгән саен аның шикләнүе һәм куркуы арткан кебек сизелә. Мин куркам. Авдотьяга нәрсә дип җавап бирергә сүз табып булмый. Кисәк кабынып, Авдотьяны әрли башладым.

— Син мине мәсхәрәлисең. Монда сезгә килеп торуымны күпсенәсең. Күпсенмә, Авдотья, мин сездә күп тормыйм. Иртәгә үк китәм. Бай килене булгач та, мине кимсетәсең. Мин инде эт кебек илдә йөрүче бер хәерче. Бәхетсез бер хәерче. Сез сугышта бары ирләрегезне генә югалтасыз. Минем бөтен язмышым һәм тормышым югалды. Һәркөнне илдә җылы почмак эзләп йөрим. Миннән шуны да кызганалар.

Авдотья йомшарды. Сүзләремне ул чынлап аңламагандыр да. Бу сүзләрне ничек уйлап тапканмындыр. Анысын үзем дә сизмәдем.

— Ярар инде, Мәрьям, үпкәләмә. Дөнья булгач, төрле хәл булыр, — диде.

Мин аның бу җавабының төпле икәнлеген аңладым. Авыл хатын-кызларының беркатлырак булуына ышана идем. Бу очракта шуңа таяндым. Монысы — бер булса, икенчедән, Авдотья ныклап шикләнсә, шунда ук: «Ир башың белән ни өчен хатын-кыз киемендә йөрисең? Мөгаен, син шулай кыланып, сугыштан качып йөрисеңдер?» — дип, минем якама ябышырга тиеш иде. Андый мәсьәләдә авыл халкы җебеп тормый. Алдашуны бер дә сөйми авыл кешесе. Үземне тыныч тотарга тырыштым. Иелгән башны кылыч кисми. Мондый чакта аяк астына җир кебек түшәлергә кирәк. Һичкемнең кәефен бозмау яхшы. Һаман тыйнак һәм намуслы кыз итеп күрсәтү юлында булырга тиеш идем. Үзеңне чакмаган елан мич башында кышласын, диләр бит. Бу фикерләрне сәфәргә керешкәндә үк башыма ныклап урнаштырган идем. Шуңа да Авдотья белән сүзгә килешкәндә: «Ай-һай ла, кәефен бозмасам ярар иде», — дигән уй йөрәгемдә генә торды. Ярар, печәннән кайтып җиттек. Авдотья минем белән дусларча булган кыяфәтен үзгәртмәде, киресенчә, ул да, мин дә бер-беребезне ныграк кайгырттык.

Кич утыру башлану белән, Анюта җиңгинең ишарәсе буенча, мин җырладым да, әкиятләр дә сөйләдем. Авдотья бу юлы, мине шикләндерү өченме, әллә миннән куркудан, читенсенепме, иң алдан Сандр бабай янына сәндерәгә менеп китте. Шулай итеп, бу кичне мин берүзем яттым һәм бик рәхәтләнеп йокладым.

Иртәрәк уяндым. Алдагы көннәрдә нишләргә? Киләчәк өчен үземә төрле юллар-ниятләр кордым, уйландым. Кичтән Сандр бабай базарга барачагы хакында сөйләгән иде. Мин дә аның белән базарга, рус-керәшен авылына, ягъни Анюта җиңгиләр авылына кире китәргә дигән карарга килдем. Шуннан станса ягына, руслар арасына китәргә кирәк, дигән фикеремне ныгыттым. Чөнки рус халкы татар халкыннан тартынучан булганга, миңа үз-үземне тоту җиңелрәк булыр төсле тоела.

Ярар, иртәнге чәй эчелде. Сандр бабай Авдотьяга ат җигәргә кушты. Ат җигешергә чыктым. Ат җиккән вакытта Авдотья белән сөйләшкәндә, мин аңа үпкәле сүзләремне әйттем. Ул да үзенең үкенгәнлеген белдерде.

— Гаепләп калма, җиңги. Мин киткәч, минем хакта шикле фикерләреңне оныт. Мин — илдә йөрүче. Бик усалларга да очрарга туры килер миңа. Сез — ак күңелле икәнсез. Сезнең хакта начар кеше дип бервакытта да уйламам. Рәхмәт сезгә. Бер атна мин сезнең белән үз туганнарым арасында торган кебек тордым, — дидем.

Авдотья чынлап йомшады.

— И, Мәрьям, — диде ул, — дөрес, мин әле бер дә дөнья күрмәгән шул. Тәҗрибәсезлегем аркасында, синең кәефеңне бозып, үпкәләттем. Бәхил бул, рәнҗемә миңа. Безне исеңә төшереп, тагын кил. Хәзер без таныш кешеләр бит инде, — диде.

Сандр бабай, сары толыбын киеп, чанага чыгып утырды.

— Мине дә көт, бабакай. Мин дә синең белән китәм, — дип, саубуллашырга өйгә кердем.

Рәхмәт сүзләре тезеп, саубуллаша башлагач, Анюта җиңги дә, әби дә гаҗәпкә калдылар. Анюта җиңги:

— Бәй, Мәрьям, әле китәсең дәмени? Тагы берәр атна торырга кирәк иде. Син киткәч, безгә бик ямансу булыр инде, — диде. Әби дә шуны кабатлады.

— Хуш, сау булыгыз инде. Рәхмәт сезгә, гаепләп калмагыз. Мине үз туганыгыз кебек күрдегез, — дидем дә, чыгып, Сандр бабай янына чанага утырдым һәм, дилбегәне тотып, кара алашаны чаптыртып чыгып та киттем.

— Безне исеңә төшереп, тагын да кил… — дип кычкырып калды әби.

***

Кара алаша — шәп йөрешле ат ул. Базарлы авылга тиз килеп җиттек. Сандр бабайның баҗасы Илья бабай да шушы авылда яши, базарга якын зур бер өйдә тора икән. Сандр бабай атны шулар капкасына борды. Өйгә кереп тормадык. Атны бәйләп куйгач, Сандр карт базарга юл тотты. Базар арасына барып кергәнче, аның белән сөйләнеп бардым. Сандр бабай базарга кереп китте. Мин Сараш дигән, ишетеп кенә белә торган бер татар авылына таба киттем. Чөнки шәһәр тирәсенә бару өчен, Сараш авылын үтмичә булмый.

Сараш авылына кадәр кырык чакрымлап атларга кирәк. Егерме чакрымы бояр урманы аша үтә. Шундый ерак юлга чыктым мин. Көн бик кыска. Кызурак атларга тырышам. Яктырак чагында урманны үтәргә кирәк. Базарлы авылны чыгып, ун чакрым баргач та, юл урманга керде. Мин хәзер урман эченнән барам. Биш чакрымлап чамасы киткән идем инде. Артымнан чанага утырган бер карт килеп җитте. Бу карт татар карты иде. Мөгаен, шул Сараш авылының татары булса кирәк. Бу юлдан башка авыл татарлары йөрми. Юл бер генә. Миңа тигезләшкәч, бабайның аты әкренәя төште:

— Бабай, бу юл Сараш авылына барамы? — дип сорадым бабайдан. Билгеле, иң элек исәнлек бирдем.

— Бара, кызым, бара. Нәкъ шул Сараш авылына бара, — диде бабай.

— Мине шул Сараш авылына кадәр утыртып алып бара алмассыңмы икән? Мин дә шунда бара идем, — дигәч, бабай киреләнеп тормады, шулай да бик үк риза түгеллеге күренеп тора иде. Тик кыз баланы урман уртасында калдырып китәргә намусы кушмый иде булса кирәк.

— Утырсаң, утырырсың инде, өстеңдә киемең бик юка. Туңмасаң, утыр, — диде бабай. Көн отыры салкынайта иде. Бабай кырыннан утырдым да, кулыннан дилбегәне алып, үзем тотып кайта башладым.

— Бабай, Сараш авылы еракмы әле? — дип сорадым мин.

— Һу-у, кызым, кырыктан унбишен генә кайттык әле. Юл мулдан. Тагын егерме биш чакрым кайтасы бар.

Бабайның аты болай көр күренә һәм бик дәрт йөри. Куганны кире кайтармый. Бабай минем ат тотып кайтуымны бик ошатты.

— Бик тернәкле кыз булып чыктың, шулай кирәк, кызым. Җебеп тору ярамый, дөньясы да шулайга таба бара бит әле. Ир балаларым булганчы, синдәй бер кызым булса, сугышка да китмәсләр иде...

— Ничә улың сугышта, бабай? — дип сорадым.

— Башка чыкканы белән өчәү киттеләр. Берсе действительныйдан кайтырга да өлгерә алмады. Өч улымнан берсе дә калмады. Үзем алтмыш сигез яшемдә, җитмештә — теге дөнья көтмештә... Башка чыккан киленем кара-каршы ике өйдә солдатка булып ялгызы калды. Карчык белән безнең янда тагын бер киленем бар. Малайларның хатлары килеп тора. Берсе инде ике тапкыр яраланырга өлгерде, лазаретта ята.

— Их, бабай, — дидем мин, көрсенеп. — Монда — ятимнәр, толлар, гарипләр, ачлар. Анда — кырылыш, җимерелеш, үлеш. Патша һәм генералларга көлке!

— Дөрес, кызым, бик дөрес. Син бик акыллы кыз икәнсең. Безнең күз яшебезне күрүчеләр юк. Ходайга гөнаһларыбыз бик күптер инде. Син, кызым, бик кыю икәнсең. Кайсы авылныкы буласың? — дип сорады бабай, ниһаять.

— Еракныкы, бабай. Кырчын дигән авылны ишеткән булсаң, мин шул авылныкы...

— Беләм, кызым, беләм, — диде бабай. — 1891 елгы ачлыкта симинәдән кайтканда, шул авылда тукталып, бер Әхмәт исемле кешедә чәй эчеп чыккан идек. Бик фәкыйрь тора иде бичара. Әле ул кеше исән микән, беләсеңме, кызым? — дип сорады бабай.

— Беләм, бабай, ул кеше хәзер карт инде. Малайлары үсеп, кул арасына керә башлагач, баеп та куйды. Хәтта урам буенда кибете дә бар инде. Ләкин өч улы берчә сугышка китте. Уртанчы улы бик укымышлы, рус школасында укыган иде. Сугышта үлгән инде, — дидем.

— Их дөньялар, — диде бабай. — Белмим, сугыш тиз генә туктамас. Беребезнеке дә кайтмас, болай булса. Карт көннәребездә ниләр күрәсебез бардыр? — диде бабай.

Мин дә, үз чиратымда, зарланырга булдым. Чөнки бабай да үз кайгысын гына сөйли бит. Миннән бернәрсә дә сорамый.

— Минем дә бердәнбер абыем сугышка китте. Әти дә, әни дә күптән үлгәннәр. Мине шушы абыем карап үстерде. Җиңги, абый сугышка киткәч, әти-әниләре йортына торырга күчте. Берүзем берничек тә тормыш итәрлек булмагач, кайда эш һәм җылы почмак табам, шунда көн күреп йөрим. Менә станса һәм шәһәр тирәсенә

барсам, рәтлерәк эш табып булмасмы дип, шушы якка килеп чыктым, бабай. Авылларда бер дә рәтле эш юк. Хосусан, кышлыкта шулай. Ашлык сугу дисәң, бер-ике көндә бетә. Малларга салам, көрпә булырлык суктылар исә, туктаталар. Калганын суктырмыйлар. Утын-печән китерү дә шулай ук, — дип зарландым.

— Итәгенә ут төшмәгән кешеләр дөньяда юктыр, кызым, — диде бабай. Шулай сөйләшеп кайта торгач, кич булды. Караңгы төште. Ниһаять, авыл өйләренең тезелеп торган ут яктылары күренә башлады. Юл буена түгелгән тирес-салам өемнәре арасына килеп кердек.

— Синең белән юл кыска булды. Кайтып җиттек бит, кызым, — диде бабай. Мин инде яңа, таныш булмаган кешеләр белән очрашуым хакында уйлана башладым. Авылның урамына кергәч, бабайга:

— Бабай, миңа кунып чыгарга бер яхшы фатир кирәк булыр. Безнең кебек илдә йөрүчеләрне кемнәр кабул итәр микән? — дидем.

— Үземдә кунарсың, кызым, хәзер ишле гаилә юк инде. Өйдәге килен белән әбиең дә мин. Бездә өч кенә җан. Кара-каршы таудай ике өем бар. Өйләрем дә киң, үзебезнең күңелебез дә бик киң. Мин дә дөньяны күп күрдем, — диде бабай.

Безне бабайның карчыгы белән йорттагы килене каршы алды. Бабайга өйгә керергә куштым. Атны үзем тугарырмын дип, чиннек каршысына илттем. Миңа әлеге яшь килен ярдәм итте. Атны тугарып, сыртын чыпта япма белән бәйләп куйдык. Килен мине өйгә алып керде. Бу өй аш өе иде. Бик җылы һәм парлы, шулай ук бик тәмле аш исе дә чыккан иде. Килен, ягъни Сабира җиңги, өс-баш киемнәремне салып, иркенләп, сәкедән урын алырга кушты. Ул җиңги болай төскә сазаган хатыннарга охшамаган. Бик яшь кыяфәттә.

— Кайсы якныкы буласыз, туган? — дип сорады Сабира җиңги йомшак тавыш белән.

— Кырчынны ишеткәнегез булса, шул якныкы, җиңги, — дидем мин.

— Ишеткәнем юк. Моннан ерактыр инде. Үзең кияүгә чыкмаган идеңме? Әллә киявең сугышка киттеме?

— Кияүгә чыкмаган идем әле. Нужалар шулай йөртә. Йөрергә калган баш, күрергә калган дөнья, — дидем.

— Шулай инде, туган, атаң-анаң да юктыр шул. Әллә сугышка киттеме әтиең?

— Бердәнбер абыем гына бар иде. Беренче чиратта ук сугышка китте. Хатыхәбәре дә юк. Җиңги әтиләренә торырга китте. Бер башым тормыш итәргә рәт калмагач, кайда нинди эш тапсам, шуны эшләп, якты чырайлы кешеләр мәрхәмәтендә шулай илдә йөрим...

— Мескен, үзең ни исемле буласың?

— Мәрьям.

Без шулай сөйләшеп торганда, әби килеп керде. Ул якты, көләч йөз белән миңа туры карап:

— Нихәл, кызым, ару гынамы? Туңмадыңмы? Аягыңдагы каткан чабаталарыңны чишеп, киптерергә куй. Киез итек киеп ал, — дип, миңа мич артыннан бер иске киез итек китереп бирде һәм килененә эндәште:

— Ашыңны җитештер, килен, атаң да намазын укып бетерә, —үзе аш урыны хәзерләргә кереште. Ул арада бабай да килеп керде:

— Нихәл, кызым, туңмадыңмы? — дип сорады.

Мин юлда кайтканга караганда юаш табигать белән җавап кайтардым:

— Туңмадым, бабакай.

Бабай, астына бер мендәр салып, түрдән утырды. Сабира җиңги аш китереп утыртты.

— Исемеңне белмим, якын килеп утыр, кызым, — диде әби.

— Мәрьям дип әйт. Мин сорадым инде, — диде Сабира җиңги.

— Мәрьям?.. — дип сорап куйды әби.

Аш эчтек. Ит тә ашадык. Аш вакытында сугыш хәлләре, хат килү-килмәүләре, һәлак булучылар хакында сүз барды. Аштан соң бабай яңа өйгә чыгып китте. Әби белән Сабира җиңги табак-савыт юдылар. Мин, базардан кайткач, бәйләп куйган атны искә төшердем.

— Ашка хәтле бабаң карады инде аны, борчылма, кызым, — диде әби.

Шулчакта бер бик матур йөзле, матур киемле, уртача гәүдәле хатын килеп керде, исәнлек-саулык сорашты һәм, әбинең кыстап торуын да көтмичә, сәкегә килеп утырды. Әби бу хатынга «Рәхимә килен», дип эндәште. Сабира җиңги «Рәхимә килендәш», дип эндәшә. Хәким бабайның башка чыккан улының хатыны икәнен чамаладым. Бу уем дөрес булды. Тагын шунсын чамаладым — Рәхимә шактый үткен хатынга охшаган иде.

Рәхимә җиңги башта миңа чирканып карады һәм мыскыллы тавыш белән сүз башлады:

— Боларда кунак кызы да бар икән әле, — дип, баш калкытырга бирмичә, минем хакта сорашырга кереште.

Сабира җиңги барын да сөйләп бирде. Сүзгә әби кушылып, мине мактап алды. Кемлегем хакында тәмам аңлап бетергәч, Рәхимә җиңги мине үз өенә өнди башлады.

— Ошатсаң, сугышлар беткәнче һәм үзеңне кияүгә биргәнче, бездә торырсың, — ди. — Ошатмасаң, тотмам. Миңа иптәш булып торырга теләүче кызлар бик күп. Шулай ук аларның кайберләрен мин үзем дә ошатмыйм. Өс-башыңны бөтәйтермен, тамагың тук булыр. Кемнең кем икәнен белгән юк, билгесез түмгәккә сөртенсәң, үпкәсе булмас, — дип куйды.

Әби белән Сабира җиңги дә Рәхимә түтине яклап, аңа керергә бик нык димлиләр, байлыгын да, юмартлыгын да әйтәләр.

— Олы улымның кәләше, олы киленем, уңган-булган, — дип кенә тора әби.

...Мин чынлап кайгыга калдым. Бу җиңги кулына төшсәң... Шиксез, шушы җиңги актык туемны итәр, дигән уй сызылып үтте. Җиңгидән йөземне һәм күземне яшерергә тырышам. Аның саен ул миңа кыюрак һәм турырак карый. Ниһаять, әби мине Рәхимә җиңгигә чыгарга күндерде.

— Әллә кайдан, күренмәгән бәхетне эзләмә, кызым. Ихлас күңелемнән әйтәм. Рәхимә җиңгәңнән дә әйбәтрәк урынны таба алмассың. Сине моңа хәтле белү түгел, күргәнебез дә юк иде. Юлда кайтканда, синең булдыклы бала булуыңа бабаңның исе киткән. Акыллы булуыңны да ул сынаган. Шунлыктан синдәй баланы без бик яратабыз һәм авыллар арасында забун булып йөрүеңнән кызганабыз. Сүземне тот, кызым Мәрьям! Кер хезмәткә Рәхимә җиңгәңә. Яратмасаң, ул сине көчләп тотмас. Эшләгәнеңә артыгы белән түләр, — диде.

Ахыры киләсе санда

ЧЫН ШАГЫЙРЬ ИДЕ

МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ

«Сарман» җыры — шушы планетада
Өзмәс-куймас сагыну җыры ул.
Нияз Акмал

СҮЗ ЕГӘРЕН ЙӨГӘНЛИ БЕЛҮ ТЫЛСЫМЫ — ТУМЫШТАН БИРЕЛГӘН БӘХЕТЕДЕР. ШИГЫРЬЛӘРЕ АША МИН АНЫҢ ЙӨЗ-КЫЯФӘТЕН, КҮЗ КАРАШЫН, ХОЛЫК-ФИГЫЛЕН, КҮҢЕЛ ТИБРӘНЕШЕ РИТМНАРЫН ТОЯМ.

Әдәбиятта, сәнгатьтә хак бәяне Вакыт бирә, дияргә яратабыз. Чынбарлыкта исә, вакытка сылтамыйча да, югары кимәлгә җиткән сәнгатьлелекне тоябыз, сизәбез бит: әсәрнең җене бармы, җаны бармы әсәрнең?! Бар икән — димәк, дога камиллегенә ирешкән сүзләр үрелеше вакыт хасиятеннән өстен биеклектә.

Ул — чын шагыйрь иде.

Туган телебезнең сыгылмалы байлыгын күңел бизмәнендә йөртеп, бу кырыс яшәештән матурлык, соклану, ачыну, уй-гамь тойгыларын чумырып алып, олы мәгънәләр таба белүендә аның Шәрекъкә хас борынгыдан килгән акынлык чалымнары бар.

Ул — илһамлы мизгелендә асмани катлардан Ходай пышылдаганны ишетә белгән сирәк шагыйрьләребездән иде. Чагыштырып карасаң, черки томшыгы чаклы гына фикер аулап, сүз чытырманлыгында өметсез чәбәләнгән шагыйрь кебекләр бихисап бездә. Ә ул — шигырь аланнарын киереп, изүен ачып, рәхәт җилдереп барган иркен сулышлы сүз остасы, сүз зәркәне иде.

Үз даирәдәгеләребез белән әңгәмә корганда искә төшерәбез дә... Һәркем күңеленнән аңа кагылышлы хатирәләрен барлый башлый. Кемдер бәгыреннән өзеп, әйтеп куя:

— Их, иртә китте... Нинди шәп шагыйрь иде бит!

***

Нияз Рәшит улы Акмалов 1954 елның 14 февралендә Сарман районы Каташ-Каран авылында укытучы гаиләсендә дөньяга килә. Быел аңа 60 яшь тулган булыр иде. Бер карганда, аны 60 яшьтә итеп күз алдына да китереп булмый. Кайберәүләр кебек ул иңенә ясалма олыгаю йөге салып, рухын бөгеп йөрмәде, ничек бар — шулай, табигый эчкерсезлегенә хыянәт итмичә, гел шулай яшь, шаян холыклы шагыйрь булып каласы иде дә бит... Замандашларының хәтеренә күчеп, ул шулай яши дә...

Казан дәүләт университетын тәмамлаганнан соң, ул төрле газета-журналларда эшләде. Кенәзләргә хас

Шагыйрь «Матбугат йорты» балконыннан шигырь сөйли. Туксанынчы – милли күтәрелеш еллары...

фамилияле бу егет белән миңа Бауман урамындагы «Ачык-китап» — нәшрият бинасында бер чорда эшләргә туры килде. Икебез дә икенче катта. Мин — Язучылар берлегендә, ул — Китап сөючеләр җәмгыятендә. Көнгә ничә тапкырлар очрашып, тәрәзә төбендә тәмәкедәшләр булып, фикергә-фикер, төтенгә-төтен кушып, күпме гәп корганбыздыр. Әмма ул, яшь шагыйрь буларак, «ә»гә «җә» дип кенә тормый. Үзе — эчкерсез, юаш та кебек, кайчакта «керпеләнеп» тә ала.

Саф шигырь генә сулап яшәгән әкә — яшьләрнең мэтры — Мөдәррис Әгъләмов та аны танырга мәҗбүр, безне дә узып китәргә мөмкин бит бу чукынчык, дигәндәй сагаебрак караса

Пакъ уйлар, ак кәгазь...

да, әдәбиятта төркемнәргә кушылып йөрмәгән бу ялгыз талантны санлый, чын шигърияткә омтылышына дәрт биреп, үсендереп тора иде.

Туган телебезнең бай хәзинәле, тәмле, каймаклы төбәгендә туып үскән егет, әлбәттә, «Сарман җыры» поэмасын язмыйча кала алмый иде. Бәгырьләргә кергән бу җыр аша ул татарның үткән юлларын урый: горурлана да, әрни дә, үзен шушы җыр ургылып чыккан төбәкнең хуҗасы итеп тә тоя.

Кайда татар — сагыну җыры шунда,
Кайда сагыну — «Сарман» шул якта.

...Җыры барда — халык мәңгелек тә,
Халкы барда — «Сарман» мәңгелек.

Инде акыннарга хас хикмәти тел белән яза белгәнен раслап, әдәбиятта ышаныч казангач, Нияз Акмал төрле жанрларда (проза, публицистика, балалар өчен маҗаралы язмалар) үзенә генә хас табышларын матбугатта укучылар хөкеменә чыгарды.

Кайчакларда ул кырысрак та булып ала, турысын бәреп әйтә, әмма гаделлек кысаларыннан чыкмый. Андый чакта мин болай дип шаярта идем:

— Их, Нияз дус, әткәң 63 чакрым уңгарак тарткан булса, син Сарманда түгел, ә Азнакайда туып, бөтенләй икенче кеше буласы идең бит, дим. Ул кайчакта көлә, кайчакта:

— Синең көнгә калудан Ходай саклаган, — дип куйган була.

Соңгы елларда гел шулай булды — күрешергә дип кулын сузганда:

— Беләм, әйтмә. 63 чакрым уңгарак кирәк булган, — дип үзе дә елмая, мине дә көләргә мәҗбүр итә иде.

Нияз Акмал һәрчак үзәктә булды. Тыңлый белә, хәленә керә белә. Корама телле күпме кулъязмаларны рәткә китереп, күпме вакытын, күз нурын сарыф иткәндер ул. Аксак телле каләмчеләрнең рәхмәте гел бер нәрсәгә кайтып кала. Нияз Акмал инде табынның күрке булып утырырга ярата. Саҗидә Сөләйманова, Кадыйр Сибгатуллиннарның шигырьләрен яттан сөйли башласа, әсәренеп, тын каласың. Әнә шулай, үзенә каратып, самавырны екканчы «сәйдәшләнеп» утыра иде ул. «Кадер» сүзен шигыренә дә әнә ничек кадерләп керткән бит:

Кадер барда күңел, әй, җылына,
Кадер юктан күңел күшегә.
Кадерлем, дип әйтсә иде дөнья
Кадерләрлек һәрбер кешегә.

Көндәлек матбугатта чыккан бер шигырьне укып, олы тәэсирләр кичергән, әмма авторының Нияз Акмал икәнен еллар үткәч кенә белә алган каләмдәшебез — Лениногорск шәһәрендә яшәп иҗат итүче Рәмзия Габделхакованың язмасыннан кайбер өзекләр китерик:

«Шатлыгымның чиге-чамасы юк. Шул ук кичне сөенә-сөенә китапханәгә йөгерәм. Нияз Акмалның китапларын күтәреп кайтып, төне буе укыйм. Минем өчен ифрат гүзәл яңа дөнья ачыла...

...Ахыр чиктә мин Нияз Акмалга хат язарга булдым. Ничә еллар буе мине елаткан-уйлаткан, күңелемне

Саҗидә Сөләйманова исемендәге премия бирү тантанасында. Сулдан уңга: Марсель Галиев, Илсөяр Ихсанова, Флёра Гыйззәтуллина, Равил Фәйзуллин, Рәмзия Габделхакова, Нияз Акмал

юаткан шул шигыре өчен Шагыйремә рәхмәт әйтәсем килде.

Мин аннан җавап килер дип көтмәгән идем. Ләкин ул язды. Аның хатын алгач, үземне күкнең җиденче катында итеп тойдым. Шигырьләре кебек үк җылы, ягымлы иде ул хат:

«Хөрмәтле Рәмзия!

Сезнең хатны алып укыгач, мин бик шатландым. Ул хат миндә яңадан да язу теләкләрен уятты. Чөнки күп көннәр гел башка авторларның язмасын әзерләп, газит мәшәкатьләре белән уза, үз шигырьләремә вакыт калмый.

Мин шигырьне аңлый алган, аңлый белгән кешеләрне бу дөньяда сирәк күрдем. Кайчандыр шулай, «Яшь ленинчы»да эшләгән чакта бугай, бер командировкага баргач, урта мәктәпне тәмамлаган укучылар мине район үзәгенә кадәр озата барган иде. Алар кичен шигырь кичәсендә булган икән. Шигырьнең кирәклеген, кадерен юл буе сүз белән түгел, гамәл белән аңлаттылар: шигырь укып баруымны сорадылар.

Менә Сездән хат алдым да әнә шул балаларны искә төшердем. Шигырь ул — чын йөрәктән чыккан шигырь — безнең өчен, шул яшәү мәгънәсен уйлаган кешеләр өчен бик кирәк икән бит!

Хат язуыгыз өчен дә, шигъри җанлы кеше булуыгыз өчен дә бик зур рәхмәт!»

2006 елда, сөекле шагыйрәбез Саҗидә Сөләймsecurityованың юбилеен үткәреп йөргән көннәрдә, без икебез дә, «Рухият» фондының кызыксындыру бүләгенә лаек булган идек, чәчәкләр күтәреп, сәхнәдә янәшә басып тордык. Бу — минем өчен чиксез горурлык. Әдәбият мәйданына миннән 20 ел алдан килгән, үткен, талантлы каләме белән гомере буе татар әдәбиятына, матбугатына хезмәт иткән Нияз Акмал да шат кебек иде...

Вафатыннан соң басылган хушлашу сүзләреннән укып кына белдем: әлеге кызыксындыру премиясе аның үз гомерендә алган иң тәүге бүләге булган, башка бернинди мактаулы исеме, дәрәҗәле бүләге юк та икән бит...»

Нәкый Исәнбәт һәм Мәхмүт Хәсәнов «Яшь Ленинчыда» кунакта. Н.Акмал беренче рәттә сулдан беренче. 1984 ел

Нияз Акмал — әдәбиятыбызның төрле жанрларында мәйдан тота алган олы каләм иясе. Прозада ул лирик повесть-хикәяләр иҗат итте, фантастик әсәр язып та шаккатырды, сатира-юморда да үткен каләм иясе икәнен раслады. Төрле композиторлар аның шигырьләренә онытылмас көйләр яздылар. «Тәрәзәңдә утың бар», «Күзләремнең төсе үзгәрмәде», «Казан каласында кар ява», «Соңгы кар», «Яшьлек болыны», «Тик бер генә карадың син миңа» җырлары әле дә халык күңелендә моңын җуймый яши бирә.

Шулай иҗат белән яшәгән шагыйребез Нияз Акмал Ходайның бер бирмеш көнендә... 2007 елның 11 августында вафат булды. Үлеменең сәбәбе (олыгаю яшенә җитә алмаган бик күп әдипләргә хас булганча) серле томанга өретелгән. Шул томанны тарата алмыйча гаҗизләнгәндә, бу кырыс дөньяга нинди матур уйлар белән килгән шагыйрьнең үз күңел язмасын тыңлап юаныч алыйк әле:

«...Менә шулай, мичтә янган учакка карап, сугыш турында сөйли, бездә фикерләү тойгысы уята иде әткәй. Аның сөйләгәннәренең тәэсире булдымы икән, сигезенче сыйныфта укыганда, мин «Ярлар һәм яралар» дип исемләнгән поэма яздым, аны Сарман район газетасында бастырып чыгардым. Бу поэма мине районга танытты. Аннан соң әле «Такташка җавап» исемле поэма да язып бастырдым мин район газетасында. Әмма бала чакта язылган шигырьләремнең берсен дә мин соңыннан чыккан җыентыкларыма кертмәдем. Бу, мөгаен, Казанга укырга килгәч, шагыйрьләр белән ныклап аралашкач, Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләмов кебек дусларымны тапкач, Саҗидә Сөләйманова кебек шагыйрәнең иҗатын яратып өлгергәч, шигъриятькә булган таләпләрем кинәттән үзгәрепартып китүдән булгандыр. Ә Такташка, Тукайга мин соңрак килдем. Аларга мәхәббәтне миндә кечкенәдән үк әнкәй тәрбияләде. Әнкәй аларны яттан белә иде. Ул аларны ятламый, әмма яттан белә иде. Аның бу гадәте (бәлки сыйфатыдыр) миңа да күчте. Әнкәй өчен Тукай, Такташ, Җәлил, Фатих Кәрим, Гадел Кутуй, Алиш — имән баганалар иде. Әнкәй минем район газетасында чыккан шигырьләремне укып бара, мактап та куя, әмма... шагыйрь булырымны күз алдына да китерми! Ул бик күп еллар узгач, бик картайгач, үзе дә шигырьләр яза башлагач кына, мине шагыйрь һәм язучы итеп таныды. Бу минем өчен иң зур бәһа иде!»

ӘДИПЛӘРЕБЕЗ МИРАСЫННАН

НИЯЗ АКМАЛ
(1954 – 2007)

Йөк атының абзар баганасына сөйләгәне

Син, багана, тыңлый беләсең шул —
Бу җәһәттән холкың-фигылең әйбәт.
Мине сиңа бәйләп куйдылармы,
Куйдылармы сине миңа бәйләп?

Ахмак, дияр берәү, баганага
Зарын сөйли, диеп көләр берәү.
Син, багана, минем күкләремне
Каплап торган түбәләргә терәү.

Син беләсең минем төннәремне,
Җиде кат тир исен, тире исен.
Күп нәрсәне беләсең син, дускай,
Күп нәрсәне ләкин син белмисең.

Син беләсең минем тәннәремдә
Төннәр буе мускул шыгырдавын:
Төшкә керә, таудай йөкне тартып,
Менеп барган чагым Шөгер тавын.

Хуҗам минем мәнсез бер зат булды,
Мәңге айный белмәс мужик сыман.
Урап кына үтеп китәр үрне
Менә бирде һаман турысыннан.

Үзе какты һаман дилбегәсен,
Чыбыркысын төшермәде кулдан.
Үргә куды — сазга илтеп тыкты,
Йөртәм, диеп, имеш, туры юлдан.

Юк, типмәдем түгел, сабыр беткәч,
Кушаяклап типтем тәртәгә мин.
Чыбыркылап ярды мине хуҗам.
Хәлсез яттым ничә мәртәбә мин.

Бәйгеләргә бүтән атлар китте,
Эш аты мин — булмый сатулашып.
Гомер үтте шулай, сарыкларга,
Дуңгызларга яшел азык ташып.

И багана!.. Мин бер колын булсам,
Син дә нәзек киртә булыр идең.
Тик синең дә язмыш: йә — бастырык,
Йә барыбер тәртә булыр идең.

Ачуланма, болай сөйләшергә
Өйрәндем мин шактый соңга калып.
Бар белгәнем — авызлык та тышау,
Татыганым — ыңгырчак та камыт.

Инде менә соңгы сәгать сукты...
Җибәр мине, зинһар, булма надан?!
Минем өчен синнән үч алмаслар,
Кем үч алсын синнән — баганадан?

Йөгәнемне салыр чаклар узган,
Кызган мине, зинһар, җибәрә күр?!
Син дәшмисең... Димәк, җибәрмисең?
Каян килде сиңа шундый мәкер?!

Җибәрмисең... Әйе, син — багана.
Холкың әйбәт синең, фигылең әйбәт.
Мине сиңа бәйләп куйдылармы,
Куйдылармы сине миңа бәйләп?..

Намуслы офицер турында баллада

Ул тумыштан асыл бер ир иде,
Офицеры иде Рәсәйнең.
Бүлмәсенә кереп бикләнде ул,
Һәм кычкырды: «Озак яшәдем!..»

Кичә аңа приказ килгән иде:
Үз халкына тиеш атарга.
«Юк, Россия! Моңа бармас иде
Денен сатып эчкән татар да!..»

Ул тумыштан затлы нәсел иде,
Ул ярата иде Ватанын.
Ул яшь иде. Ләкин ул аңлады
Үз илендә барган хатаның,

Үз илендә барган саташуның
Халык җилкәсенә төшәсен:
«Үз халкына кул күтәргән ирне
Бүре бусын, елан тешләсен!..»

Наганында алты патрон иде,
Аңа җитә иде берсе дә.
Ул көзгегә карый. Үзе елый,
Үзе көлә, үзе күрсенә:
«Хуш, Россия, китәм, каласың!
Үз халкына кул күтәргән ирне
Өегешкән этләр таласын!..»

Ул наганын куйды өстәленә.
Сыкрап әйтте: «Озак яшәдем...»
Фәхеш сөяркәсен кичерде ул,
Кичермәде ләкин Рәсәен.

«Һәрбер яуда артка типке алган
Гарип солдатларың култыклап
Син яшисең... Әллә кемнәр яши,
Шәрәләнеп калган арт саныңны
Бармак башы белән кытыклап,
Һәрбер ахмак синдә акыл сата,
Һәрбер надан — фикер иясе.
Хуш, Россия — ахмаклыклар иле,
Наданлыклар империясе!
Нәсел айгырлары көчли сине,
Син, Россия, кемнәр биясе?
Хуш, Россия — байбәтчәләр иле,
Гайбәтчеләр империясе!..»

Ул наганын куйды чигәсенә
Һәм кычкырды: «Озак яшәдем!..»
Барлык тарафларын гөрселдәтте
Акылыннан шашкан Рәсәйнең.
Тик Россия аны ишетмәде,
Бугазына көннең ябышып.
Каргаларның каргап каркылдавы
Күмеп китте наган тавышын...

*Нишләдең...**

Син моңлы күңел идең бит,
Мин моңлы күңел идем.
Син мондый түгел идең бит,
Гел мондый түгел идең...

Син якты күлем идең бит,
Зәп-зәңгәр күгем идең.
Нәрсә булды, нишләдең син,
Син мондый түгел идең?!

Син минем тамырларымда
Җыр булып ага идең.
Шулкадәр серле идең син,
Һәр таңда яңа идең.

Мин сиңа гашыйк идем бит
Сабый чагымнан бирле.
Ул мин ачарга ымсындым
Синдә яшәгән серне!

Син мине үсмер чактан ук
Биеккә дәшә идең.
Син шулкадәр якын идең,
Син гел янәшә идең.

Син минем күңел түрендә
Сулмас бер гөлем идең.
Син мондый түгел идең бит,
Гел мондый түгел идең!

Мин түгелме яшьлегемдә
Учак булып кабынган? —
Йөзләреңә сөеп баккан,
Күзләреңә табынган.

Мин сине чынлап яраттым,
Чын йөрәктән ышандым.
Инде син дә алдалагач,
Тагын кемгә ышаныйм?!

Син мине нигә ташладың
Эченә кыямәтнең?
Булганы бар идеме соң
Мондый ук хыянәтнең?!

«Аңлый белсәң — кичерәсең...»
Минме шулай язмадым?
Мин бит сине сөюемнән
Ваз кичәргә базмадым.

Сиңа бик нык рәнҗесәм дә,
Мин авыр сүз әйтмәдем.

---
* Шигырь матбугатта беренче тапкыр басыла. — *Ред.*

Синнән китәргә җыенып,
Минме кире кайтмадым?!

Бу кадәрле әрнүләрдән
Хәзер ничек бушаныйм?
Синең күзләр дә алдагач,
Инде кемгә ышаныйм?!

Сиңа кабат ышанырга
Минем соң хакым бармы?
Ничек мин сиңа ышанып
Калдырыйм якыннарны?

Мин, синең өчен үртәлеп,
Йөрәкне талдырыйммы?
Мин хәзер дусларны сиңа
Ышанып калдырыйммы?!

Бәхет кошы сунары, дип
Әйтимме хәзер сине?
Ахырзаман сыңары, дип
Атыйммы хәзер сине?!

Синме ул буып ташлаган
Өметләрнең исәнен?
Ходай шулай яралткан дип
Акланумы исәбең?

Синең өчен оялудан
Кара көеп яшимме?
Мин соң сиңа шушы көннән
«Монафыйк!» дип дәшимме?!

Син күзем нуры идең бит,
Җыры идең чишмәнең.
Йә, әйт, дөнья! Нишләдең син,
Нишләдең син, нишләдең?!

Син моңлы күңел идең бит,
Мин моңлы күңел идем,
Син мондый түгел идең бит,
Мин мондый түгел идем...

Әйбәт какты

Юкны сөйләмәгез!
Тормыш мине тукмамады,
Бары
Өстемдәге тузанымны какты.
Болай әйбәт какты —
Кулы тигән җирдән каннар акты...

Күптән инде...

Күптән инде үксеп елаган юк,
Күптән инде шашып көлгән юк.
Нәрсә булды, дуслар, нәрсә булды,
Нәрсә булды миңа — белгән юк?

Күптән инде җылы яңгырларга
Кочакларны җәеп кергән юк.
Күптән инде йолдыз санаган юк,
Күптән инде айны күргән юк.

Күптән инде язгы күкрәүләрдә
Ярга ятып учак яккан юк.
Күптән инде, күптән югалткан юк,
Күптән инде, күптән тапкан юк.

Бураннарда күптән адашкан юк,
Давылларга күптән тарган юк.
Күптән инде, күптән сайраган юк,
Күптән инде яфрак ярган юк.

Күптән инде янып ашыккан юк,
Мең үкенеп соңга калган юк.
Бер сокланып тыңлар дөреслек юк,
Бер ышанып тыңлар ялган юк.

Нәрсә булды, дуслар, нәрсә булды,
Нәрсә булды миңа — белгән юк? —
Күптән инде, күптән яшәгән юк,
Күптән инде, күптән үлгән юк.

Күптән инде күзләремне тутырып
Караган юк дөнья күзенә.
Сүз тидермим диеп яши торгач,
Күз тидердем мәллә үземә?!

Коткарыгыз мине, коткарыгыз
Тик бер генә көнгә булса да!
Сез аңларга тиеш минем хәлне —
Сезнең дә бит хәлләр шул чама... ■

ШӘРИФ КАМАЛНЫҢ ТУУЫНА 130 ЕЛ

КЕШЕ КИЧЕРЕШЛӘРЕНЕҢ РӘССАМЫ

ДАНИЯ ЗАҺИДУЛЛИНА,
филология фәннәре докторы, профессор,
ТР Фәннәр академиясенең баш гыйльми сәркатибе

2014 ЕЛНЫҢ 27 ФЕВРАЛЕНДӘ ЯЗУЧЫ, ДРАМАТУРГ, ЖУРНАЛИСТ, XX ЙӨЗ БАШЫНДА МИЛЛИ ТАТАР ПРОЗАСЫН ФОРМАЛАШТЫРУГА ЗУР ӨЛЕШ КЕРТКӘН ТАЛАНТ ИЯЛӘРЕНЕҢ БЕРСЕ – ШӘРИФ КАМАЛНЫҢ (ШӘРИФ КАМАЛЕТДИН УЛЫ БАЙГИЛДИЕВ) ТУУЫНА 130 ЕЛ ТУЛА.

Элекке Пенза губернасы Инсар өязе (Мордва Республикасының Рузаевка районы) Пешлә (Татар Пешләсе) авылында мулла гаиләсендә туып, кадим мәдрәсәдә укыган, төплерәк гыйлем җыю нияте белән башта Төркиягә, аннары Мисырга барган, ләкин матди як кысынкы булу сәбәпле, ике елдан кире Россиягә әйләнеп кайтып, Украинадагы күмер шахталарында, Каспий диңгезе буендагы балык промыселларында эшләгән Ш.Камал 1905 елгы революция чорында үз урынын татар милләтенә хезмәт итүдә дип таба. Инкыйлаби вакыйгаларны Петербургта татар мәдрәсәсендә мөгаллим булып каршылап, ул «Нур» исемле беренче татар газетасы редакциясенә корректорлык хезмәтенә урнаша һәм шушы газета битләрендә үзенең тәүге әдәби тәҗрибәләрен — мәгърифәтчелек рухында язылган шигырьләрен һәм публицистик мәкаләләрен бастыра. 1906 елда яшь авторның «Сада» («Аваз») исемле шигырьләр җыентыгы дөнья күрә.

Туган авылы Пешләгә кайтып, мәдрәсәдә балалар укытырга керешүе Ш.Камалга актив иҗат белән шөгыльләнә башларга мөмкинлек бирә. Ул күп укый, аеруча проза, М.Горький, А.П.Чехов иҗатлары белән кызыксына. Эпик жанрдагы беренче әсәрен — «Уяну» (1909) исемле хикәясен яза һәм аны Оренбургта чыга торган «Шура» журналына җибәрә. Озакламый хикәя басылып та чыга, укучылар арасында уңыш казана. Әдәбият мәйданында чын-чынлап каләм сынарга теләп, 1910 елда Ш.Камал гаиләсе белән Оренбургка күчеп килә, «Шура» журналы һәм «Вакыт» газета-

сы нәшриятында хисапчы, соңга таба редакция хезмәткәре булып эшли, үзен проза остасы итеп таныта.

Ш.Камал татар әдәбиятында XX йөз башы мәдәни яңарышын башлап җибәргән, психологик прозага нигез салган язучыларның берсе буларак күренекле. Бер яктан, үз чоры татар җәмгыятендәге төрле катлау, бигрәк тә хезмәт кешеләренең (сезонлы эшчеләр, балыкчылар, шахтёрлар), интеллигенция вәкилләренең яшәешен тормышчан картиналарда һәм образларда тасвирлап, язучы милли әдәбиятка өр-яңа темалар алып килә: татар кешеләренең читтә бәхет эзләве, сукбайлык, иҗтимагый авырлыкларның кеше язмышларын җимерүе шундыйлардан. Икенче яктан, татар прозасының формасы өлкәсендә башланган үзгәрешләр дә Ш.Камалның 1909-1910 елларда иҗат ителгән кыска хикәяләренә барып тоташа. Ул XX йөз башы татар әдәбиятына сәнгатьнең гади кешеләр күңелендәге матурлыкны, рухи байлыкның танып бетерү мөмкин булмаган тирәнлеген, кешенең тормыштагы һәр мизгелгә җылы мөнәсәбәт белдерә, ягъни бәхет кичерә алуын сурәтләргә тиешлеге хакындагы карашны алып килә, кешеләрнең катлаулы психологиясен, эчке дөньясын, рухи үзгәрешләрне, хәтта аң төпкелендә барган процессларны сурәтләү объектына әйләндерә. Эмоциональ-лирик моң, аз сүз белән бирелгән тирән мәгънә, композицион җыйнаклык һәм тыгызлык — әдипнең хикәяләренә әнә шул сыйфатлар хас. Тормышны тышкы детальләр, әйберләр, эш-хәрәкәт яссылыгында сурәтләүдән — кешенең эчке дөньясын, хис-фикер үсеш-үзгәрешен тасвирлауга күчү, шәхесне эш-гамәл һәм уй-омтылыш берлеге булган катлаулы характер итеп күрсәтә башлау милли сүз сәнгате өчен яңа мөмкинлекләр

Шәриф Камал. 1926 ел

Ш.Камал туган йорт. Пешлә авылы

ача. Моны без шулай ук Г.Исхакый, Г.Ибраһимов, Ф.Әмирхан кебек әдипләр иҗатында да күрәбез.

Хикәяләрендә кешеләрнең фаҗигасе яки күңел матурлыгы, рухи байлыгы яки бушлыгы хакында сөйләп, Ш.Камал һәр әсәрендә яшәешнең бер ягын ача. Аның геройлары — гади кешеләр, ләкин характер бирелеше ягыннан автор аларга бер төркемгә, сыйныф-катлау вәкилләренә хас сыйфатларны туплый, тормыш сынауларының иң авырларын үткәргән бу кешеләр хәлиткеч мизгелдә — тагын да җаваплырак сынауны кичкән мәлдә сурәтләнәләр. Әйтик, «Уяну» (1909) хикәясе тегермәндә эшләүче Муса һәм аның хатыны Гафифә образлары, аларның язмышы аша тормыш китергән авырлыкларны күтәрә алмауның ике моделен тергезә. Элек бай баласы булган Муса хәзер *«шәһәрнең читендә иң сәләмә, иң ярлы мәхәлләдә»*[1] яши. Язучы аның ни сәбәпләр белән бу хәлгә төшүен күрсәтми. Ләкин әлеге сынау Мусаны үзгәртә: ул эчүгә бирелә, язмышка үчен сөеп өйләнгән хатыныннан ала башлый, нишләгәнен белмәс дәрәҗәгә җиткән эрткычка әверелә. Иң соңгы сынау — үзе өчен бердәнбер кадерле кеше булган хатынын кыйнап үтергәнен белү — Мусаны акылдан яздыра. Гафифә исә сынауларны сабырлык белән кабул итә. Ире кыйнаганнан соң, елгага ташланырга җыенуы да аның хакына булып чыга (*«Ах, үләм инде, тынычланырсың…»*). Язучы бу вакыйганы Мусаның да, Гафифәнең дә фаҗигасе итеп сурәтли. Хикәяләү әле Муса хисләрен, әле Гафифә кичерешләрен тергезә һәм тормышның башкача булу мөмкинлеген искәртә. Хикәянең исеме Мусаның үзе кылган хаталарны аңлавы, мәхәббәтен югалтканлыгына төшенүе турында сөйли. «Уянган» Муса, үзенең вәхшилеге нәтиҗәләрен күтәрә алмыйча, акылдан яза. Г.Халит мондый финалны «гади кеше намусының явызлыктан, кыргыйлыктан өстенлегенә, аның вөҗдан уты сүнмәвенә, рухи матурлыгына ышаныч»[2] уятучы дип бәяли.

Ретроспекция ясап, язучы Муса һәм Гафифәнең яшь вакытларын, мәхәббәтләрен искә төшерә. Егет уйларында мәхәббәтне саклау мөһимлеге искә алына: *«Ниһаять, гыйшык… өйләнү… мәхәббәт… ух! Нихәтле зәвык, нихәтле сәгадәт иде! Әүвәлге икесе инде үткән… соңгысын гына кайтарып булмасмы икән?»*[3]. Хикәядә әһәмиятле символ буларак бирелгән, Гафифәнең якасыннан өзелгән сәдәфтөймә дә мәхәббәтнең өзелгән булуын искәртеп килә. Егетнең: *«Югалмасын, үзе килгәч, үзенә бирермен…»* — дип уйлавы мөнәсәбәтләрне тергезергә омтылыш булып аңлашыла. *«Муса, үбеп-үбеп, җан сулышы белән аның кулларын җылытмакчы була иде. Әмма куллар инде җылынмый иделәр»,* — дигән өлештә дә Мусаның күңелендә хатынына карата хисләрнең исән булуы белдерелә. Әмма төймә, яшьле күзгә охшап, Мусага гаебен искәртә, «Мусаның аңына фаҗигане бөтен тулылыгында җиткерә»[4]. Мәхәббәтен, иң якын кешесен, бәхетен, киләчәген югалтуы хакында сөйли. Шулай мәхәббәт категориясе хикәяне аерым кеше тормышы тарихыннан гомумән яшәеш кануны хакындагы тарихка әйләндерә. Кеше өчен иң кадерле хис — мәхәббәтнең бик нәфис һәм нәзберек икәнлеген, тормыш авырлыкларын күтәрә алмыйча, аны югалтуның

---

[1] Шәриф Камал. Сайланма әсәрләр. — Казан: Таткнигоиздат., 1954. — Б.7.
[2] Халит Г. Шәриф Камал. // Татар әдәбияты тарихы: Алты томда. Т.3: XX йөз башы. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1986. — Б.321.
[3] Шәриф Камал. Сайланма әсәрләр. — Казан: Таткнигоиздат, 1954. — Б.7.
[4] Бәширов Ф.К. XX йөз башы татар прозасы. — Казан: Фикер, 2002. — Б.153.

кешегә фаҗига булып чыгуын сөйли. Бер ясалган ялгышның, хатаның төзәтелә алмаганын укучы сызлануы объектына әйләндерә.

Шулай ук «уяну» халәтендәге геройлар язучының башка хикәяләрендә дә тасвирлана. «Буранда» (1909) хикәясендә, әтисенең коткысына бирелеп, әнисен рәнҗеткән Мостафаның, ялгышын аңлап, аны төзәтергә ашкынуы, ләкин улы ишектән кергән мизгелдә ананың бакыйга күчүе кебек үсә барган вакыйгалар, егет күңелендә кайнаган каршылыклы уй-кичерешләрнең тышта котырган буран белән янәшәлектә бирелүе сәбәпле, шулай ук фәлсәфи гомумиләшә. Ялгышлар кеше күңелендә тынычсызлык уята, аны кайгыга сала, диюче язучы шушы халәтне психологик анализ ярдәмендә барлык ваклыкларында укучыга җиткерә. Ялгышны аңлау — хәтер категориясе, үткәндәге аерым мизгелләрне искә төшергәндә хасил була. Ш.Камал геройларының матур омтылышлары да, хисләре дә искә төшерүләрдә күрсәтелә. Шулар аша язучы ясалган ялгышларның сәбәпләрен дә укучыга җиткерә. Хикәядә ул, һичшиксез, Мостафаның үзенә бәйле: әтисе исән вакытта кылган дорфалыкларыннан тыш, ул үлгәч тә, егет әнисе янына килеп гафу үтенми. Әлеге ялгышы Мостафаның холкына тәэсир итә, ана мәхәббәтеннән мәхрүмлек аның салкын, башкаларга ышанмый, аларга мыскыл итеп карый торган кеше булып формалашуына китерә. Андагы үзгәрү ноктасын тасвирлаганда, язучы иптәше Хөсәен исеменнән мондый бәя бирә: *«Һәрнәрсәгә мыскыл күзе белән карый, бер сүзгә дә инанмый, кеше сөйләгәнне тыңламый, үзе сөйләсә, кешедән көлә торган салкын һәм ян-елымсыз бер кешенең аптырау һәм оялуы чынлап кызык иде»*[5].

Шуның белән янәшә, язучы бу ситуацияне татар җәмгыятендә еш очрый торган әхлаксыз күренеш кебек шәрехли *(«Атаң мине сөрә...»)*. Символ буларак та, янәшәлек кебек тә урынлы кулланылган буран мондый күренешләрнең кешеләр күңелен дә, җәмгыятьне дә хаоска, куркыныч салкынлыкка, билгесезлеккә китерүче булуын ассызыклый. Хикәя ахырында әнисеннән исән вакытта гафу үтенеп кала алмаган, ләкин ялгышын аңлаган Мостафа шул халәттә кала. Соңгы җөмлә — *«Тышта буран һаман дулый иде»* — ялгышны аңлауның, уянуның тормышны үзгәртү өчен беренче адым гына булуын искәртә.

Аерым бер хикәяләрдә тормыш сынаулары кешенең аларны кабул итүенә бәйләп куелмый. Язучы яшәешнең кешеләргә зур авырлыклар китерүен күрсәтеп, татар җәмгыятендәге бәхетсезлекләрне милли проблема буларак аңлата. «Сулган гөл»дә (1909) 19 яшьлек Камәрнең ялгызлыгы көндәш өстенә карт ирләргә кияүгә бирелгән татар кызлары фаҗигасе кебек шәрехләнә. «Кычкырыш»та (1910) киленнәрнең — хатын-кызларның татар гаиләсендәге хокуксызлыгы игътибар үзәгенә куела. Фаҗигале күренеш белән янәшә, геройлар күзаллаган, хыялланган бәхет тә кечкенә детальләрдә сиземләнә. Әйтик, «Сулган гөл»дә Камәрнең рухи ялгызлыгына 13 яшькә кадәрге балачагы һәм шул вакыттагы өмет-хыяллары каршы куела, бәхеткә омтылыш, рухи яктан үзенә якын кеше белән аралашу ихтыяҗы кичерешләр агышы кебек сурәтләнеп, Г.Халит бик дөрес билгеләгәнчә, «бу кичерешләрдә үзен бәхеткә хаклы санаган олы җанлы герой дөньясының якты бер чите, тәрәзәчәге ачылып киткән кебек»[6]. Гади бер татар кызының рухи дөньясы, аның табигать, күкләр белән аралашу гүзәллеге язучы сурәтләгән фаҗигане

[5] Шәриф Камал. Сайланма әсәрләр. — Казан: Таткнигоиздат., 1954. — Б.12.

тагын да көчәйтергә ярдәм итә. Шундый ук алым башка хикәяләрдә дә күзәтелә. «Ата» (1910) хикәясендәге картаеп кына әти булган, ашлык абзарында эшләүче Корбангалинең улы туу белән бәйле хыяллары гади кешеләр яшәгән тормышның авырлыгын тасвирлауда катнаша, бер үк вакытта кешеләрнең, нинди генә кыенлыклар килүгә карамастан, бәхет кичерә алу мөмкинлеге турында сөйли.

«Сукбай»да (1910) читкә акча эшләргә китеп, авылдагы анасын, хатыны белән баласын, апасының гаиләсен бәхетсезлек чигендә калдырган Гали фаҗигасендә язучы, бер яктан, аның үзен гаепли: *«Ятькачтан бераз вакытка кадәр төрле кешеләр вә манзаралар аның күз алдына берәм-берәм генә килеп торалар да ахырда һәммәсе буталып китә… Менә заводлар, трактирлар, пивнойлар, ночлежный домнар, койма аслары, төрмәләр — һәммәсе бергә капма-каршык! Әнә аның иптәшләре җырлыйлар, көлешәләр, кычкырышалар, кыйнашалар, исереп, койма асларында ауныйлар…»*[7] . Шушы фикерне ныгытыр өчен, автор төкерек детале куллана: *«Бервакыт Гали, югары караган көе: —Тфү! — дип төкереп җибәрде. Авыз суының вак бөртекләреннән беразы үз битенә кайтып төште… Шуннан соң ул җиңе белән битен сөртте дә, йөз өстенә капланды вә үксеп-үксеп елый башлады…»*[8]. Аның ярдәмендә кешегә үзе кылганнарның нәтиҗәсен күрергә, кичерергә туры киләчәген сөйли.

Икенче яктан, язучы иҗтимагый сәбәпләрне дә ассызыклап үтә: *«Ул үзен җиңелгән, алданган кебек күрә вә әллә нинди генә катгый берәр сүз әйтәсе килә, кемнәрнедер бик кычкырып сүгәсе, орышасы, аларның залим икәнлекләрен күрсәтәсе килә иде. Тик кемнәрне сүгәргә кирәклекне билгеләп очына чыга алмый иде. Кемне сүгәргә?.. Ул җир азлыктан авылны ташлап китте. Заводка эшкә керде… Забастовка вакытында мастерны кыйнарга теләгән өчен аны ябып куйдылар. Менә төрмәдән чykканнан бирле инде ул эш таба алмый йөри. Өс-баш ертык, тамак ач…»*[9]. Әлеге өзек, туган җирләреннән китеп, башка мохиттә яшәү шартларына яраклаша алмаган татарлар бәхетсезлегенә дәлил булып яңгырый. Шуңа күрә дә хикәянең ахырында язучының оста каләме белән тудырылган табигать сурәте *(«Гали кояш чыгышына таба китеп бара… Тик, кояш чыгар алдыннан күренергә тиешле матур манзараны буран каплаган иде…»).* Галинең караңгы язмышына гына түгел, татар җәмгыятенең караңгылыктагы, билгесезлектәге киләчәгенә проекцияләнә.

Шушы юнәлештәге иң аяныч, фаҗигале хикәяләрнең берсе — «Козгыннар оясында» (1910) шулай ук туган җирләреннән аерылып, шахтада эшләүче татарлар көнитешеннән алып язылган. Эчүчелек, юктан кызык табып, мәгънәсез көлке оештырып яшәүче «козгыннар» Мәрьям белән Госманның — *«бер-берсенә бик якынлык хис итә»* торган ир белән хатынның — тормышын, бәхетен, өметләрен җимерә: Мәрьям суга батып үлә, бәхетсез Госман үзенең гаебен аңлаган хәлдә, билгесез тарафка юл тота. Язучы әлеге вакыйга ярдәмендә читтә акча эзләүче татарларның үз тормышларын да, башкалар тормышын да әрәм итүе хакында сөйли, бу юлның татарлар өчен мәгънәсез икәнлегенә укучының игътибарын юнәлтә.

---

[6] Халит Г. Шәриф Камал. // Татар әдәбияты тарихы: Алты томда. Т.3: XX йөз башы. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1986. — Б.321.
[7] Шәриф Камал. Сайланма әсәрләр. — Казан: Таткнигоиздат., 1954. — Б.40.
[8] Шунда ук. Б.40-41.
[9] Шунда ук. Б.40.

Ш.Камалның гасыр башында, бигрәк тә 1910-1913 елларда иҗат ителгән юмористик һәм сатирик хикәяләре шулай ук милли җәмгыятьтәге аерым күренешләр, характерлар, ситуацияләр хакында уйланырга мәҗбүр итә. Сыра эчеп, үз гомере өчен борчылудан башканы белмәгән Гайнетдин бай («Холера вакытында», 1910), мөгаллимдә үзенә көндәш күреп, әхлакка сыймас адымнар ясый торган икейөзле мулла («Авыл мөгаллиме», 1910), үзенең вазифасын да төшенмәгән депутат («Депутат», 1910) — көлү катыш фаҗигалелек ярдәмендә иҗат ителгән булулары белән әһәмиятле.

Ш.Камалның аерым бер хикәяләре кеше психологиясен яшәеш хакында гомуми нәтиҗә ясарлык итеп файдалана, язучы «мәгълүм бер халәте рухияне (психологик момент) эләктереп алып, шунда казыну, эзләнү юлы»[10] сайлый. Шундыйларның берсе — «Ике яхшы» (1910) хикәясе. «Бер хатирә дәфтәреннән» дип куелган әсәр мәхәббәт һәм хыянәт, гафу итү тарихын сөйли. Хикәяләүче-мин Зөһрә исемле кызга гашыйк була. Ләкин кыз башканы сөя, егетне мыскыл итә. Сөйгәне ташлап киткәнне белгәч, егет Зөһрә янына килә. Шунда кыз аңа: *«Син бик яхшы күңелле»*, — ди. Бу очракта егетнең яхшылыгы гафу итә алу сыйфаты булып аңлашыла. Яшьләр өйләнешәләр, кызның «яхшы»лыгы яратмаган кешесен бәхетле итү рәвешендә төгәлләшә.

Хикәя бер гаилә булып гомер уздыргач, картайган кеше авызыннан сөйләнелә. Ул картның фикер агышы кебек оештырылган. Шушы фикер агышы: *«Менә хәзер икебез дә картайдык, чәчләребез агарды, һаман бер-беребезгә иң сөйгән вә иң якын кешеләр булып гомер итәбез»*[11], — дигән җөмләгә кадәр килә, шушы фикерне расларга яки кире кагарга омтылып сөйләнә. Картның хәтеренә уелып калган, димәк, иң әһәмиятле берничә вакыйгага мөнәсәбәт, шул мизгелләрдәге кичерешләре бәян ителә. Балачакта кызның кулын учына алып, уңайсызлык кичерүе; гашыйк булу, кызга табыну, бәхетле чак; кызның кире кагуы — «хәрабә», аңсызлык вакыты; яратканын башка белән күреп, аннан мыскыл ителү — «ярым үлек» хәлдә булу; ташланган кыз янына барып, аны гафу итү. Ләкин кызны гафу иткәннән соң, яңадан ярату хакында сүз бармый: мәхәббәт инде «үлгән». Егет бары тик кызның үзен «яхшы» дип атавы хакында гына сөйли, киң күңеллелек күрсәтүе белән горурлана. Өйләнешү яки гаилә булып яшәү хакында да «хәтер»дә берни юк.

Шул рәвешле, хикәя мәхәббәт үлгәннән соң гафу итү, ике кешенең, ярату булмаган килеш, гомерләрен берберсенә багышлавы хакында булып чыга. Аның моңсу интонация белән сөйләнүе, хикәяләүченең берничә урында калкытып куелган эчке каршылыгы, һаман да «дөрес эшләдемме», дигән үкенечле сорау куя килүе, шул сорауга үзенең «сентименталь вә хыялый» булуын сәбәп итеп, аклану эзләве дә — шуңа дәлил. Кешенең хәтерендәге иң мөһим күренешләрнең үз хәтерләве тәртибендә, үзенең мөнәсәбәт белдерүе кебек язылып, хикәя укучыны аның язмышына фаҗига итеп карау баскычына күтәрә, фикер агышын күзәтеп бару шул фаҗигане аңлау ноктасына алып килә. «Аң агышы» хикәяләүчекешегә хакыйкать булып тоелган нәрсәләрнең шартлылыгын ассызыклый һәм укучыны фәлсәфи нәтиҗә чыгарырга этәрә: бер үк бәхетне ике тапкыр кичерү мөмкин түгел!

«Эч пошулы» (1912) хикәясе нәкъ шул схемада иҗат ителгән. Узганны хәтергә төшерү бүгенге халәт турын-

[10] Вәлиди Җ. Матбугат галәмендә // Вакыт. — 1914. — 2 ноябрь.
[11] Шәриф Камал. Сайланма әсәрләр. — Казан: Таткнигоиздат., 1954. — Б.36.

да башламда һәм ахырда сөйләү белән каймалап алынган. Биредә төзек сюжет та юк: әсәр, мозаика кебек, аерым бер күренешләрдән җыелган. Биш ел элек яшәгән шәһәргә кайтып, фатирда торган хуҗа картны очрату. Шул чакны хәтерләп, кечкенә кызлары Мәрьямнең яланаяк йөрүе һәм скрипка уйнаганны тыңларга керүен искә төшерү. Мәрьямнең хәзерге хәлен сорау. Шушы күренешләр хикәянең буеннан-буена тормышның пычрак, караңгы, күңелсез, түбән булуы хакында сөйләү белән үрелеп бара. Хәтта фатир хуҗасының гаилә тормышы, андагы үзара мөнәсәбәтләр дә тискәре бәяләнә: *«Мәгълүм вә туфрагыбызга ук сеңгән әчпошыргыч эшләр... Әлхасыйл, инеше, тавы, елгасы, чокыры билгеле иске бер басу...»*[12] Язучы шулай вакыйгаларны татар җәмгыятенә хас күренешләр итеп карарга юл күрсәтә.

Хикәядә егетнең Мәрьямгә гашыйклыгы, мәхәббәт хакында сүз бармый. Мәрьям — матурлык һәм сафлык символы. Беренче бәя болай яңгырый: *«Ул гүзәллеккә чумган мәгъсум бер бала иде әле»*. Яланаяк йөрү күренешен искә төшергәндә, хикәяләүче аны *«хикәяләр галәменнән килгән бер пәри кызы»*, дип атый. Скрипка уйнаган кичтә, хикәяләүче үзенең йоклап китүен һәм төшен искә төшерә. Төштә канатлы, очып йөрүче Мәрьям *«тереклекне мактый»*. Моңа хикәядә шактый урын бирелгән. *«Кояш вә айны, чәчәкләр вә гөлләрне, таулар вә урманнарны, кошлар вә былбылларны, елга вә диңгезләрне, кичә вә йолдызларны, тагын әллә ниләр, әллә ниләрне, очсыз-кырыйсыз мактый...»*[13]. Мәрьям — матурлыкның үзе, хыял, тормышның матур якларын күрергә мәҗбүр итүче идеал кебек тәкъдим ителә. Бу фикер хикәянең ахырында бирелгән фикер агышында тагын ике тапкыр калкып чыга: *«Ул» күкләрдә оча, ул — мәңгелек, ул — сер», «Мәрьям — мәгъсум, мөкатдәс рух ул»*[14].

Хикәянең ахырында *«Бу язу бер гостиницаның 13 нче номер бүлмәсендә табылган иде»*, дигән автор искәрмәсе бар. Әсәрнең исеме, «Эч пошулы» гыйбарәсе белән кушылып, ул тирән депрессиядәге кешенең башына килгән уйларын кәгазьгә төшереп баруы кебек уйланылган. Хикәягә салынган фәлсәфи фикер текстта да күпмедер чагылыш таба. Беренче ике җөмлә болай яңгырый: *«Күңел тели: бир куәт! Шул мең кат тапталып беткән чиркин тар кабыкны тишеп чыгыйм...»*[15]

Фәлсәфи планда, кеше үзе уйлап тапкан матурлык һәм изгелек идеалы кайберәүләр, яшәүдән өмет өзгәннәр өчен яшәешнең матур якларын күрергә, шәхесне томалап алган тар кабыкны ватарга ярдәм итә ала, диелә.

Шул ук вакытта хикәяне милли проблема яктылыгында уку мөмкинлеге бар. Хикәяләүче сафлык идеалы итеп сурәтләгән кызны, әтисе сүзләре белән әйткәндә, *«аздырдылар, мескенне»*. Әйтелеш рәвеше Мәрьям фаҗигасендә тирәлекне, җәмгыятьне гаепләрлек итеп уйланылган. *«Чиркин таш кабыкны тишеп чыгу»* — җәмгыятьтә билгеләнгән рамкаларны, кешелексез тәртипләрне җимереп, сафлыкка, чисталыкка омтылыш төсен ала. Хикәянең исеме — «Эч пошулы» — Ш.Камалның башка әсәрләрендә дә татар яшьләрендәге халәт кебек кабатлана. «Шәкерт» (1910) хикәясендә мәдрәсә тормышының мәгънәсезлеген, һөнәрсезлеге сәбәпле киләчәгенең томанлы булуын аңлаган Гомәрнең дә «күңелендә шулхәтле шигъриятсез бер эч пошу» оялаган. Бу үзенчәлеккә Г.Нигъмәти игътибар итә: «Ш.Камал

[12] Шунда ук. Б.116.
[13] Шунда ук. Б.119.
[14] Шунда ук. Б.120.
[15] Шунда ук. Б.115.

әсәрләрендә яратып бирелгән коллизияләрнең берсе — хыял белән хакыйкатьнең бәрелеше булып, моның нәтиҗәсендә матур, тәмле хыял һәм өметләр һәрвакыт җимерелеп, алар урынын әчпошыргыч, күңелне сыкраткыч, омтылышларны буучан чынбарлык ала»[16]. Әлеге гыйбарә алга таба татар прозасында тотрыклы төс алып, Ф.Әмирхан, Г.Рәхим, Г.Гобәйдуллин, Ә.Тангатаров, М.Хәнәфи һ.б. әсәрләрендә күзәтелә һәм татар җәмгыятенең кимчелекле якларын күреп тә, шуны үзгәртә алмау чарасызлыгын ассызыклый.

Ш.Камал тормышны төрле яклап, төрле төркем кешеләр очрашкан психологик әһәмиятле мизгелләр сәхифәсе кебек тергезә. «Курай тавышы» (1912) хикәяләүченең балачагындагы кайбер истәлекләрне яңартуы кебек язылган. «Ике яхшы»дагы кебек үк, биредә «яхшы» һәм «начар» сүзләре уйнатыла: *«Дәдәм мине ятатмый иде. Аның берничә мәртәбә: «Син, малай, яхшы булмассың!» — дигән сүзләре хәтеремдә. Мин моңа бик борчыла идем. Аулакка китеп елыйдыр идем. Башкаларның яхшы булып та, үземнең начар булачагыма күңелем әрни иде. Минем яхшы буласым килә иде. «Яхшы» булыр өчен нишләргә кирәк икәнлеген төрлечә уйлый вә аңларга тырыша идем.*

Хезмәтче Фәйзулла агайны дәдәм бер дә орышмый иде. Мин аны «Яхшыдыр ахрысы...» дип уйлыйм, ләкин нәрсәсе яхшы икәнлеген белә алмый аптырыйдыр идем» [17]. Аннары чәчүдәге бер көнне сурәтләп, язучы хезмәтченең «яхшы» булуын, кай ягы белән яхшы икәнлеген укучыга җиткерә: Фәйзулла иртә таңнан эшкә йөрергә мәҗбүр ятим баланы кызгана, аның хәлен җиңеләйтергә омтыла.

Ләкин, күп тә үтми, Фәйзулла үлеп китә. Нәтиҗәдә, Хәсән исемле кечкенә бу малай хезмәтчене үз хыялында әтиәнисе белән янәшә куя. Шулай итеп, хикәя кешедәге яхшылык турында, автор җәлли белү һәм мәрхәмәт күрсәтүнең яхшы кешегә хас сыйфатлар булуын ассызыклый.

Хәлиткеч мизгелләрне кичерүче, үз хәлләрен аңлау-төшенү халәтендә сурәтләнгән геройлар Ш.Камалга укучыны да «ачыш ясау бусагасына» бастырырга мөмкинлек бирә. Хакыйкатькә күзләре ачылган геройлар тормыш ситуациясен чишү юлларын таба алмый: морза улы Әсфәндиар Мохтаров, матди кысынкылыктан котылу юлы таба алмыйча, үзенә кул сала («Җимерелгән звонок», 1911), балаларына кирәксез икәнлеген төшенгән карт үлемне өмет итә («Бер картның тойгылары», 1910), кызы Газизәнең алданганын белгән ана йөрәге чыдамый — ул үлеп китә («Күңелсез эш», 1910), атасының үги ана җәбереннән үзен яклый алмавына төшенгән Нәфисә чыгып югала («Нәфисә», 1912). Язучы чарасызлык чигенә килеп җиткән кешене сурәтли, гадәти булмаган күренешләр ярдәмендә яшәеш кануннарын билгели. Шул ук вакытта гадәти булмаган ситуацияләр XX йөз башы татар җәмгыятенә бәя булып яңгырый. Җәмгыятьтәге торышны күп кешеләр язмышлары мисалында, төрле яклап сурәтләп, Ш.Камал аны чарасызлык чигенә җитү, дип белдерә.

Ш.Камал 1914 елны күләмле әсәр — «Акчарлаклар» повестен төгәлли. Ул язучы хикәяләрендә очраган күп кенә мотивларны мөстәкыйль сюжет сызыклары дәрәҗәсенә үстереп язылган. Вакыт ягыннан, Каспий диңгезенә эшкә килгән кешеләрнең бер сезон — җәй башыннан көзгә кадәр тормышларын колачлап алган повесть күп язмышлар, ялланып эшкә килергә мәҗбүр иткән сәбәпләр хакында

[16] Нигъмәти Г. Сайланма әсәрләр. — Казан: Татгосиздат., 1958. — Б.148.
[17] Шәриф Камал. Сайланма әсәрләр. — Казан: Таткнигоиздат., 1954. — Б.109.

җентекләп сөйләп, татарларның читкә эшкә йөрү хәрәкәтен тулы яктырта. Автор сурәтләгән геройлар — ярлылыкка түзә алмыйча, акча эшләргә килүчеләр. Ләкин алар арасында солдаттан кайтыр җире булмаганнар да (Хөснетдин), эчү аркасында гаиләсен җимергән мулланың балалары да (Гариф), бөлгән бай малайлары да (Фёдор Лашкарев) бар. Җир азлык акча эшләргә читкә куа, диюче автор бу кешеләрнең асылда бераз мая туплап, яңадан туган якларына кайтып дөнья көтәргә хыялланууын ачыклый. Ләкин повестьта сурәтләнгән сезон да, эшчеләрнең искә төшереп — ретроспекция ясап тәкъдим ителгән алдагы еллар вакыйгалары да бу хыялның тормышка ашарлык түгеллеген күрсәтә. Шул ук вакытта язучы читтә йөрүнең татар гореф-гадәтенә, әхлагына тискәре йогынты ясавы турында да сөйли: аракы эчү, карта уйнау, сугышу-талашу, пасха бәйрәмнәрен билгеләп үтү күренешләре шулай мотивлаштырылган. Бу яктан, Сафа җыры әлеге эшчеләрнең дөньяга карашын җыеп бәяләве белән әһәмиятле:

«Без эчәбез дә җырлыйбыз,
Акча бетсә, урлыйбыз.
Ходаем безгә шушылай язган,
Мулласыннан курыкмыйбыз...»[18].

Гариф белән Газизә мәхәббәте турындагы сюжет сызыгы да ялланып эшләүчеләрнең кабат татар авылларына кайта алмаячагына, шушы алдавыч тормыш белән яшәү дәвам итәчәгенә мисал булып килә. Газизәгә карата күңелендә җылы хисләр уянган Гариф, шулар иркенә буйсынып, кызга вәгъдә бирсә дә, әлеге вәгъдәнең тормышка ашмаячагы табигать сурәте аша сиздерелә. Бер тапкыр бу юлга бастыңмы — моннан котылу юк. Язучы читтә ялланып эшләүчеләрнең йортсыз-җирсез, өметсез, киләчәксез булуын ачынып сөйли. Бүгенге табыш хакында уйлау ераккарак күз ташларга мөмкинлек бирми. Газизәнең авылга кайтып эшләргә, дөнья көтәргә теләге булса да, Гариф гаилә корырга әзер түгел. Ш.Камал читтә бәхет эзләүнең милләтне инкыйразга китерә торган хәрәкәт булуын идея итеп күтәрә. Шушы фикерне ассызыклау өчен кертелгән канатсыз акчарлаклар метафорасы, аларның *«тонык һәм эчпошыргыч тавыш белән елаганга да, көлгәнгә дә охшашлы гыйгылдап-гыйгылдап»*[19] кычкырынулары автор сызлануы, экзистенциясе төсен ала.

Гариф һәм Газизә язмышына Ш.Камал «Таң атканда» романында әйләнеп кайта. Роман 1917 елның 6 октябре вакыйгалары белән башланып китә. Солдатларның Беренче Бөтендөнья сугышыннан качып кайтулары, вакытлы хөкүмәткә мөнәсәбәт, большевиклар идеяләренең таралуы хакында сөйләп, язучы аны власть Советлар кулына күчкән вакытка кадәр алып килә. Шушы кечкенә аралыкта карашлар бәрелешен, омтылышлар төрлелеген сурәтләп, Ш.Камал халык арасындагы таркаулыкны ассызыклый, большевиклар партиясенең системалы, максатчан эш алып баруын үзәккә куя. Читтә ялланып эшләүчеләрнең — Гарифның, Мохтарның — иң беренче чиратта, большевиклар идеясен эләктереп алуы билгеләнә. Алар чарасызлык чигенә җиткән үз тормышларын үзгәртү юлын бары тик шушы идеядә генә күрәләр.

Шәрәфи картка һәм Газизәгә терәк — большевик Мохтар Булатов романда үзәк герой буларак тәкъдим ителә. Язучы Мохтарның фикри өлгерүен күзәтә, моның сәбәпләрен тарихи ихтыяҗ белән генә аңлатмыйча, татар җәмгыятендәге патриархаль күренешләргә дә тоташтыра. Әйтик,

[18] Шунда ук. Б.233.
[19] Шунда ук. Б.241.

Мохтарның ире кыйнап үтергән апасы Хәлимәнең, аның кызы Фатыйманың язмышы шундыйлардан. Моннан тыш, язучы татар җәмгыятендә революция тудырган кайбер тарихи бәхәсләрне вакыйгалар тукымасына кертеп җибәрә. Шундыйлардан милли яки сыйнфый көрәш мәсьәләсенә кагылышлы дискуссия аеруча кызык. Җәмгыятьтәге бер төркем кешеләрнең фикерен белдерүче Нәгыйм Кәбиров болай сөйли: *«Гомумән алганда, татар милләте — үзенең тарихы, үзенең кара язмышы белән, гомумән, дөнья йөзендәге бөтен милләтләргә караганда артыграк җәбер, җәфалар, хәсрәт һәм кысынкылыклар, пришанлык һәм фаҗигаләр күргән бер милләт. Гомумән алганда, шушы сәбәпләр аркасында, ул, наданлык, фәкыйрьлек чокырына батып, башка милләтләрдән бик күп артка калган. Иң элек татар милләтен гомуми икътисади һәм мәдәни яктан тәрәккый иттерү һәрбер татар баласының бурычы хисапланырга тиеш. Бу эш фәкать милли-мәдәни мохтарият аркасында гына гамәлгә куелырга мөмкин…»*[20]. Яки мөгаллим Фазлуллин шулай ук: «Иң элек милләт аякка басарга тиеш. Шуннан соң социализм турында уйларбыз», — дип белдерә. *Аларга каршы Мохтар авызыннан әйттерелгән сорау («Ул кысынкылык, ул җәфалар, ул наданлыклар милләт дигән нәрсәнең бөтен катлаулары өлешенә тигез төшкән бәхетсезлекме?»*[21]), милли-дини мәсьәләне «мигрень» дип атау исә капма-каршы як позициясе буларак яңгырый.

Шәхси сюжет сызыклары шулай ук билгесезлектә төгәлләнә. Большевик Гариф сугыштан Петроградка китеп бара. Газизәнең сугыштан яраланып кайткан ире Төхфәт үлеп китә. Ләкин романның исеме — «Таң атканда», символик мәгънәгә ия булып, киләчәкнең якты булачагына өмет уята.

Шулай итеп, Ш.Камал иҗаты гасыр башы татар прозасына бик зур йогынты ясый, реалистик яки романтик сурәт тукымасына психологик анализ үтеп керүне тәэмин итә. Татар прозасының шәрыктан килгән форма үзенчәлекләрен — лириклыкны, табигать белән кешене янәшәлектә сурәтләүне, кешенең хис-кичерешләрен, омтылышларын, хыялларын, фикер үсеш-үзгәрешен тасвирлау аша тормышка бәя бирүне, символик һәм метафорик сурәт тудыруны, тирәлектәге үзгәрешләрдә кәефхаләт көчешен тергезүне үстереп, бу иҗат аларның XX гасыр буе милли әдәбиятта кулланылышын тәэмин итә.

Ш.Камал татар әдәбиятына яңа темалар, милли мәдәният моңа кадәр игътибар итмәгән катлаулар тормышын алып килә. Кеше концепциясе ягыннан иң авыр сынауны кичү мәлендә сурәтләнгән геройлар шәхес күңеленең чиктән тыш матурлыгын яки түбәнлеген тасвирлап сискәнергә мәҗбүр итә. Тормыш-көнитеш күренешләре Ш.Камал әсәрләрендә һәрчак яшәеш, кешенең хата-ялгышлары, аларның кеше холкына, киләчәгенә, язмышына тәэсире хакындагы гомумиләштерүләргә алып килерлек итеп сайлана. Мондый тирәнлеккә ирешү өчен, психологик анализ, символлар, ишарәләр ярдәмгә килә. Автор идеалны геройларның хыялөметләрендә генә таба, тормышны исә шул өметләрне җимерүче, иҗтимагый һәм мәдәни чикләүләр белән шәхеснең олы җанын вакларга әзер авырлык, шулай ук сынау кебек аңларга юл күрсәтә. Шушы сынау язучыга кеше җанының, аңының, күңеленең чиктән тыш тирән, фаҗигаләргә дә, матурлыкка да сизгер, нәзберек, бай булуын тасвирлау мөмкинлеге бирә. ■

[20] Шунда ук. Б.325.
[21] Шунда ук. Б.326.

ХАЛЫК МЕДИЦИНАСЫ ЯДКЯРЕ

КАН АЛДЫРУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

АЙДАР ГАЙНЕТДИНОВ,
филология фәннәре кандидаты,
Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының
Музыкаль һәм язма мирас үзәге фәнни хезмәткәре

БОРЫНГЫ ЧОРЛАРДА ҺӘР ХАЛЫК, ШУЛ ИСӘПТӘН ТАТАР ХАЛКЫ ДА, КҮПТӨРЛЕ СЫНАУЛАР АША ҮТКӘРЕП, БИХИСАП КҮП ДӘВАЛАУ ЧАРАЛАРЫН ГАМӘЛГӘ КУЯ. ШУЛАЙ ИТЕП, ХАЛЫК ҮЗЕ БУЛДЫРГАН, ҮЗЕ ТУДЫРГАН ХАЛЫК МЕДИЦИНАСЫ БАРЛЫККА КИЛӘ.

Халык дәвалаучылары үз эшләрен бик яхшы белеп башкарган. Алар шулай ук һәртөрле авыруларны дәвалау ысулларын һәм алымнарын да яхшы белгән һәм үзләре булдыра алган кадәр бик күп авыруларның барлыкка килүенә һәм таралуына каршы көрәш тә алып барган. Бик күбесенә бу өлкәдә медицина буенча язылган һәм басылган шәрык телләрендәге китаплардан — Әбү Гали Сина, Әл-Бируни һ.б. борынгы галимнәрнең хезмәтләреннән укып алган гыйлемнәре булышкан.

Күп кенә дәвалану ысуллары татарларга ислам дине аркылы да кергән. Моңа бер мисал итеп кан алдыру белән дәвалануны китерергә мөмкин. Чөнки Мөхәммәд пәйгамбәр үзенең кайбер хәдис-шәрифләрендә аның хакында телгә ала. Мәсәлән, «Иң яхшы дәвалану чараларының берсе — кан алдыру» (Бохари һәм Мөслим риваятьләреннән). Икенче бер хәдистә Мөхәммәд (с.г.в.): «Мин күккә ашканда, күкнең һәрбер баскычы саен: «Әй Мөхәммәд, үзеңнең өммәтеңә кан алдырырга куш», — дигән сүзләрне ишеттем», — дип әйтеп калдырган (Ибн Маҗә риваятеннән). Шуңа күрә пәйгамбәр заманында да авыруларны шушы ысул белән шифа кылганнар.

Кан алдыруны икенче төрле «хиҗама» дип тә йөртәләр, чөнки Мөхәммәд галәйһиссәлам аны нәкъ менә шулай атый. «Хиҗама» исә «хәҗем» сүзеннән алынган һәм ул гарәпчә «суыру» дигән мәгънәне аңлата.

Хиҗама — кан алдыру, төгәлрәк әйткәндә, начар канны чистарту. Ул тире катламын тишеп, тәндәге оешкан начар канны суыртудан гыйбарәт. Әлеге алым бик борынгы заманнарда ислам динендә булмаган халыклар арасында да, мәсәлән, Кытай медицинасында киң кулланылган.

Татар халкында кан алдыру белән дәвалану һәрвакыт киң таралышта булган. Ләкин, кызганыч ки, инкыйлабтан соң бу дәвалау төре кулланылмый башлый, югала, онытыла. Фәнни медицина алга киткән саен, аеруча совет чорында, халык медицинасы белән сихәтләндерүгә шикле караш аны тормышыбыздан кысрыклап чыгара. Та-

тарлар соңгы елларда гына бу борынгы дәвалау ысулына яңадан мөрәҗәгать итеп, аның тән һәм рухи сәламәтлек өчен кыйммәтен аңлап, куллана башладылар.

Кан алдыру күп сырхаудан шифа булса да, ул авырган очракларда гына түгел, ә чирне кисәтү, организмның гомуми эшчәнлеген яхшырту ниятеннән дә эшләнгән.

Мондый төр дәвалау чаралары күп гасырлар дәвамында халыкның сәламәтлеген саклап килгән. Шуңа күрә халык медицинасының, шул исәптән кан алдыру кебек дәвалау ысулларының, хәзерге медицина фәне үсешенә керткән зур өлешен күрергә һәм бәяләргә кирәк.

Кан алдыру элек-электән татарларда киң таралган булган, археологик казылмалар вакытында табылган операция кораллары моны исбатлый торган дәлил булып тора. Еш кына мәчетнең имамы дини вазифалар гына үтәп калмыйча, кешеләрне дәвалау белән дә шөгыльләнгән. Хиҗаманы ирләргә мулла үзе ясаса, хатын-кызларны абыстайлар дәвалаган.

Татар халкында кан алдыруның таралган булуын күп сандагы борынгы кулъязмалар да раслый. Аларның бер өлеше Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана. Шуларның берсе — 2008 елда мәшһүр татар галиме М.И.Әхмәтҗанов тарафыннан Казан шәһәрендә табылганы 39 нчы фонд, 7067 нче шифр астында теркәлгән. Кулъязманың төгәл датасы куелмаса да, палеографик билгеләре буенча аның XIX гасыр уртасына караганлыгын чамаларга мөмкин. Кулъязма — борынгыдан килгән текстның күчермәсе.

Ни кызганыч, текстта язма авторының, күчерүченең исеме, күчерелү урыны һәм вакыты күрсәтелмәгән. Ләкин кәгазендә җитештергәндә куела торган штемпеле бар: «Успенской / Н.П. / Фабрики». Библиограф, тарихчы С.А.Клепиков фикеренчә, бу фабрика 1864-1867 елларда кәгазь җитештергән. Андый штемпельле кәгазьләр барысы да шул елларга карый[1].

Кулъязма китапның үлчәме: 17,5х11 см, текстының үлчәме: 14х7,5 см. Һәр биттә 13әр юл, язмалары имән кайрысыннан ясалган көрән төстәге каралар белән язылган. Кустодлары даими күрсәтелеп барылган. Китапның тышы каты кәгазьдән булып, аксыл көрән төстәге киндер тукыма белән тышланган.

Әлеге кулъязма безгә татар халык медицинасына караган мирасны барларга ярдәм итә. Аның эчтәлеге белән укучыларны да таныштырып үтәргә булдык. Текст хәзерге телгә яраклаштырып бирелә.

БУ БҮЛЕК КЕШЕДӘ ХАСИЛ БУЛГАН АВЫРУЛАРНЫҢ СӘБӘБЕН ҺӘМ БИЛГЕЛӘРЕН БӘЯН ИТӘР[2].

Әгәр бер кешенең авыруы кан күп булудан исә, билгесе шулдыр ки, гел йокысы килер һәм еш иснәр. Кан тамырлары киңәеп, гәүдәсе авыраер, авыз эче татлы булыр, борыны канар, бетчәләр чыгар, бите һәм теле кызыл булыр, төшендә кызыл нәрсәләр күрер, кыяфәте кайгылы булыр. Күп очракта моның дәвасы кан алдырудан булыр. Аны ваемсызлык күрсәтмичә дәваларга кирәк.

[1] Клепиков С.А. Филиграни и штемпели на бумаге русского и иностранного производства XVII-XX вв. — М.: Изд-во Всесоюзной Книжной палаты, 1959. — С.109.

[2] Тәкъдим ителә торган текстны медицина буенча кулланма буларак түгел, ә бары тик халык медицинасы ядкяре, милли мирасыбыз дип кабул итүегезне сорыйбыз. Канны табиб киңәше белән бу өлкәдә махсуслашкан учреждениеләрдә генә алдыру рөхсәт ителә.

Шулай ук авыруының сәбәбе үт сыекчасы күп булудан исә, аның билгесе шулдыр ки, авыз әче әче булыр. Бите һәм күзе сары булыр, кәефе төшәр, бәвеле сары булыр, төшендә сары нәрсәләр күрер. Аны дәваларга кирәк.

Шулай ук авыруының сәбәбе какырык күп булудан исә, аның билгесе шулдыр ки, авыз яры зур, зәгыйфь булыр. Гәүдәсе авыр һәм дәртсез, селәгәе сары булыр һәм акрынлык белән чыгар. Төшендә сулар, яңгырлар һәм суыклар күрер, гәүдәсе суык булыр, бәвеле куе һәм ак булыр. Аның гәүдәсен дәваларлар.

Шулай ук авыруының сәбәбе һәм авыруы кара үт суы күп булудан исә, аның билгесе шулдыр ки, адәм зәгыйфь, ябык булыр, аннан гәүдәсе, бите кара булыр, йокысы килмәс, каны кара һәм куе булыр, гәүдәсендә күп каннар булыр, төшендә куркулы караңгылыклар күрер, бәвеле кызыл, куе һәм карарак булыр. Инде аны ваемсызлык күрсәтмичә дәваларга кирәк. Әгәр дәваланмаса, ахырдан вафат булырга мөмкин.

ДӘВАЛАУ

Бу бүлек яз һәм кыш көннәрендә кан алдыру белән дәвалауны бәян итәр.

Инде кешегә яз һәм кыш көннәрендә кан алдыру тиешледер. Эчйомшарткыч нәрсәләр эчеп, эчне бушандырырга кирәк. Әмма күп хәрәкәтләнмиләр һәм мунчага еш керүдән саклананалар.

Җәй фасылында күп хәрәкәтләнмиләр, күләгәләрдә рәхәтләнеп ял итеп утырырга кирәк. Ләкин гәүдә кыздыручы нәрсәләр ашамаска, яшь җимешләрдән кыяр, карбыз кебекләрне ашап, бер микъдар баллы эчемлекләр эчәләр, болар файдалы булалар. Әгәр суга керергә туры килсә, ачы ризыктан саклананалар һәм алар белән күп мавыкмыйлар.

Күзләрне суык су белән юмыйлар, артык суык су эчмиләр. Башны суыктан сакларга, иртә һәм кич аны ачык тотарга кирәк, шулай итеп салкын тию һәм томау төшүдән саклананалар. Җимешләрне күп ашаудан, мунчага кереп, суга күмелүдән саклананалар.

Кыш көннәрендә гәүдәне каплап бетерми торган киемнәр кимиләр, суык тота торган киемнәрдән, каты чирләрдән саклананалар. Әмма башка ризыкларга, мәсәлән, арыш шулпасы, кишер, шалкан һәм башка нәрсәләргә өстенлек бирәләр.

БУ БҮЛЕК КАН АЛДЫРУ БЕЛӘН ДӘВАЛАУНЫ БӘЯН ИТӘР.

Инде мәгълүмдер ки, суык көннәрдә һәм суык табигатьле кешеләрдән кан алу ярамас. Көчне зәгыйфьләтә һәм гәүдәне авырайта торган мунчаларда күп утыру хатадыр. Һәртөрле дәвалауны кешенең табигатенә карап билгеләрләр. Шулай ук кан алуны шул рәвешле эшләп, бер яшеннән ундүрт яшенә хәтле кан алдырмыйлар, аннан алтмыш яшеннән соң алдырмыйлар.

Кан алдыру тәнне тулысынча чистартудыр, ләкин хатасы юктыр. Күбесенчә, яхшы остаз булмыйча, кан алдырмыйлар, чөнки кеше һәлак булырга мөмкин. Әмма кан алдыруда хата юктыр.

Әгәр баштан кан алдырсалар, билгә хәтле булган бөтен җирләрдәге авыруларны бетерү өчен файдалы булыр. Әгәр биленнән кан алдырсалар, аякларына кадәр һәм алардан югары өлешләргә файдасы булыр.

Кан алдыру тиешле булган хәлдә, яз көннәрендә исә иртәнге вакытта, кыш көннәрендә исә төш вакытында алдырырга кирәк. Болай эшләгәндә, файдасы күп була.

Әгәр бер кеше айның уналтысында кан алдырса, аның тәнендә булган чуаннары юкка чыгачак.

Унҗиденче көнендә алдырсалар, ул

кеше бернинди авыруларны белмәячәк, Аллаһ рәхмәте белән.

Унсигезендә алдырсалар, гәүдә сызлауларыннан котылачаклар.

Унтугызында алдырсалар, паралич чиреннән котылачаклар һәм аның белән башка авырмаячаклар.

Егермесендә алдырсалар, йөрәкнең ритмы бозылуын һәм йөрәк авыруын белмәячәкләр.

Егерме берендә алдырсалар, йөрәк авыруын белмәячәкләр.

Егерме икесендә алдырсалар, авыздан килгән начар исне бетерер.

Егерме өчендә алдырсалар, күз күремен яхшыртыр һәм күз чирләрен бетерер.

Егерме дүртендә алдырсалар, нервлар белән бәйле авыруларны белмәячәкләр.

Егерме бишендә алдырсалар, төрле куркулардан һәм көлкеле фикерләрдән арынырлар.

Егерме алтысында алдырсалар, барлык шешләрдән котылыр һәм югары температураны төшерер.

Егерме җидесендә алдырсалар, акылны һәм зиһенне яхшыртыр.

Егерме сигезендә алдырсалар, бөтен гәүдәгә көч-куәт бирер.

Егерме тугызында кан алдырмыйлар.

Инде һәркем айның уналтысыннан алып егерме тугызынчы көненә кадәр кан алдырса, югарыда әйтелгән тәртип буенча эшләсә, бик күп файдасын күрәчәк. Әгәр һәр айның башыннан уртасына хәтле кан алдырсалар, һәр көндә бер авыру һәм чир пәйда булыр. Әгәр һәр айның уналты көненнән тәмам егерме сигезенче көненә кадәр һәр көннең үзенә хас файдаларын алачагы билгеләнгәндер.

Кан алдырудан соң, ул көнне тозлы нәрсәләр ашамыйлар, чөнки авыру барлыкка килер. Әгәр бер кешенең кан алдырган вакытта хәле начарланса, аңа кан алыр алдыннан бер микъдар шәраб эчәргә кирәк. Бу очракта шәрабның төрле сортлары тәкъдим ителә. Әгәр кан кара төстә килсә һәм ул кеше зәгыйфь исә, кан алдыруны туктату кирәктер. Баш тамырын «кыйфал» дип атыйлар. Аннан кан алдыралар, чөнки муеннан югары җирдән алу авыруны бетермәс.

Гәүдә тамырыннан аста булган тамырны «басыйлык» дип атыйлар. Әгәр аннан алсалар, муеныннан аста булган гәүдә арыр, шул тамырны «әлхәл» дип атыйлар. Аннан алсалар, шулай ук гәүдә аякка хәтле арып, пакь итеп авыруны бетермәс.

Кан алдырганнан соң, бер-ике данә җимеш ашыйлар һәм бер микъдар шикәр ширбәтен эчәләр.

Итле ризыклар ашасалар, файдасы барлыгы тикшерелгән.

Кан алдырырга теләмәгән кешеләрдән һәм кече яшьтәге балалардан кан алдырмыйлар.

Җенси мөнәсәбәттә булган, мунчага кергән, җиңел яки бик зәгыйфь булган кешеләрдән кан алмыйлар, чөнки бу — хатадыр. Әҗәле якынлашкан кешегә сак булырга кирәктер.

Колак артында булган тамырны халык «әләзән» дип йөртә. Әгәр аннан кан алдырсалар, авыруларны бетерә, колак эчендә булган чирләрне бетерә һәм талак авыртканда файдалы, бу инде тикшерелгән.

Ике ирен урталарында ике тамыр бар, аларны «горук әл-шәфәтәйн» дип атыйлар. Инде әгәр алардан кан алдырсалар, теш итләрен сәламәтләндерер һәм ирен җәрәхәтләрен бетерер.

Шуны да әйтергә кирәк: җомга иртәсендә һәм пәнҗешәмбе көнне кан алдырмыйлар, чөнки ул көннәрдә бер сәгать бардыр ки, нигездә, кан туктамас, соңыннан кеше вафат булырга мөмкин. ■

«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1914 елның февраль ае

Шәһәрнең мәктәпләр комиссиясендә

30 гыйнварда* шәһәрнең мәктәпләр комиссиясе мәҗлесе булды. Бу мәҗлестә мөселман әгъзалардан Габдулла Йосыф угылы Апанаев[1], Габдулла мелла Апанаев[2], Гайнетдин Мөэминов, Һади Максуди хазир иделәр. Мәҗлестә урта мәктәпләр хакында байтак мәсьәләләр мөзакәрә кылынды [тикшерелде]. [...][3] Русча-татарча 3 нче ибтидаи мәктәпкә дин мөгаллиме кую мәсьәләсе, дин мөгаллимлегенә дигән кандидатлар хакында шәһәр ибтидаи мәктәпләре һәм дә комиссиянең мөселман әгъзалары мәгълүмат алганга кадәр кичектерергә карар ителде. Рафаэль.

№ 328. — 3 февраль

Имамлыкка тасдыйк ителгән [расланган] мәхдүм

Бишбалтаның беренче мәсҗедендә имам Билал хәзрәтнең[4] угылы Исмәгыйль мәхдүм[5] бер елдан бирле эшсез ята иде. Атасының иҗтиһады вә үзенең мәхәллә халкына күренә белүе аркасында, хәзер атасына шәрик [иптәш] имамлыкка сайланып, 13 гыйнварда губернатор тарафыннан тасдыйк ителде.

Мәхдүм әфәнде әһле гыйлемнән үк түгел, ләкин Бохара вә Хиҗаз

* Даталар иске стиль белән бирелә

[1] Габдулла Мөхәммәдйосыф улы Апанаев (1873-1937) — 1 нче гильдия сәүдәгәр, ат заводлары, 3 йорт, 300 дисәтинә җир хуҗасы.

[2] Габдулла Габделкәрим улы Апанаев (1862-1919) — җәмәгать һәм дин эшлеклесе, нашир, педагог, Печән базары (хәзерге Нурулла) мәчете имамы.

[3] Кыскартылган урында рус мәктәпләре проблемалары турында языла.

[4] 4 нче шәһәр мәчете каршындагы Айтуганов мәдрәсәсендә укыган Билалетдин Габитов 1874 елда Бишбалта бистәсе мәчетенә имам-хатыйб итеп билгеләнә. Ул, 1878 елда мәктәп каршында мәдрәсә ачып, бистә малайларын укыта башлый. Мәхәллә халкы, 1892 елда аңа ярдәмгә, Кострома шәһәре янындагы татар бистәсендә туып-үскән, Казанда дини белем алып, мөфти М.Солтанов чакыруы буенча Уфа ирләр гимназиясендә мөселман балаларына җәмәгать хисабына ислам дине сабагын укыткан Шәрәфетдин Абызовны (21.11.1859-8.04.1911) имам итеп сайлап куя. Ул, 1902 елда ахун исемен алып, мәхәлләнең беренче имамы итеп сайлана. 1911 елда, Ш.Абызов үлгәннән соң, Бишбалта бистәсе мәхәлләсенә кабат Билалетдин җитәкчелек итә башлый.

[5] Исмәгыйль Билалетдин улы Габитов (8.08.1891-1920 еллар уртасы) шулай ук 1910 елда Айтуганов мәдрәсәсен тәмамлый. Ике ел чит илдә дини белемен тирәнәйтеп кайта. Шунда ук имамлыкка билгеләнә алмау сәбәбе — егеткә канун буенча тиеш булган 22 яшь тулмау була. Ул мәчет каршындагы мәдрәсәдә, шулай ук Бишбалта бистәсендә шәһәр идарәсе хисабына эшләүче рус-татар башлангыч мәктәбендә укучы мөселман балаларына дин сабагы укыта, биредәге педагогик хезмәте өчен елга 300 сум жалованье ала.

күргән кеше. Аның имамлыкка сайлануы да мәхәлләгә имам кирәк булганлыктан түгел, мәхдүмгә мәхәллә кирәк булганлыктан.

Атасы хәзрәт мәктәп-фәлән тәрбия итеп мәшәкатьләнгән кеше түгел, мәхдүм әфәндегә «атасына охшамаса иде», дип дога кылабыз.

Шулай да Казанга инде меллаларны тикшеребрәк алырга, меллалыкка мәхдүмнәрдән бигрәк, әһле гыйлемне сайларга тырышырга вакыт җитте инде.

Учитель булачак әфәнделәр

Казанда Татарская учительская школаны[6] бетерәчәк егетләрнең барысы быел ундүрт икән. Шуларның арасыннан берсе — Уфадагы «Галия»не[7] бетергән, аннан чыккач школага кергәнче берничә ел мөгаллим дә булып торган Зәки Ишаев. Калганнардан икесе «Буби»ның[8] дүртенче рөшдия [урта] сыйныфын бетергән егетләр — Камил Мансуров белән Тәкыйулла Алиев. Берсе — Уфа «Госмания» мәдрәсәсенең[9] дүртенче рөшдиясеннән килгән Кәнзелгыйлем Солтанаев. Ике әфәнде Казанның Галимҗан хәзрәт мәдрәсәсеннән[10]: берсе — Габбас Индиков, өченче рөшдия бетергән. Икенчесе — беренче рөшдиядән килгән Габделшәкүр Аширов. Калганнардан икесе — Сәхибгәрәй Габделбәширов белән Шәрифҗан Үтәшев — мәдрәсә күргән егетләр. Әмма калган бишесенең татарча укый-яза белүләре бик сайдыр. Заһиров.

Протоколлар

Үткән якшәмбе көн сату иткән өчен 2 нче частьта 67 мөселман сәүдәгәре өстеннән, 4 нче частьта 5 сәүдәгәр өстеннән, 3 нче частьта 10, шуларның 4се мөселман сәүдәгәр өстеннән протоколлар куелган.

№ 329. — 4 февраль

Бәйрәмнәрдә ял итү
(хокук комиссиясе утырышы)

Шәһәр хокук комиссиясенең 3 нче февраль мәҗлесендә, бәйрәмнәрдә ял итү көннәре хакында мөштәрәк [уртак] комиссия төзегән карарны, 1906 ел 15 ноябрь законына[11] мотабикъ итеп [туры китереп] төзәтергә дип, шәһәр Думасының 8 гыйнвар мәҗлесе тарафыннан тапшырылган мәсьәлә тикшерелде. Хокук комиссиясенең бу мәҗлесенә приказчиклар җәмгыятеннән вәкилләр, мөселман приказчикларыннан вәкил итеп Сәмигулла Салихов, рус сәүдәгәрләреннән вәкилләр килгән иде.

---

[6] «Татарская учительская школа» — Казанда 1876-1917 елларда башлангыч рус-татар мәктәпләренә укытучылар әзерләгән уку йорты.
[7] «Галия» — 1906-1920 елларда Уфа шәһәрендәге мәдрәсә.
[8] «Буби» — 1891-1911 елларда Вятка губернасы Иж-Бубый авылындагы (хәзерге Әгерҗе районы) мәдрәсә.
[9] «Госмания» мәдрәсәсе — 1887-1918 елларда Уфа шәһәрендәге мәдрәсә.
[10] «Галимҗан хәзрәт мәдрәсәсе» — 1882-1918 елларда Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе.
[11] «1906 елның 15 ноябрь законы» — шулай ук, 1907 елның 12 сентябрендә чыгарылган закон — приказчиклар, һөнәрчеләргә якшәмбе һәм христиан бәйрәмнәре көнне ял итү турында канун.

Комиссиядә Макаров рәислек итте. Мәҗлес Дума тарафыннан комиссиягә тапшырылган мәсьәләдән ерак читкә китте һәм руслар белән мөселманнар арасында сүз көрәштерү генә түгел, сүз сугышы төсен алды.

Руслар белән мөселманнар арасында булган бу мәҗлестәге моназарәне [сүз көрәштерүне] тәфсилләп язуны әһәмиятсез табабыз, чөнки бу моназарәләр башыннан аяк диярлек 8 гыйнварда шәһәр Думасында сөйләнгән сүзләрнең тәкрары гына иде. Ул чагындагы моназарәне без газетабызда мөфассал [җентекле] сурәттә язып үткәргән идек[12]. Сәүдә хезмәте вәкилләре — руслар, кызу сурәттә мөселманнарның гомуми мәмләкәт низамына баш июләрен, якшәмбеләрдә вә бүтән христиан бәйрәмнәрендә кибет ябуларын таләп иткәнлекләрен белдерделәр. Бу тәкәллефләренә [кылануларына] дәлил итеп, алар үзләреннән яңа бернәрсә дә сөйләмәделәр. Алар барлыгы ике халәтне генә күз алдында тоттылар. Беренчесе — мөселман сәүдәгәрләренең рус сәүдәгәрләренә конкурентлыгы, мөселман сәүдәгәрләренең үз бәйрәмнәрен бәйрәм итү ягында торулары барлыгы күп файда җыю теләге белән генә булган эш. Икенчесе — мөселманнарга үз бәйрәмнәрендә ял итәргә ихтыяр бирү, бәйрәмнәрдә ял итү мәсьәләсен гамәлгә татбикъ итәргә [яраштырырга] уңайсызлык китерә. Арада, мөселманнарның үз бәйрәмнәрендә ял итүгә әһәмият бирүләре дини, игътикади бер нигезгә мәбни [корылган] түгел, чөнки 1906 елда Дума тарафыннан мәҗбүри карар чыгарылганнан элек, мөселманнар җомга көннәрендә сату итәләр, кибет ачалар иде, диючеләр дә булды.

Мөселманнарны христиан бәйрәмнәрендә ял иттерергә тырышучылардан бөтенләй читтән чыгучылары да, эшнең инсафка гаид ягында эшебез юк, диючеләр дә, үз монафәгабызны [файдабызны] яклауда без бернәрсәдән дә тартынмыйбыз, диючеләр дә булды. Җөмләдән берсе, приказчиклар җәмгыятеннән вәкил булып килгән Непочатыхка комиссия мәҗлесендә бу мәсьәлә хакында мөселман приказчиклары белән сөйләшергә туры килде. Алар өчен ял итү көне якшәмбеме, җомгамы — барыбер, дигән сүзне әйтүдән дә тартынмады. Аның сүзенә караганда, мөселман приказчикларының кайберләренә якшәмбе вә христиан бәйрәмнәрен бәйрәм итү яхшырак та икән, чөнки рус бәйрәмнәре мөселманнарныкыннан күбрәк икән.

Табигый, мондый әсассыз [нигезсез] бәян үзенә тиешле рәдд [кире] җавабын алмый калмады. Мөселман приказчиклардан вәкил булып барган Сәмигулла Салихов Непочатыхның бу сүзләреннән борчылган хәлдә, аның бу сүзләре бөтен мөселман приказчикларга ифтира [яла], бу сүзләрнең һәммәсе дә ялган икәнен игълан итте.

Непочатых, үзенең гадәтенчә, һәрвакытта мондый урында әйтә торган сүзен тәкрар [кабат] әйтте: «Әгәр ялган булса, исбат ит, исбат итә алмасаң, минеке дөрес!»

Мәҗлестә мөселманнарны яхшы химая итә [яклый] торган Садретдин Максудов[13] бар иде. Ул һәрбер сүзне тәгъкыйб итә барды. Мөселманнар файдасына булган һәммә фикерне тәкъвия кыйла [яклап куәтли] вә тулма-

---

[12] Күләмле мәкаләләрне кара: Чиркәү бәйрәмчеләре — мөселманнар // Кояш. — 1914. — №309. — 9 гыйнвар; Бикколов И. Казан шәһәр Думасында (шәһәр Думасының 8 гыйнвардагы мәҗлесенә куелачак мәсьәләнең әһәмиятенә карап, «Кояш» үз идарәсеннән ике мохбир җибәргән иде) // Кояш. — 1914. — №310. — 10 гыйнвар; Рафаэль. Казан шәһәр Думасында // Кояш. — №311. — 12 гыйнвар.

[13] Садретдин Максудов (1878-1957) — дәүләт эшлеклесе, сәясәтче, хокук белгече.

ган фикерләрне тутыра барды. Думада 8 гыйнвар мәҗлесендә мөселманнар файдасына әйткән фикерен тәкрар әйтте. Мөселман сәүдәгәрләренә үзләренең дини вә горфи бәйрәмнәрендә бәйрәм итәргә ихтыяр бирелсен, дигән фикерне мәҗлескә гарыз итте. Комиссия бу фикерне кабул итмәгәч, шәһәрнең мөселманнары күп урынын һәм фәкать мөселманнарга китә торган әйберләр белән генә сәүдә итүче мөселман ягын (Болакның бу ягын[14]) аерырга гарыз итте.

Мөселман приказчиклар вәкиле Сәмигулла Салихов үзенең иптәшләре булган приказчикларның чын дини вә милли яклаучысы роленә кереп китте булса кирәк, аның кызу нотыгыннан ялыныч вә үтенечләр үзенә йөкләнгәннән дә артып киткәне сизелде. Ул русларны үзенең фикеренә чынлап төшенергә вә шулвакытта үзләрен ничек хис итәчәкләрен тәгаен итәргә өндәде. Ул аларны гадәдләре [саннары] вә көчләре күп җәһәтеннән өндәде, үзенең көчле вә күп гадәдле түгел икәненә ишарә кылды. Мәсьәләгә инсаният ноктасыннан карарга, салкын уй белән эш итүне ташларга, саф күңел белән эш итүне юлбашчы итеп алырга дәгъвәт итте. Ул үзенең таләпләрен киметә-киметә бик азга калдырырга да риза булды. Җомга көн бәйрәм итүнең бары тик Печән базарына тәхсыйс ителүен [билгеләнүен], иң ахыр чиктә мөселманнарга үз бәйрәмнәрендә кибетне ябарга, якшәмбе вә башка христиан бәйрәмнәрендә нибары 5 сәгать кибет ачарга рөхсәт ителүен сорады. Болай итеп кимететелгән һәммә таләпләр, хиснең иң нечкә җиреннән, җәрәхәтләнгән күңелдән саф рәвешчә чыккан, дингә вә горефкә ихтирам белән булган бу үтенечләр әсәрсез [эзсез] калдылар.

Комиссия, мәҗбүри карар ляихәсенең [проектының] 2 нче маддәсендәге мөселманнарга үз бәйрәмнәрендә бәйрәм итәргә, христиан бәйрәмнәрендә сәүдә кылырга ихтыяр бирелер, дигән ихтарны [искәртмәне] бетерергә карар бирде.

Менә шулай бәйрәмнәрдә ял итү мәсьәләсе хәл ителүнең мөкаддимәсе булды. Шәһәр Думасы бу карарны алмаштырыр, мөселман җәмәгатенә тиешле булган рәвешчә хәл кылыр, диеп өмид итәргә урын юк. Шулай да комиссия мөселманнарга җомга бәйрәм итүгә ихтыяр бирүне Дума тиешле җирләренә мөрәҗәгать итеп үтенсен, һәрникадәр законга хилаф булса да, мөселманнарның җомга бәйрәм итүләрен тиешле җиреннән үтенергә Думаның хакы барлыгына карар бирде. Рафаэль.

№ 330. — 5 февраль

Протоколлар

Якшәмбе көн сәүдә иткән өчен төрле сәүдәгәрләр өстеннән протоколлар куелган. Беренче частьта — 48 протокол, һәммәсе мөселманнар өстеннән. Икенче частьта — 35, һәммәсе мөселманнар өстеннән. Өченче частьта — 8 протоколдан 5се мөселман, 3се рус өстеннән. Алтынчы частьта —15 протокол, 9ы мөселман өстеннән.

№ 334. — 11 февраль

[14] Ягъни Печән базары тирәсендәге сәүдә рәтләре

Авыл хуҗалыгы поезды

Җирләр исляхате департаментының ярдәме белән Мәскәү-Казан тимер юлы идарәсе авыл хуҗалыгы дәресләре оештырачак вә моның өчен кирәкле нәрсәләр йөртергә махсус бер поезд бирәчәк. Поезд авыл хуҗалыгы хакында лекцияләр уку һәм шул хосуста киңәшләр бирүгә хезмәт итәчәк. Поездны йөртүдән максуд: Мәскәү-Казан тимер юлы буйларындагы игенче халык арасына авыл хуҗалыгы гыйлемнәре таратмактыр. Поездда бер аудитория вагоны, ике данә музей вагоны, ике вагон хайваннар өчен йөртеләчәктер.

Сөембикә манарасы

Сөембикә манарасы бик искергәнлектән, күптән инде шәһәр идарәсе аны төзәтергә йөри. Ике ел чамасы инде эченә кеше кертелми иде. Бу көннәрдә губерна вәлисе [хуҗасы] шәһәр идарәсенә шушы манараның кирпечләре коела башлаганлыгын, якынына бару куркынычлыгын, шуңа күрә бик тиз арада эшкә керешеп, бу тарихи бинаның төзәтелүе тиеш икәнлеген белдергән.

Шәһәр идарәсе хәзер шушы манараның иң зарур урыннарын гына булса да тоткарсыз төзәтүне үзенең бер архитекторына тапшырырга карар биргән.

Коръән аятьләрен хурлау

Габдулла Килдишевның[15] ит кибетеннән берәү мәчеләргә ашатырга дип ит сатып алган. Шушы итне кибеттән Һади Максуди әсәре «Мөгаллиме сани»нең[16] берничә данә сурәләр язылган 39 нчы сәхифәсенә төреп җибәргәннәр. Ит алучы мөселман кибетендәге мондый игътибарсызлыкка бик кәефе китеп, сәхифәне идарәбезгә кертеп бирде. Бу сәхифәнең ит кибетенә ничек төшкәнлеген белмибез. Һәрхәлдә мөселманнар мөкаддәс сүзләр язылган сәхифәләрне ихтирам итәргә тиешләрдер. Бу ихтирамны бервакытта да онытырга ярамый.

№ 335. — 12 февраль

Губернатор Боярскийның[17] тәшәккере [рәхмәт белдерүе]

7 февральдә җомга намазыннан соң, беренче җамигъда имам Сафиулла хәзрәт[18] халыкка падишаһ хәзрәтләренең тәшәккерен изһар итеп [белдереп]

---

[15] Габдулла Килдишев — мәшһүр ит һәм казылык сәүдәгәре. «Кояш» газетасында: «Шәрык казылыклары кярханәсе. Восточная Колбаса. Габдулла Килдишев тарафыннан тәэсис ителгән бу кярханә 3 нче ел дәвам итә! Аурупа ысулында хәзерләнеп хифзыссыйхәткә [саулыкны саклауга] муафикъ [туры килгән] рәвештә илле төрледән артык казылык вә колбаса бастырмалар эшли...» — кебек реклама даими рәвештә басылган.

[16] Һади Максуди әсәре «Мөгаллиме сани» — татар һәм башка мөселман халыклар арасында укырга-язарга өйрәтә торган китап. Басмаханәләрдә китапның күп тиражлар белән еш басылып торуы мәгълүм.

[17] Пётр Михайлович Боярский (1870-1944) — рус җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе. Казан губернасының соңгы губернаторы (1913-1917).

[18] Сафиулла Абдуллин — 1899 елда 1нче җамигъ мәчетнең икенче имамы итеп билгеләнә, 1908 елдан мәчетнең беренче имамы вазифаларын башкара.

язган хәбәрне сөйләп, дога кылындыктан соң, губернатор җәнапларына дә дога әйтелгән иде. Ошбу вакыйганы мәчет вә мәдрәсә назыйре рапорт берлән губернаторга игълям иткән [белдергән] һәм февральнең 11ендә губернатор Габдрахман әфәнде Кушаевка[19] һәм мәсҗедтә хазир булып дога әйткән мәхәллә халкының һәркаюларына үзенең гаять мәмнүн булдыгын белдереп тәшәккернамә [рәхмәт хаты] җибәргән.

Мортазинның[20] бенефисы

Җомга көн — 14 февральдә Шәрык клубында «Сәйяр» труппасы[21] баш артистларыннан Вәлиулла әфәнде Мортазинның бенефисы булды. Бенефис шәрифенә Шиллерның «Мәкер вә мәхәббәт» исемле әсәре куелды. Сәхнәнең кечкенәлегенә, мондый әсәрләрне уйнауда тәҗрибәнең юклыгына карамыйча, артистлар «Мәкер вә мәхәббәт»не шундый бер иттифак берлән, шундый тырышып уйнадылар ки, аларга шатланып карамаска мөмкин булмады: бенефис сахибе Мортазин үзе Фердинанд ролен менә дигән итеп башкарды. Аның рольне бик яхшы аңлаганлыгы, бик тырышып эшләгәнлеге һәрбер хәрәкәтеннән күренеп тора иде. Хода яман күздән сакласын, бу артист соңгы вакытларда бик зур адымнар белән тәрәккый итә бара. Аның бу тәрәккыен, бенефисы мөнәсәбәте белән матбугат әһеле һәдия [бүләк] җибәреп, мөселман студентлар адрес тәкъдим итеп, икърар иттеләр. Бөтен зал аны иң самими сурәттә алкышлады.

Кариев[22] һәм Болгарская[23] үз рольләрендә яхшы иделәр. Иманская[24] гадәттәгечә йомшак иде.

Залда халык тулы, буш урыннар һичбер калмаган иде. Сбор да Шәрык клубы залы бирә алырлыкның кямиле [тулысы]— 400 сум иде. Бенефис сахибенә матбугат әһелләреннән бик матур өстәл сәгате һәм алтын брелок һәдия ителде. Бүләк бик матур итеп чәчәкләргә чолганган иде. Мөхәррир Галиәсгар Камал[25] әфәнде тарафыннан Мортазинга көмеш портсигара, артист Кариевтан көмеш бокаллар, артистка Болгарскаядан алтын жетон, Габдулла Сәгыйдовтан көмеш шырпы савыты һәм сәүдәгәрләр тарафыннан язу әсбаплары һәдия ителде. Шәрык клубы һәм мөселман студентлар Мортазинга адрес бирделәр. Студентлар тарафыннан бирелгән адреста милли сәхнәнең нинди фикергә хезмәт итәргә тиешлеге һәм Мортазинның милли сәхнәдә тоткан урыны оста вә матур күрсәтелгән иде.

---

[19] Габдрахман Габдулла улы Кушаев (1862-1917 елдан соң) — 2 нче гильдия сәүдәгәр.

[20] Вәлиулла Гайназар улы Мортазин-Иманский (1885-1938) — актёр, режиссёр. 1907-1915 елларда «Сәйяр» труппасында иҗат итә. БАССРның халык, РСФСРның атказанган артисты.

[21] «Сәйяр» труппасы — 1907 елда Оренбургта оешкан беренче татар профессиональ театраль төркем. 1919 елда аның җирлегендә Беренче татар совет драма труппасы төзелә.

[22] Габдулла Кариев (Миңлебай Хәйрулла улы Хәйруллин) (1886-1920) — актёр, режиссёр, татар профессиональ театрына нигез салучыларның берсе.

[23] Гөлсем Муса кызы Болгарская (1891-1968) — актриса, ТАССРның халык, РСФСРның атказанган артисткасы.

[24] Мәрфуга Иманская (1928 елда вафат) — артистка, В.Мортазин-Иманский хатыны, 1910 елдан «Сәйяр», 1915 елдан «Ширкәт» труппасында.

[25] Галиәсгар Галиәкбәр улы Камалетдинов (1879-1933) — күренекле драматург, театр сәнгате һәм җәмәгать эшлеклесе.

Спектакль тәмам булгач, Мортазин матбугат әһеле һәм зыялыларга чәй тәкъдим итте һәм кыска гына бер нотык белән хазирунга хөсне тәвәҗҗеһләр [яхшы теләкләр] өчен рәхмәтләр укып, бу хөсне тәвәҗҗеһләр үзе өчен бик зур куәт булганлыгын бәян итте. Соңгы кунаклар клубтан сәгать бишенчедә генә тарала башладылар.

№ 339. — 17 февраль

Табибә мәктәбен тәмам иткән мөслимә

«Ак юл» журналы[26] мөхәррире Фәхрелислам Агиевның[27] рәфикасе [хатыны] Суфия ханым, Петербургтагы гали [югары] тыйббия [медицина] институтын тәмам итеп, кичә Казанга кайтты. Язда государственный экзаменнар тотачактыр. Булачак яшь табибны, мәктәпне уңышлы бетерүе белән тәбрик итеп, тоткан юлында да уңышлар телибез.

№ 340. — 18 февраль

Сөембикә манарасы

Губерна башлыгы һәм вилаять, шәһәр вә земство эшләре присутствиесе Сөембикә манарасының бик бозылганлыгын күрсәтеп, аны төзәтү тиешлегенә тәнбиһләрдә булына [искәртеп] килделәр.

Инде хәзер шәһәр идарәсе үзенең инженерлары белән шуны тикшерергә керешкән. Алар, манараны карагач, бик начар хәлдә дип тапканнар ки, югарыдагы кәрнизләре төшә башлаган, кирпечләре коела икән, манара яныннан үтәргә дә куркыныч хәлдә икән.

Шәһәр управасы бу тарихи манараны төзәтергә хәзердән үк керешергә карар бирде һәм шәһәр инженеры Евдокимов аны төзәтергә 7 мең сум акча кирәк булыр, дип тәхмин дә итеп [чамалап билгеләргә дә] өлгерде.

Без, үз тарафыбыздан, шуны әйтә алабыз ки, Сөембикә манарасы шикелле зур манараны төзәтергә әлеге тәхмин ителгән микъдар гына җитешә алмаячактыр. Бу манараның саклануы мөселман җәмәгате өчен бигрәк тә әһәмиятле ки, манараны төзәтер өчен мөселманнар моннан элегрәк үзара акча җыймакчы да, шул акчага төзәттермәкче дә булганнар иде. Инде хәзер шәһәр идарәсе бу эшкә башлап үзе керешкәч, халык хезмәтендә торучы мөселманнарның вазифасы — шушы манараның төзәтелүенә зур әһәмият биреп, аның бозылырлык рәвешчә купкан җирләренә ямау салу белән генә канәгатьләнмичә, төзәтүнең мөкәммәл [камил] булуына тырышудыр. Моннан тыш, тарихи хәтердә булган бу манара төзәтелгәч тә, үз архитектурасын югалтмыйча, искедә булган үзенчәлеген саклау да, шулай ук мөселманнарның вазифасыдыр.

Өмид итәбез ки, мөселманнардан булган яхшы кешеләр бу тарихи хатирәне әүвәлдән килгән хәлендә саклау юлында хезмәтләрен аямаслар

---

[26] «Ак юл» — 1913-1916 елларда Казанда татар телендә айга ике мәртәбә нәшер ителгән балалар өчен рәсемле әдәби журнал.

[27] Фәхрелислам Нигъмәтулла улы Агиев (1887-1938) — балалар язучысы, журналист. «Ак юл» журналының нашире һәм мөхәррире.

һәм, әгәр шәһәр идарәсе тәгаен иткән кадәрле мосариф [акча] манараны төзәтүгә җитмәслек булса, бозып калдырудан саклау өчен ярдәм итүдән дә тартынмаслар[28].

Автомобиль ярышлары[29]

22 февральдә вилаять земствосы автомобиль ярышы оештырачак. Автомобильләр газ заводы яныннан Оренбург тракты буенча китәчәкләр.

Вилаять земская управасының рәисе Миленков ярышта иштиракъ итәчәк [катнашачак] автомобильләрне театр мәйданында 21 февральдә карап чыгарга рөхсәт итүне шәһәр идарәсеннән сораган. Шәһәр главасы ризалык җавабын биргән[30].

№ 341. — 19 февраль

Сыгыр [сыер] туйдыру хакында рисалә

Заливадный әфәнденең «Сыгырны авырлыгына карап ашатыгыз!» дигән рисаләсенең татарчага тәрҗемәсе бу көннәрдә басылып тәмам буладыр. Бу рисаләчек авыл халкы өчен файдалы китаплар нәшер итә торган Ибраһим мирза Терегулов[31] тарафыннан нәшер ителгән, рәсемнәр белән бизәлгән.

Мәрҗани урамы хакында

25 февральдә чыккан «Йолдыз» газетасы Һади әфәнденең[32] шәһәр Думасына, Екатерининская поперечная урамның Мәрҗани урамы дип аталуын сорап, гариза бирдеген язадыр[33]. Бу урамның бер тарафында 7-8 йорт, бер тарафында 4-5 йорт кына булганга, бу урамны гына Мәрҗани диеп атау азрак булыр төсле. Безнеңчә, Шиһаб хәзрәтләренең үз урамы булган Захарьевская урамын[34] Мәрҗани исеме илә атау яхшырак булыр иде. Мәрҗанинең йорты һәм Мәрҗани мәсҗеде шушы урамда булу да, бу урамны Мәрҗани дип атауның яхшырак булганын күрсәтәдер[35].

Хәйретдин Әхмәдҗанов.
№ 347. — 26 февраль

---

[28] 1914-1916 елларда «Сөембикә» манарасы вертикаль юнәлештән тайпыла башлау сәбәпле, аңа реставрация эшләре үткәрелә, түбән ярусы тимер кыршау белән уратып алына. XX гасыр — XXI йөз башында манараны өйрәнү һәм ныгыту эшләре 1941-1955, 1958-1959, 1977-1978, 1985-1991, 1998, 2004 елларда башкарыла.

[29] 1907 елда Пекин-Париж маршруты буенча дөньяда узган беренче зур автомарафонның Казан һәм Алабуга шәһәрләре аша узуы мәгълүм. Бу турыда кара: http://humus.livejournal.com/2808971.html

[30] Әлеге ярышның булу-булмавы турында «Кояш» газетасында мәгълүмат юк. «Йолдыз» газетасының 1914 елгы 23 февраль санында бу турыда: «Кичә иртә белән Казаннан Лаеш шәһәренә ярышыр өчен 11 автомобиль чыгып китте. Бу ярышны баш булып карар өчен 21 февральдә Петербургтан Императорское Российское автомобильное обществоның (1903 елда Санкт-Петербургта оеша. — *Л.Г.*) рәисе һәм падишаһ хәзрәтләренең флигель-адъютанты полковник Владимир Владимирович Свечин җәнаплары Казанга килде. Автомобильләр чыгып киткәч, кинәт кар бураны башланды. Бу буран автомобильләрнең юлларын бозачак дип куркалар, чөнки алар шул ук 22 февральдә Лаештан Казанга кайтачаклар икән».

Шиһабетдин Мәрҗани урамы

Шәһәр Думасының үткән мәҗлесендә Шиһабетдин әл-Мәрҗани исеме белән берәр урамны атау мәсьәләсе мөзакәрәгә [тикшерүгә] куела алмый калды, вакыт җитмәде. Киләсе мәҗлесендә, иншаллаһ, бу мәсьәләгә чират тияр.

Болай караганда кечкенә генә шикелле күренгән бу мәсьәлә безнең өчен бик зур әһәмияткә иядер. Бу мәсьәләдә рус гласныйлары үзләренең безгә каршы саклаган мөнәсәбәтләрен, безнең олугларыбызга күрсәтергә тиеш тапкан ихтирамнарын изһар итәчәкләрдер [белдерәчәкләрдер].

Русларның һичбер интересларына зарар итмичә, безгә зур ризалык вә шатлык бирерлек бу эшне рус гласныйлары риза калеб белән үткәрсәләр, бу эш һәр ике тараф өчен бик күңелле булачак вә арадагы күркәм мөгамәләне арттырачактыр. Шиһабетдин әл-Мәрҗани хәзрәтләре үзенең сәяси мәсләге белән бик могтәдил [умеренный] кеше булганлыктан, Казанны идарә итә торган мәэмүрләр дә [чиновниклар да] Думаның шул карарын тасдыйк итүдән [раслаудан] баш тартмас, дип өмид итәргә мөмкин. Зур дини галимебез, мөәррихебез [тарихчыбыз], халыкны яктылыкка өстерәгән бер милләт хадимебезнең исеме белән мөселманнар яши торган бер урам аталганнан ни хөкүмәт вә ни рус халкы һичбер төрле зарар күрәчәк түгелдер.

Думаның бу мәсьәлә каралачак мәҗлесенә мөселман гласныйлар берсе дә калмый килергә вә рус иптәшләренә бу мәсьәләнең безнең өчен әһәмиятле икәнен аңлатырга тиешлеләрдер ки, өмид итәбез, гласныйларыбыз бу эштә мөсаһәлә итмәсләр [игътибарсызлык күрсәтмәсләр].

Милләтнең үз угылларын ихтирам итә белүе, аларга ядкярләр калдыра алуы — кирәк үсә торган буынны тәрбия итү ноктаи нәзарыннан, кирәк хезмәт кадерен тәкъдир итү ноктаи нәзарыннан бик әһәмиятле эштер. Милләт үзенең милли аңы үсүе нисбәтендә генә үзенең олугларын хөрмәт итә белә һәм олугларын хөрмәт итә алган микъдарда гына ул үзүзен хөрмәт иткән буладыр. Олугларын, хезмәт иткән кешеләрен онытткан милләт шөкранәсез, аңсыз милләттер ки, аның дөньяда яшәргә хакы юктыр.

№ 348. — 27 февраль

Печән базары мәсҗеденең[36] хисабы хакында

Печән базарының мәсҗеде килә торган доходының күплеге белән Казан мәсҗедләре арасында беренче мәсҗедләрдән саналадыр. Аның файдасына

---

[31] Ибраһим Вәлиулла улы Терегулов (1852-1921) — педагог, тәрҗемәче, җәмәгать эшлеклесе, татар телендә бакчачылык, игенчелек, терлекчелек фәннәре буенча китаплар нәшер итә.
[32] «Һади әфәнденең» — Әхмәдһади Максуди турында сүз бара.
[33] Урам исемнәрен үзгәртү // Йолдыз. — 1914. — № 1132. — 25 февраль. Биредә «Поперечная первая Екатерининская» дип языла, ягъни хәзерге Зәйни Солтан урамы турында сүз бара. Екатерининская урамы хәзерге Габдулла Тукай урамы дип атала.
[34] Бу урамга 1930 елда Каюм Насыйри исеме, мәгърифәтченең 105 яшьлек юбилее уңаеннан бирелә.
[35] Казанның Кабан күле буенда революциягә кадәр — «Левая набережная Кабана», Совет чорында — Комсомольская исеме белән танылган урамга Ш.Мәрҗани исеме 1998 елда гына, галимнең 180 еллык юбилее уңаеннан бирелә.

вәкыф ителгән бәгъзе кибетләрдән алына торган акча, мәсҗеднең расходларына җитү генә түгел, елдан-ел артып килә. Шулай итеп мәсҗеднең үзенә махсус бер сәрмая тәшкил итәдер.

1910 елга кадәр бу мәсҗеднең попечителе булып Садыйк әфәнде Галикәев[37] торган иде. Ул һәр елны мәхәллә халкына мәсҗед акчасының еллык хисабын күрсәтә, никадәр доход вә никадәр расход булганлыгын һәм мәсҗеднең үзенә караган акчасының хисап елында никадәр артканлыгын җентекле бәян итә иде.

1910 елда Садыйк әфәнде үзенең хосусый эшләре сәбәпле, попечительлекне ташларга карар биргәч, мәхәллә аның урынына Гайнетдин әфәнде Сабитовны[38] сайлады. Садыйк әфәнде бу яңа попечительгә 1910 елның 17 мартында мәсҗеднең хисабын күргәзеп, мәсҗеднең үз исеменә Волжский-Камский банкка салынган 11 160 сум акчасының билетын һәм кулда торган 3 сум 76 тиен акчасын тапшырды вә шуның белән мәсҗеднең бөтен хисабы Гайнетдин әфәнде Сабитов тарафыннан йөртелә башлады.

Шәһәребезнең могтәбәрләреннән бер затның идарәбезгә хәбәр бирүенә күрә, яңа попечитель Гайнетдин әфәнде Сабитов мәхәллә халкына хәзерге көнгә хәтле бер мәртәбә дә мәсҗеднең хисабын күрсәтмәгән икән. Имеш хәбәрләренә күрә, мәсҗед вакыфлары акчасыннан вакыф шартында күргәзелмәгән җирләргә расход тотылганлыгы да ишетелә. Бу соңгы хәбәрләрнең никадәр нигезле икәнлеге безгә мәгълүм түгел, шулай да Гайнетдин әфәнде мәсҗеднең хисабын елга бер мәртәбә мәхәлләгә күргәзеп килергә тиеш иде. Идарәбезгә кергән мәхәллә картларының кайберләре бездән ошбу эшне газетабызга дәрҗ итүне [бастыруны] үтенделәр.

Габдулла Кариев бенефисы

Бүген 28 февральдә «Сәйяр» труппасының мөдире Габдулла әфәнде Кариев бенефисы хөрмәтенә Шәрык клубында татар телендә театр уйналачак. Тамашага VIII Людвиг заманындагы французлар тормышыннан «Хөкемдә хаталык» исемле биш пәрдәлек куәтле драма белән, Габдулла Кариевның беренче әсәре — «Артист» исемле бер пәрдәлек комедиясе куелачак. «Хөкемдә хаталык» драмасы өчен кирәк булган киемнәр эшләтелде. Уен, һич кичекмәенчә, 8 сәгатьтә башланыр.

№ 349. — 28 февраль

*Текстны һәм искәрмәләрне басмага **Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

[36] «Печән базары мәчете» — 1845-1849 елларда төзелгән. 1992 елдан Нурулла мәчете дип исемләнә.
[37] Мөхәммәдсадыйк Мөхәммәдсафа улы Галикәев (1847-1919) — сәүдәгәр, хәйрияче, абруйлы җәмәгать эшлеклесе.
[38] Гайнетдин Сабитов (1858-1917) — сәүдәгәр һәм җәмәгать эшлеклесе. Милли баш киемнәре тегеп сату иткән.

ЯҢА КИТАПЛАР



КЫЙССАИ ЙОСЫФ / КОЛ ГАЛИ [текстны хәзерге әдәби телгә күчерүчеләр: Ф.Фасиев, А.Нуриева, Ә.Исхак; кереш сүз авторы Р.Ганиева; рәссамы Б.Гыйльванов]. — Казан: Татар.кит. нәшр., 2013. — 224 б.

Татар халкы яшәешендә озак гасырлар дәвамында рухи юлдаш вазифасын үтәгән тирән эчтәлекле әсәрләр бар. Шуларның күреклесе — болгар бабаларыбыздан мирас булып калган шагыйрь Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы (1233). 2013 елда болгар-татар әдәбиятының нигез ташларын салучы мәшһүр шагыйребез Кол Галинең тууына 830 ел тулды. Бу уңай белән Татарстан китап нәшрияты әдәбият сөючеләргә, «Кыйссаи Йосыф» поэмасының 1983 елгы басмасына нигезләнеп, танылган рәссам Булат Гыйльванов һәм мөхәррир Р.Хәсәншин бизәлешендә башкарылган яңа әдәби-нәфис басмасын тәкъдим итте.

Коръәни Кәримнең 12 сурәсенә һәм фарсы әдәбияты үрнәкләренә нәзыйрә рәвешендә иҗат ителгән Кол Гали кыйссасының оригиналы безнең көннәргә кадәр килеп җитмәгән; гасырлар дәвамында татар халкы аны күчермәләрдә укыган. Мәгърифәтче Утыз Имәни тарафыннан әзерләнгән кыйссаның тәнкыйди тексты беренче тапкыр 1839 елда Казан университеты типографиясендә дөнья күрә һәм Октябрь инкыйлабына кадәр ул Казанда 80 мәртәбә диярлек басылып чыга. Совет атеизмы хөкем сөргән елларда, дини рухтагы әсәр дип, «Кыйссаи Йосыф» поэмасына әллә ни игътибар бирелми. Шулай да XX гасыр уртасында тел галиме, текстолог Җәвад Алмаз тарафыннан аның яңартылган тәнкыйди тексты әзерләнә, әмма совет заманындагы идеологик каршылыклар аркасында басылмый кала. ЮНЕСКО карары нигезендә, 1983 елда — Кол Галинең тууына 800 ел тулу уңае белән — тел галиме Фазыл Фасиев, текстны транскрипцияләп, искәрмәләр һәм глоссарий (аңлатмалы сүзлек) белән фәнгә мәгълүм кулъязмаларын тасвирлап бастырып чыгара. Юбилейдан соң кыска гына вакыт аралыгында — 1989 елда — Йосыф кыйссасының, галим һәм шагыйрь Нурмөхәммәт Хисамов тарафыннан әзерләнгән, хәзерге әдәби телгә шигъри тәрҗемәсе дә дөнья күрә.

Менә кабат утыз елдан соң, Ф.Фасиев, А.Нуриева, Ә.Исхакларның хәзерге татар әдәби теленә тәрҗемәсеннән файдаланып, Венера Камалиева редакциясендә Кол Гали кыйссасының яңа басмасы эшләнде. Аңа кереш сүз профессор Резеда Ганиева тарафыннан язылган. Аталар һәм балалар конфликтына корылган, Зөләйханың Йосыфка булган ялкынлы мәхәббәтен сурәтләгән бу поэманы галимә Көнчыгыш Ренессанс кысаларында мәйданга чыккан болгар-татар Яңарышы әсәре итеп карый, андагы һәр мәсьәләнең илаһият фәлсәфәсенә таянып яктыртылуына, әсәр каһарманының гүзәллек, акыл, гаделлек, сабырлык даһие итеп гәүдәләнүенә игътибар итә. Әсәр авторы Йосыфның һәр гамәлен әт-Тәүхид фәлсәфәсе күзлегеннән чыгып бәяли, һәм үзенең әдәби тәхәллүсен Аллаһ колы Гали, ягъни «Кол Гали» дип атый. Коръәнгә һәм Мөселман Ренессансының гуманистик традицияләренә таянып, болгар-татар шагыйре Кол Гали дә Кешене Галәмнең Олуг Заты дип игълан итә.

Бөек Кол Гали шигъриятенең гуманизмы бүген дә мәдәниятебез һәм әдәбиятыбызның әхлакый кыйммәтләр чыганагы һәм мәхәббәт сакчысы булып калуын дәвам итә. Нурмөхәммәт Хисамовның Кәрим Тинчурин исемендәге Татар Дәүләт драма һәм комедия театрында сәхнәләштерелгән «Йосыф-Зөләйха» тарихи драмасы (языла — 1992, куела — 2012), шагыйрь Ренат Харис либреттосына композитор Леонид Любовский тарафыннан иҗат ителгән «Кыйссаи Йосыф» балеты (2001) шул хакта сөйли.

Алия Мөбарәкшина,
Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты аспиранты ■

РИФКАТЬ ВАХИТОВ

Татарстанның халык рәссамы, республикабызның атказанган сәнгать эшлеклесе

Рәссам 1938 елның 26 февралендә Ижау каласында туа. 1954-1959 елларда Казан сынлы сәнгать училищесында, 1959-1965 елларда Харьков (Украина) сынлы сәнгать институтында рәссам һөнәрен үзләштерә. 1965-1990 елларда Ижау, Ташкент сынлы сәнгать институтларында һәм Казан сынлы сәнгать училищесында укыта, 2006 елдан — Казан (Идел буе) федераль университеты доценты.

Рифкать Мөхәммәт улы — монументаль-декоратив сәнгать әсәрләре һәм тарихи портретлар авторы. Картиналарында ислам цивилизациясе һәм татар мәдәнияте традицияләре чагылыш таба. Аның сәнгать әсәрләре Татарстанның үзәк музейларында, Лондон, Амстердам, Голландия, Төркия, АКШтагы шәхси тупланмаларда һәм галереяларда урын алган.

«Сөембикә». 2013
Киндер, май

*Халкыбыз тарихы,
әдәби, мәдәни мирасыбыз,
тәнкыйди фикер һәм
заманча караш – барысы да*
«ЧЫН МИРАС»
журналында

Беренче ир балалар гимназиясе.
Бүгенге көндә — А.М.Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты

ИНДЕКС

ТАТАРСТАНДА – 54132

ЧИТ ТӨБӘКЛӘРДӘ – 70275

БЕЗ МИРАСЛЫ ХАЛЫК. «ЧЫН МИРАС» БЕЛӘН БЕРГӘ БУЛЫГЫЗ!

МИРАС №2 / 2014